БАЛАЛАР – ПӘРӘВЕЗДӘ
Белгечләр аларны гаджетлардан аерырга киңәш итә

> 15

УЙДЫРМА ҺӘМ ЧЫНБАРЛЫК:
вакцинация турындагы сорауларга җаваплар

> 16

РИММА ИБРАҺИМОВА:
«Хәзер җырчы белән композитор арасында элемтә юк»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 8 (28781) | Җомга | 21 гыйнвар | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

Роман Хасаев

ИЛ АГАСЫ

ДӘҮЛӘТ КИҢӘШЧЕСЕ МИНТИМЕР ШӘЙМИЕВКӘ – 85 ЯШЬ

Кемне булса да хөрмәт белән телгә аласы булса, без берсеннән-берсе матур сүзләр эзли башлыйбыз. Татарда исә аларның бөтенесен дә алыштырырлык, үзенә күп мәгънә сыйдырган бер сүз бар, ул – «ага» дигән сүз. «Ага» дип без өлкән яшьтәге кешегә генә әйтмибез, ул – иң тәҗрибәле, тормыш күргән олпат зат. Заманалар үзгәргәндә, дөньялар буталганда, кыенлыклардан чыгу юлы табылмаганда, яисә туар көн томанлы күренеп, югалып калганда киңәш-табыш итәрдәй шәхес ул. Инде «ил агабыз» дибез икән, миллионлаган кеше язмышы өчен җаваплылыкны үз өстенә алырга курыкмаган зирәк шәхес күз алдына килеп баса. Без әнә шундыйларның берсе – Минтимер ага Шәймиевне олуг юбилее белән котлыйбыз, аңа озын гомер, исәнлек-саулык телибез!

> 4–7

Ишетми калмагыз

Пенсия өстәп бирелә

Дәүләт Думасы 1 гыйнвардан пенсияләрне 8,6 процентка арттыру турында төзәтмәне соңгы укылышта кабул итте. Шулай итеп, 2022 елда илдә пенсиянең уртача күләме 18984 сум тәшкил итәчәк. Өлкәннәр гыйнварда 5,9 процентка арттырылган пенсия алды инде. Февраль аенда аларга 8,6 белән 5,9 процент арасындагы аерма өстәп биреләчәк. Хезмәт һәм социаль яклау министры Антон Котяков әйтүенчә, бу хәбәр 30,8 миллион чамасы кешегә кагыла.

Иң мөһиме – гаилә һәм эш

Татарстан халкы быел гаилә һәм эшкә өстенлек бирергә ниятли. Республикада яшәүчеләр арасында hh.ru тикшеренүләр хезмәте үткәргән сораштыруның төп нәтиҗәсе шул. Респондентларның 59 проценты шушы ике вариантны сайлаган. Моннан тыш халык үз-үзен камилләштерүгә (57%), сәламәтлекне кайгыртуга (45%) өстенлек бирмәкче. Шулай ук яраткан шөгыленә (29%), спортка (12%) һәм дус-ишләр белән күңел ачуга (7%) күбрәк вакытын багышларга ниятләүчеләр дә бар.

Бигрәк тә эшчеләр (76%), шулай ук яшь белгечләр (73%) һәм административ хезмәткәрләр (65%) эшкә зур игътибар бирергә җыена. Ә үз-үзен камилләштерү белән асылда мәдәният һәм медиа өлкәсе вәкилләре (71%) шөгыльләнергә ниятли.

Карлы яллар

КФУ профессоры, география фәннәре докторы Юрий Переведенцев әйтүенчә, соңгы өч көндә Татарстан башкаласында айлык норманың өчтән бер өлеше күләмендә кар яуган. Бу республикага тәньяктан үтеп кергән циклонга бәйле. «Кар катламы биеклеге 45 мм тәшкил итә. Ай йомгаклары буенча явым-төшем нормасы арттырып үтәләчәк. Хәзер безгә чираттагы атлантик циклон килә. Ул карны азрак алып киләчәк, әмма явым-төшем булачак әле», – дигән Переведенцев.

Татарстан Гидрометеоүзәгеннән хәбәр итүләренчә, 22 гыйнварда көндезге сәгатьләрдә Татарстанның күпчелек өлешендә кар көтелә. Көндез –5...–10 градус, төнлә –9...–14 градус суык булачак. Көнчыгыш районнарда термометрның терекөмеш баганасы 18 градуска кадәр төшәчәк. 23 гыйнварда карлы-буранлы һава торышы саклана. Көндез –5...–10 градус, төнлә –8...–13 градус суык. Синоптиклар фаразына караганда, якшәмбедән дүшәмбегә каршы төндә, элеккечә, аз гына кар явып торачак. Киләсе атнаның башка көннәрдә явым-төшем ихтималы аз. Атна башында суыта: көндез –8...–13 градус булса, төнлә –11...–16 градус көтелә.

Районнарда ни хәлләр?

Минзәлә

Тыл ветераны Оркыя апа Минһаҗева тормыштан тәм табып, балалары ихтирамын тоеп, Минзәлә шәһәрендә гомер кичерә. Ул бу көннәрдә үзенең 100 яшьлек олуг юбилеен билгеләп үтте. Аны шәһәр башлыгы урынбасары Роза Салдаева район башлыгы Айдар Сәлахов исеменнән тәбрик итте, Россия Президенты Владимир Путин һәм Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның котлау открыткаларын тапшырды. Оркыя апа тумышы белән элеккеге Калинин, хәзерге Актаныш районы Пучы авылыннан. 1960 елда тормыш иптәше, балалары белән Минзәләгә күченеп киләләр. Оркыя апаның хәтере яхшы, тормыш-көнкүреш вакыйгалары, ил яңалыклары белән даими кызыксына. Бүген ул үз йортында уллары тәрбиясендә гомер кичерә. 5 оныгы, 6 оныкчыгы һәм оныкчыкларының да ике баласы бар.
(«Минзәлә-информ»)

Зәй

Шәһәрнең 370 еллык юбилеена шәһәрдә яңа бассейн төзергә планлаштыралар. Спорт корылмасы 35 нче кварталда төзеләчәк. Проект эшләре инде башкарылган. Аның нигезендә бердә өлкәннәр һәм балалар өчен аерым йөзү урыннары ясау планлаштырыла. Һәрберсендә душ кабиналары, киенү-чишенү бүлмәләре каралган. Төп бассейнда алты йөзү юлы булачак, аларның озынлыгы 25 метрны тәшкил итәчәк.
(«Зәй офыклары»)

Чаллы

2021 елда Җәмигъ мәчет төзелешенә 55,8 миллион сум акча җыелган. Аның 48,6 миллионы финанс ярдәме фондына акча күчерү юлы белән кергән. 2021 елда мәчет төзелешенә акча җыюда иң актив хәйриячеләр булып «Хаят Кимья» һәм «Кастамону» оешмалары табылган. Алар икесе дә җиде миллион ярымышар сум акча биргән. «Сетевая компания» – 5 миллион 155 мең сум, «Яңарыш» фонды 5 миллион сум белән ярдәм иткән. Чаллыдагы проектның 6,6 мең квадрат метрдан артыграк мәйданында – биналар комплексы, ә үзәктә гөмбәзле биш катлы төп бина булачак. Мәчет манараларының иң озыны 76 метр биеклектә булыр дип көтелә. Чагыштыру өчен: «Кол Шәриф» мәчетенең манаралары – 58 метр.
(«Челнинские известия»)

Арча

Бу сезонда Арча Укучылар сарае «Мин – Арча баласы» проектын «Восточный» территориаль иҗтимагый үзидарәсенең җирле иҗтимагый оешмасы белән бергә гамәлгә ашырачак. Проект кысасында Арча районының тарихи һәм истәлекле урыннары турында 15 видеоролик булдыру планлаштырыла. Шулай ук иҗади конкурслар: рәсемнәр, фотографияләр, ребуслар чишү, асфальтта рәсем ясау, тарихи квестлар, фестиваль дә дәвам итәчәк. Анда Арча районында яшәүче 5 яшьтән алып 18 яшькә кадәрге барлык балалар һәм яшьләр катнаша ала.
(«Арча хәбәрләре»)

ХЕЗМӘТЕНӘ КҮРӘ ХӨРМӘТЕ

Зирәк, хөрмәтле, үрнәк. Беренче Президент Минтимер Шәймиевнең туган көне уңаеннан юлланган котлауларда әнә шулай диелә.

Россия Президенты Владимир Путин, Минтимер Шәймиевнең бар тормышы һәм эшчәнлеге Татарстан үсешенә багышланган иде, дип билгеләп үткән.

Республиканы үзгәртеп кору чорында җитәкләгәндә, ул иң катлаулы һәм кискен мәсьәләләрне хәл итүдә үрнәк булып торды. «Төбәкнең социаль-икътисади үсешенә, аның мәдәни, рухи традицияләрен саклауга зур өлеш кертүегез иҗтимагый абруй алып килде һәм сез илебездә хөрмәт казандыгыз. Сезнең дини һәйкәлләрне торгызуга юнәлдерелгән проектларыгыз тынычлык һәм татулык кыйммәтләрен ныгытуның мөһим символына әверелде», – диелә аның тәбрикләмәсендә.

Дәүләт алдындагы казанышлары өчен Минтимер Шәймиев Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә Изге апостол Андрей Первозванный ордены белән бүләкләнде. Бу – Россия Федерациясенең иң югары дәүләт бүләге. Әлеге орден белән, Россиянең үсешенә, бөеклеген һәм данын арттыруга ярдәм иткән гаять зур хезмәтләре өчен, илнең күренекле дәүләт һәм иҗтимагый эшлеклеләре, шулай ук, Россия алдындагы хезмәтләре өчен, чит илләр башлыклары һәм хөкүмәтләре җитәкчеләре бүләкләнә. 1998 елда торгызылган Андрей Первозванный ордены барлыгы 15 кешегә тапшырылган.

Россия Хөкүмәте башлыгы Михаил Мишустин Минтимер Шәймиевнең искиткеч сәясәтче, зирәк, җаваплы кеше булуын телгә алган.

«Сезнең һөнәри осталыгыгыз, хезмәтегез нәтиҗәсендә республика тиз арада үсеш алган, күп кенә тармакларда алдынгы саналган төбәкләрнең берсенә әйләнде. Сез хәзер дә туган республикагыз тормышында актив катнашасыз, күп эшләр башкарасыз», – диелә аның котлау хатында.

Илнең оборона министры Сергей Шойгу Татарстанның Беренче Президентын принципларына тугры кеше дип атады.

«Күп еллар дәвамында сез үз көчегезне һәм энергиягезне кыю максатларны тормышка ашыруга юнәлттегез, төбәкнең социаль-икътисади үсеше һәм чәчәк атуы өчен кулдан килгәннең барысын да эшләдегез», – дигән котлау сүзләрен җиткерде ул.

Казахстан Президенты Касыйм-Жомарт Токаев: «Минтимер Шәймиевне Казахстанда да хөрмәт итәләр һәм үзара хезмәттәшлеккә бәйле мөнәсәбәтләрне ныгытуга керткән өлешен югары бәялиләр», – диде.

Минтимер Шәймиевне шәхсән котлаучылар арасында Федерация Советы рәисе Валентина Матвиенко бар иде. Ул аңа 85 яшьлек юбилей хөрмәтенә Федерация Советына 25 ел тулу уңаеннан медаль дә тапшырды.

– Безне шулкадәр күп еллар бәйли, без бергә шундый катлаулы юл уздык. Сез, Минтимер Шәрипович, Россиянең таянычы булган шәхесләрнең берсе, – диде Валентина Матвиенко.

Моннан тыш Дәүләт Киңәшчесен Марат Хөснуллин, Дмитрий Медведев, Татьяна Голикова, Сергей Кириенко, Сергей Собянин, Анатолий Чубайс, Юрий Чайка, Радий Хәбиров, Равил Гайнетдин, Тәлгать Таҗетдин, патриарх Кирилл, Алексей Кудрин һәм башкалар котлады.

УТТА ЯНМАСКА, СУДА БАТМАСКА

Республикада янгыннар һәм анда үлүчеләр саны арткан. Алар тагын да күбрәк булырга мөмкин иде, янгын хакында хәбәр бирә торган махсус җиһазлар күп кешенең гомерен саклап калган. Соңгы биш елда шушы җиһаз тавышы 172 кешене үлемнән коткарган.

tatarstan.ru

Бу хакта Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча Баш идарәсе һәм Татарстан Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының уртак йомгаклау утырышында ведомство башлыгы Рафис Хәбибуллин җиткерде.

– Янгыннар һәм кешеләр үлү белән килеп туган хәлгә җентекләп анализ ясадык. 2020 һәм 2021 елдагы янгыннар саны аермасы – 95. Монда безнең дә гаеп барлыгын яшермибез, – диде ул. – Чаллы шәһәрендә 192 янгын очрагы, Тукай муниципаль районында 203 очрак теркәлгән. Шушы ике районадагы янгыннар бөтен республика буенча саннардан 4 тапкыр күбрәк. Кешеләр үлеме очраклары белән дә шундый ук хәл күзәтелә. Уттан чыга алмыйча, узган ел 178 кеше үлде. Шуның алтысы – балалар. Янгында гомере өзелгән кешеләрнең 62 проценты исерек хәлдә булган.

Рафис Хәбибуллин һәр йортка янгын хакында хәбәр бирүче җиһаз куярга кирәклеген тагын бер кат искәртте. 2016 елдан бирле республикада шундый 340 мең җайланма куелды. Аның кирәклеге елдан-ел ныграк сизелә.

– Күпме кеше гомерен саклап калып була бит. Әлеге җиһазны кую теләген белдергәч, безне Татарстан Президенты хуплады һәм аларны алу өчен ярдәм күрсәтте. Моның өчен республика җитәкчелегенә чиксез рәхмәт. Сүз кеше гомере хакында бара. Киләчәктә дә бу эшне дәвам иттерергә иде, – диде ул.

Гадәттән тыш хәлләр килеп чыкса, республикада меңнән артык яшерену урыны бар. Аларга 645 яшеренү һәм 449 радиациядән саклану урыны керә. «1 меңнән артык яшеренү урынының 768е теләсә кайсы вакытта кешеләрне качырырга әзер», – диде Рафис Хәбибуллин.

Республикада кышкы чорда да сулыкларда коткару постлары эшли. Коткару дигәннән, быел «112» хезмәтенә дә шалтыратучылар күп булган. Ел дәвамында 2 миллионнан артык кеше мөрәҗәгать иткән. Тәүлегенә 6 мең шалтыратучы була икән. Министр киләчәктә җавап бирүне тизләтү турында да әйтте. Быелдан әлеге системага таләпләр үзгәрә. Кеше операторның җавабын 8 секундтан да артык көтмәскә тиеш. Шалтыратучының мөрәҗәгатен хәл итәр өчен 75 секунд биреләчәк. Әнә шуңа да Рафис Хәбибуллин утырышта Татарстан Премьер-министры Алексей Песошиннан әлеге системаны яңарту өчен матди ярдәм сорады. Үтенечләр аның белән генә бетмәде. Актанышка янгын сүндерү депосы кирәк, Казанда һәм Чаллыда урнашкан янгын станцияләре төзекләндерү көтә, Республика тернәкләндерү үзәгенә дә ремонт кирәк.

Алексей Песошин коткаручыларның үтенеченә дә каршы килмәде, эшләренә дә уңай бәя бирде.

– Тулаем алганда, Татарстандагы күрсәткечләр илнең башка төбәкләренә караганда түбәнрәк булуга да карамастан, аеруча торак массивларында һәм кешеләр күп җыелган урыннарда янгыннарны кисәтү эшен дәвам иттерергә кирәк, – диде ул. – «112» хезмәтенә килгән бер шалтырату да игътибарсыз калмасын. Һәр очракта сүз кеше язмышы турында бара. Сулыклардагы хәлләр дә уйландыра. Узган ел 10 ел дәвамында булмаган урман янгыннары күзәтелде. Әмма сезнең һөнәри осталык белән без җиңеп чыктык. Быел исә республикада зур чаралар көтелә. Аныңына да сезнең ярдәм кирәк булачак.

Утырыш башланганчы Алексей Песошин Татарстан Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы хезмәткәрләрен кирәкле техника бирел сөендерсә, ахырдан иң алдынгыларга мактаулы исемнәр, Рәхмәт хатлары тапшырды.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

МИНИ-ТРАКТОР ОТКАН ФАВАРИС ГАЛИЕВ:

«БАШТА ЫШАНМЫЙ ТОРДЫК»

Илдар Мөхәммәтҗанов

Без укучыларыбызны һәрдаим сөендереп торырга тырышабыз. Менә бу юлы да 2022 елның беренче яртыеллыгына газетага язылучылар арасында мини-трактор уйнаттык. Акциянең иганәчесе – «Уралец» сәүдә йорты белән әзерләнгән бүләгебез Балтач районының Смәел авылына китә.

«Ватаным Татарстан»га язылучыга – мини-трактор» акциясенә 1500дән артык квитанция кабул итеп алдык! Җиңүчене исә редакция коллективы белән 20 гыйнварда ачыкладык. Алдан әйтелгәнчә, барысы да гадел узды, мини-тракторның булачак хуҗасын жирәбә юлы белән белдек. Әлеге мизгелләрне «Инстаграм»дагы сәхифәбез аша туры трансляциядә күрсәттек. Бәхетленең исеме кем, дисезме? Газетабыз уйнаткан мини-трактор Балтач районының Смәел авылында гомер итүче Фаварис Галиевка насыйп булды. Ничек туры килде: ул Россиянең атказанган агрономы икән. Без Галиевлар гаиләсен чын күңелдән котлыйбыз!

Аңа бу хәбәрне җиткереп шалтыраткач, берничә минуттан Фаварис абый үзе кабат элемтәгә чыкты. Ышанмаганнар икән куанычлы хәбәргә: мошенниклар алдамыймы дип борчылганнар! Нишләмәк кирәк, заманасы шундый. Тугызынчы дистәсен ваклаучы укучыбыз газета белән 10 яшьлек чагыннан бирле таныш икән.

– Сез шалтыраткач, әбием баскан җиреннән биеп китә язды. Әле дә ышанып бетеп булмый – бүләге бигрәк саллы бит! Кичә генә шул турыда уйлап куйган идем. Мин бит «Ватаным Татарстан»ны 10 яшемнән бирле укыйм. Безнең мәрхүм әтиебез дә 95 яшенә кадәр укыды аны, бер калдырмады. Гаиләбезнең каныңа сеңгән басма. Уку гына түгел, бик еш язышып торабыз әле без. Газета битләрендә күп тапкырлар шигырьләрем басылды. Аларны күргән саен сөенәм, – диде ул. – Инде бер генә бүләк уйнатмадыгыз бит, моңа кадәр дә сез уздырган бәйгеләрдә катнаша килдек. Алла рәхмәте, монысында бәхет елмайды бит, әй!

Фаварис абый белән Гөлсем апа ике ул һәм ике кыз үстергән. Бер уллары күршеләрендә генә яши икән. «Ул трактор малай белән икебезгә булыр инде. Үзебезнең дә бакча бар бит. Кечкенә булса да, эше җитәрлек. Алла боерган булса, трактор булган эшне җиңеләйтер иде», – ди Фаварис абый.

ВИРУСЛЫ СОРАУЛАР АРТА

Зур тырышлык, төгәллек, акыл көче сорый торган чиктән тыш мөһим эш. Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Юстиция министрлыгы коллегиясе утырышында ведомство хезмәткәрләренең эшен шулай бәяләде. Чарада министрлыкның узган елдагы эшчәнлегенә йомгак ясалды.

Юстиция министры Рөстәм Заһидуллин әйтүенчә, 2021 елдагы эшчәнлек асылда коронавирус инфекциясен йөгәнләүгә ярдәм итү юнәлешендә алып барылган. Чикләү чаралары кертелү сәбәпле, халыктан кергән мөрәҗәгатьләр саны алдагы елдагыга караганда ике тапкыр арткан. 4670 мөрәҗәгатьнең 3040ы коронавируска каршы чараларга бәйле.

Закон проектлары буенча эшчәнлеккә килгәндә, министрлык узган елда Дәүләт Советына 34 закон проектын кертә. Шулай ук законнарны гамәлгә ашыру өчен 99 норматив акт әзерләнгән. Ведомстволар һәм муниципаль хакимият органнары норматив хокукый актларына экспертизалар саны 3 тапкыр арткан.

Министр кешеләргә бушлай юридик ярдәм күрсәтү буенча эш турында да сөйләп үтте. Аның әйтүенчә, Россиянең 28 төбәгендә дәүләт юридик бюролары оештырылган. Татарстан Президенты да республикада шундый бюро булдыру турында карар кабул иткән.

Фәрит Мөхәммәтшин министрлыкның узган елдагы эшчәнлегенә югары бәяләде. «Эшегезне башка юнәлешләр белән чагыштыру кыен, – дип билгеләп үтте ул. – Зур тырышлык, төгәллек, акыл көче сорый торган чиктән тыш мөһим эш бу. Аны сез уңышлы алып барасыз».

Парламент башлыгы ведомство хезмәткәрләренә коронавирус инфекциясе таралуга каршы көрәштәге ярдәм өчен рәхмәт сүзләре җиткерде. «Яңа чикләүләр кертелү сәбәпле, кешеләрнең дәүләт хакимияте органнарына мөрәҗәгатьләре артты, судларга хакимият карарлары буенча шикаятьләр алына башлады. Мондый шартларда яңа эш формаларын табу, прививка ясатырга шикләнүчеләрнең, аңа каршы булганнарның һәркайсына «барып җитү» бик мөһим», – диде ул.

Киләсе елда министрлык белгечләренә «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» федераль закон проектын тикшерү эшенә ныклап алынырга туры киләчәк. Әлеге документ җирле үзидарәләр эшенә зур үзгәрешләр кертергә мөмкин. Димәк, халык тормышына да турыдан-туры кагылачак. Шуңа күрә Фәрит Мөхәммәтшин әлеге закон проектын төрле яклап өйрәнергә киңәш итте.

Кимчелекләр дә юк түгел. Закон актларын кабул итүгә кагыла бу. Фәрит Мөхәммәтшин фикеренчә, аларның кайберләре соңарып кына пәйда була. Ә бу хәл законнарны үтәмәү сәбәбенә китерергә мөмкин. «Парламент кабул итеп, Президент имзалаган законның гамәлгә керүгә үк эшли башлавына ирешергә кирәк», – диде ул.

Утырышта җәмәгать судьяларының эшчәнлеге турында да сүз булды. Узган ел әлеге судларда эшләүче 308 кеше эштән киткән. Кайбер районнарда хәтта бер ел эчендә бөтен кеше алмашынып беткән. Ә бит Татарстанда җинаять эшләренең – 31, гражданлык эшләренең – 82, административ эшләрнең исә 90 проценты җәмәгать судларында карала. Бер участокка уртача 348 эш туры килә. Эштән китү сәбәбен хезмәт хакы түбән булу белән аңлаталар. Быел бу мәсьәләне ничек тә хәл итәргә тырышачаклар.

ТАТАРЧА СӨЙЛӘШӘБЕЗ

Айдар ШӘЙХИН

КАРНЫ ЧИСТАРТУ / ЮЛНЫ ЧИСТАРТУ

Кыш җиттеме, матбугат чараларында һәм дәүләт органнарының рәсми сәхифәләрендә кар чистарту турында яза башлыйлар. Тырыша-тырыша кар чистартуның кемгә кирәге бардыр, һич аңлый алмыйм. Шул ук вакытта кар чистарткан кешене яки андый җиһаз яисә машинаны да күргәнем булмады әле. Аны чистартыр өчен махсус иләкләр уйлап таптылар микән, белмим.

Сарказм саркып торган бу җөмләләремнән эшнең нидә икәнлеге, бәлки, аңлашылгандыр. *Кар чистарту машинасы, Казан урамнарында карны чистарту* кебек сүзтезмәләр һәм җөмләләрдән чыга торган мәгънә шундый: кемдер пычрак карны нәрсәдәндер чистарта. Мәсәлән, комнан яки тоздан. Яисә башка берәр нәрсәдән. Ә бит әйтәсе килгән сүз бөтенләй башка булгандыр. Сүз, әлбәттә, урамнарны кардан арындыру, түбәләргә җыелган карны төшерү турында барадыр. Әмма без никтер рус телендәгечә *чистить снег* дигән тезмәне татарчага тәрҗемә итәбез дә куябыз (рус телендә дә болай сөйләшү әдәби дип саналмый).

Сүзлеккә генә игътибар итик, бар да аңлашылыр: *Чистарту – 1) кердән, чүптән, пычрактан һ.б.дан арындыру, чиста итү; 2) чүбеннән, катнашмалардан арындыру, чүпсез итү.*

Димәк, *кар чистарту машинасы* түгел, ә *кардан чистарту машинасы, кар чистарткыч* түгел, ә *кардан чистарткыч, карны чистарту* түгел, *кардан чистарту*. Дөрес җөмлә мисалы: *Хәзер юлларны кардан чистарту мәсьәләсе килеп басты.*

Чиста, чистарту сүзләре рус теленнән кергән, *пакь, пакьләү* сүзләренең килеп чыгышы исә фарсы теленә барып тоташа. Сөйләшләрдә шул ук мәгънәдә *таза, тазарту* сүзләренең кулланылуы билгеле. Аны саф төрки сүз дип карый алабыз.

ТОРМЫШ / ЯШӘЕШ / ЧЫНБАРЛЫК

Күптән түгел «Телеграм» каналларының берсендә татар телендә *бытие* сүзенең тәрҗемәсе турында сорау бирелгән иде. Уйламыйча гына тәрҗемә итсәң, барысы да җиңел сыман: *бытие* – тормыш, яшәеш, чынбарлык. Әгәр дә сүзнең *быть/essere* фигыленнән чыкканлыгын исәпкә алсаң, калькалаштырып, *бар булу* яки *булу* дип тәрҗемә итәргә мөмкин.

Әгәр дә *бытие* сүзенең фәлсәфи категория булуын искә төшерсәк, сорау бераз катлауланa төшә. Эш шунда ки, безгә алай тоелмаса да, чынлыкта фәлсәфә – шактый төгәл фән. Ул билгеле бер мантыйкка буйсына яки аны үзенең коралы итә һәм билгеләмәләрнең конкрет булуын таләп итә. Шуңа да без бер җөмләдә – *тормыш*, ә икенчесендә *яшәеш* дип яза алмыйбыз. Фәлсәфә төшенчәсе буларак, татарча *бытие* үз эченә төшенчәнең бар төсмерләрен сыйдырырга тиеш.

Бу җәһәттән телебездә элек кулланылган *вөҗүд* сүзе отышлы булып тоела. Ул *яшәеш, барлык (бар булу), бытие* дигәнне аңлата. Әйе, аның рухи яссылыктагы мәгънәсеннән тыш, матди мәгънәсе дә бар: *тән, корпус, гәүдә*. Әмма күбесенчә аның беренче мәгънәсе кулланыла.

Карл Марксның хезмәтеннән өзек менә ничек яңгырар иде: *«Матди тормышны җитештерү ысулы, гомумән, тормышның иҗтимагый, сәяси һәм рухи процессларына алшарт булып тора. Кешеләрнең вөҗүден аңнары билгеләми, киресенчә, иҗтимагый вөҗүд аларның аңнарын билгели».*

Ни өчен *бытие* сүзен *яшәеш* дип тәрҗемә итеп булмый соң? Монда *существование* дигән категориянең дә барлыгын онытмаска кирәк. Аны татарчалаштырганда *яшәеш* сүзенең кирәге чыгачак әле.

ТОРМЫШЫГЫЗ – ФИДАКАРЬЛЕК ҮРНӘГЕ

Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе, республиканың Беренче Президенты Минтимер Шәрип улы ШӘЙМИЕВкә 85 яшь тулу уңаеннан Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Нургали улы МИҢНЕХАНОВның КОТЛАВЫ

МӨХТӘРӘМ МИНТИМЕР ШӘРИПОВИЧ!

Сезнең олы казанышларга бай, гамьле тормышыгыз – фидакарьлек һәм Ватанга тугры хезмәт итү үрнәге.

Авыл хезмәтчәннәре гаиләсендә туып-үсеп, тырышлык, оешыру сәләте кебек асыл сыйфатларыгыз нәтиҗәсендә инженердан алып Россиянең иң эре төбәкләреннән берсе булган республика җитәкчесе вазыйфасына кадәр барлык үсеш баскычларын уздыгыз. 25 яшьтә үк инде Сезне зур оешма – «Авыл хуҗалыгы техникасы» районара берләшмәсенең идарәчесе итеп куялар, ә 29 яшьтә Сезгә Советлар Союзының иң зур бүләге – Ленин ордены тапшырыла.

Җәмгыятьтә социаль-икътисади һәм иҗтимагый-сәяси үзгәрешләр барган чакта Сез Татарстан җитәкчесе вазыйфасын үтәргә алындыгыз. Зирәк, уйланылган сәясәтегез шул катлаулы чорда республиканың бик күп мәсьәләләрне хәл итеп, кыенлыкларны җиңүенә китерде, үткәндә тупланган зур тәҗрибәне саклап калырга, үстерергә мөмкинлек бирде. Татарстанның Россия Федерациясендә алдынгы һәм алгарышлы төбәк буларак беренчеләр сафына чыгуын тәэмин иткән социаль-икътисади программалар Сезнең җитәкчелектә гамәлгә ашырылды.

Сез – Татарстан Республикасы дәүләтчелегенең хәзерге моделе архитекторларының берсе, яңа Россия дәүләтчелеген төзүгә, аның федерализмы һәм демократиясе нигезләрен ныгытуга гаять зур өлеш керттегез.

Сезгә төпле акыл һәм тиешенчә, тәртип белән эш итү, фикер офыкларының киңлеге хас. Сез Россия Федерациясе Президенты Владимир Владимирович Путинның илебезне ныгытуга юнәлтелгән курсын эзлекле төстә хуплый киләсез.

Уңышларыгызның нигезен, һичшиксез, сәясәтче буларак көчле ихтыярыгыз, җитәкчелек сәләтегез, фикердәшләрегезне оешкан командага туплый белүегез тәшкил итә. Дипломатлык, аралашу осталыгы һәм кешелеклелек кебек сыйфатларыгыз халыкара эшчәнлекнең нәтиҗәле булуына, Татарстан Республикасының дөньяда танылуына ярдәм итте. Россия татарлары һәм чит илләрдә яшәүче татарлар, илебез һәм бөтендөнья мәселманнары алдындагы олы абруегыз дәүләтебез бердәмлеген һәм аның куәтен арттыруга хезмәт итә.

Граждан җәмгыяте институтларының үзара нәтиҗәле элемтәләрен җайга салып, Сез милләтләрнең дус-тату яшәвенә, диннәргә тигез караш булдыруга ирештегез, бу исә Татарстанга конкурентлык өстенлеге бирде, бик күпләрнең аның белән хезмәттәшлек итәргә теләк һәм кызыксыну белдерүенә этәргеч булды.

Милләтара мөнәсәбәтләр һәм мәдәниятләр арасындагы багланышлар мәсьәләләре буенча бөтен дөньяда танылган белгеч буларак, Сез Россиянең һәм республиканың ЮНЕСКО белән тыгыз хезмәттәшлеге нигезен кордыгыз. Сезнең булышлык белән ЮНЕСКОның Бөтендөнья мирасы исемлегенә Казан Кремле, Болгар тарих-архитектура һәм археология комплекслары, Свияжск утрау-шәһәренең православиедә изге дип танылган корылмалары кертелде.

Сезнең башлангычта һәм илебез Президенты Владимир Владимирович Путин ярдәме белән Болгар ислам академиясен ачу һәм Казан Мәрьям Ана иконасы соборын торгызу буенча тиңдәшсез проектлар гамәлгә ашырылды. Болар бөтен Россия күләмендә рухи яңарыш һәм тарихи гаделлек тантанасы буларак кабул ителә.

«Адымнар – белемгә һәм бердәмлеккә юл» күптелле белем бирү комплексын булдыру юнәлешендә Сез башкарган игелекле эш искиткеч зур әһәмияткә ия. Монда туган халкыбызның мәдәниятенә һәм теленә ата-ана тәрбиясе белән сеңдерелгән сакчыл карашыгыз, шулай ук башка халыклар мәдәниятләренә олы хөрмәтегез чагыла.

Турыдан-туры тавыш бирү барышында республика Президенты вазыйфасына өч тапкыр сайлануыгыз, «Россия Федерациясе Хезмәт Герое» дигән мәртәбәле исемгә, «Ватан алдындагы казанышлар өчен» орденының барлык дәрәҗәләренә һәм башка олы бүләкләргә лаек булуыгыз – болар барысы да Сез алып барган күпкырлы эшчәнлекнең гаять югары бәяләнүенә дәлил.

Шунысы сөенечле: ачыклык, ярдәмчеллек, олпатлык кебек хасиятләрегезне саклап калган хәлдә, Сез республиканың иҗтимагый-сәяси тормышында бәрәкәтле хезмәтегезне дәвам иттерәсез.

Сезне, мөхтәрәм Минтимер Шәрипович, ихлас йөрәктән юбилеегыз белән котлыйм һәм нык сәламәтлек, озын гомер, уңышлар телим!

МИНТИМЕР ШӘЙМИЕВ: «ТӨП КАГЫЙДӘМ –

Гаилә һәм балачак

Әнкәй исән чакта авылга сирәк кайтканыма үкенәм. Барысы да бар югыйсә: транспорт, вакыт, мөмкинлекләр… Ә әнкәй янына кайтып күрешеп килергә өлгермим. Әни кеше ул һәрчак үз балаларын көтеп яши.

Биш яшьтә мин апамнан хәрефләрне күрсәтеп-аңлатып бирүен үтендем. Әткәй, хәреф тануымны белгәч, мине тантаналы төстә өстәлгә утыртты да кулыма газета тоттырды. Үзе каршымда минем район газетасыннан ниндидер хәбәрне кычкырып укуым белән горурланып, күңеле булып тыңлап утырды. Бәлки шуңадыр, яңа газета-журналлардан, яңа китаплардан килгән типография буяулары исе – балачагымнан калган иң яраткан исләрнең берсе. Мәктәп елларында минем иң яраткан җирләремнең берсе район китапханәсе иде.

Сәкинә – язмышның миңа биргән иң зур бүләгедер ул. Чынлап та шулай. Безнең якта бик зур кадер турында «күз керфеге кебек итеп» диләр. Сәкинә гаиләбезне күз керфеге кебек итеп саклады. Яшьлек мәхәббәте белән, яраткан кешеңә өйләнү, кияүгә чыгуның нинди зур байлык булуын торып-торып аңлыйсың. Без үзебезне таныштырган, табыштырган көннәрне ниндидер бер якты сагыш белән, матур итеп сагынып сөйләшәбез. Гомер буе ара-тирә искә төшергәләп торгангамы, һәр мизгеле аермачык ул, шагыйранә итеп әйтсәк, сәгадәтле сәгатьләрнең.

Мин – авыл малае, шуның белән горурланам. Җирдә туып, шул тормышны күреп үсү, абзар исен иснәү, этләр, хайваннар арасында йөрү, дересен әйткәндә, үзе бер могҗиза ул. Авыл җирендә мал арасында үстек без, шуңа күрә бер эт тәрбияләү турында гел хыялландым. Президент вазыйфалары моңа мөмкинлек бирмәде. Президентлыктан китәргә бер ел кала, алдан ук эт баласы алып куйдым. Исеме Тукай шигыреннән алынды – Маһмай.

Бервакыт, сабый чакта, мин бик каты авырып киткәнмен. Аңыма килеп, күземне ачкан чакларымда баш очымда утыручы әнкәй белән әткәйнең борчулы йөзләрен күрүдән, маңгаемдагы сулы чүпрәкне алмаш-тилмәш алыштырып торуларын тоюдан ниндидер татлы хис кичерүемне хәтерлим…

Тел

Туган тел – ана теле, чөнки ул һәркемгә тумыштан бирелә. «Тел – ананың теләге, тел – ананың баласына иң кадерле бүләге», – ди татар халык мәкале. Аны ата-бабаларыбызның васыяте дип тә, әманәте дип тә әйтеп була. Ана телен саклау, аны буыннан-буынга җиткерү – әниләребезне ярату, ата-бабаларыбызны ихтирам итү билгесе. Шуңа күрә кешене үз теленнән, милләтеннән, диненнән мәхрүм итәргә беркемнең дә хакы юк.

Тел, милләт язмышын хәл итүдә аның барлык проблемаларын ва тирәнтен аңлаган, үз йөрәгә аша кичергән затларның катнашуы зарур дип саныйм. Мондый авыр заманны без бер үздык бит инде.

Биография

Туган көне — 1937 елның 20 гыйнвары

Туган җире — Актаныш районының Әнәк авылы

Белеме — 1959 елда Казан авыл хуҗалыгы институтының механикалаштыру факультетын тәмамлаган

Хезмәт эшчәнлеге
- ТАССР Мөслим районы ремонт-техника станциясе инженеры, баш инженеры (1959)
- ТАССР «Сельхозтехника» Минзәлә районара берләшмәсе идарәчесе (1962)
- КПСС Татарстан өлкә комитетының авыл хуҗалыгы бүлеге инструкторы, мөдир урынбасары (1967)
- ТАССРның мелиорация һәм су хуҗалыгы министры (1969)
- ТАССР Министрлар Советы Рәисенең беренче урынбасары (1983)
- КПСС Татарстан өлкә комитеты секретаре (1983)
- ТАССР Министрлар Советы Рәисе (1985)
- КПСС Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре (1989)
- ТАССР Югары Совет Рәисе (1990)
- Халык тарафыннан Татарстанның беренче Президенты итеп сайланды (1991 елның 12 июне)
- Аннан соң ике тапкыр: 1996 елның 24 мартында һәм 2001 елның 25 мартында халык тарафыннан Татарстан Президенты итеп кабат сайланды
- Россия Президенты В.В.Путин күрсәтүе буенча, Татарстан Дәүләт Советы тарафыннан М.Ш.Шәймиевкә Татарстан Президенты вәкаләтләре бирелде (2005 елның 25 марты)
- 2010 елның 22 гыйнварында үз кандидатурасын киләсе срокка Татарстан Президенты вазыйфасына күрсәтүне кире какты һәм шул ук елның 21 апрелендә Татарстан Дәүләт Киңәшчесе итеп билгеләнде

Дәүләт бүләкләре — Ленин ордены (1966), Хезмәт Кызыл Байрагы ордены (1971), Октябрь Революциясе ордены (1976), Халыклар дуслыгы ордены (1987), II дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлар өчен» ордены (1997), I дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлар өчен» ордены (2007), III дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлар өчен» ордены (2010), IV дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлар өчен» ордены (2014), «Россия Федерациясенең Хезмәт Герое» исеме (2017), «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены (2010), «Дуслык» ордены (2015), Изге апостол Андрей Первозванный ордены (2022) һәм башка күпсанлы бүләкләр

КЕШЕЛӘРНЕ ЯРАТУ»

Милләт

Чыннан да, һәр халык үз киләчәген үзе кайгыртырга тиеш. Бу аның бердәмлек дәрәҗәсенә, милли үзаңына һәм матди куәтенә бәйле. Базар мөнәсәбәтләренә кучүгә карамастан, хөкүмәт милли мәдәниятне, телне саклап калу мәсьәләләреннән читләшмәячәк.

Габдулла Тукайның: «Рус җирендә без әсәрле, эзле без», – дип язуы – бу сорауга тулы җавап. Без үзебез турында үзебез кайгыртмасак, җан-фәрман хезмәт итмәсәк, аны кем хәл итәр... Әгәр башыңа милли аң тирән уелмаса, яшәүнең мәгънәсен күз алдына китерү дә авыр.

Милли үзаң көчәю – киләчәк берничә гасыр өчен нигез ул. Бөтен нәрсә дә тиз генә эшләнми, хәзер менә «Мин – татар!» дип кычкырып, горурланып йөри торган көннәр килде. Шуның белән татар халкына ихтирам да тудырдык. Чөнки илгә, дөньяга үзебезне акыллы, булдыклы һәм тәртипле халык итеп күрсәтә алдык.

Безнең халыкның, мөмкинлеге чикле булганда да, хыялы бар, рухы бар. Ә тарихта, мәгълүм булганча, омтылышлы, рухлы халыклар гына эз калдыра.

Эш

Мин бик яшьли җитәкче вазыйфаларда эшли башладым. Җаваплы эшкә иртә тотынуымның сәбәбен яшьтән үк фәнни, әдәби китаплар укырга яратуымнан, белемгә омтылудан күрәм. Гомер буе шулай кайнап яшәп, күп вакытымны эштә уздырганлыктан, өйдә утыруны күз алдыма да китерә алмадым. Ә инде бүген миңа күпмедер дәрәҗәдә игътибар-ихтирам бар икән, аңа ирешүнең юлы бер генә: кешеләрне яратырга кирәк! Кешеләрне яратып, кешечә мөгамәләдә булып эшләсәң генә, бу тормышта эзең кала. Бу һәммәбезгә дә кагыла!..

Шунысына сөенәм: эш дәверендә нинди генә мизгелләр булмады: ачулары килеп, ризасызлык белдерсәләр дә, нәфрәт белән карамадылар. Авыр икән, авыр, диделәр, еладылар, кычкырдылар, әмма мин беркайчан да, беркайда да үземә карата нәфрәт сизмәдем.

Тормыш фәлсәфәсе

Бала белән ана арасында да, ир белән хатын арасында да, туганнар, күршеләр, хезмәттәшләр арасында да хөрмәт яшәсә генә җаннар тыныч. Эчебез ак булып бетми икән, тормышның рәхәте юк. Һәркемнең гомере бер генә. Башлана да бетә ул, мәңгелек каршында безнең гомер – бер мизгел. Менә шуның турында ешрак язсак, сөйләшсәк, уйлансак иде...

Һәр кеше үзенең әзерлегеннән, тәрбиясеннән чыгып, яшәү рәвешенә һәм кагыйдәләренә карап, үз фикерен белдерә яки үз гамәлләрен кыла. Төрле кешегә төрле мохит тәэсир итә. Шуңа күрә үз карашыңны аңлата белергә һәм сабыр булырга кирәк. Үз гомеремдә күңелемдә эшче кешегә карата нинди дә ачу туганы булмады. Барысы да – безнең кешеләр, безгә беркемне дә Айдан ташламаганнар лабаса... Мин кешеләрне яратам – тормышымдагы төп кагыйдәм шул.

Әүвәл беркем дә «тәрбиялим әле» дип утырып, бала тәрбияләмәгән. Хәзер дә шулай ул. «Тәрбия җитмәдә шул» дигән сүз – үз-үзеңне алдау гына дим мин. Тормышта юньле аралашу, юньле мөгамәлә күреп үскән бала юньле була. Балада кимчелек күрсәң, гаепне үзеңнән эзлә, гаиләңнән эзлә. Бала шәхесенә нигез гаиләдә салына. Шул әби-бабай тирәсендә.

(Минтимер Шәймиевнең төрле елларда «Ватаным Татарстан», «Шәһри Казан» газеталары, «Сөембикә», «Безнең мирас», «Татарстан», «Казан утлары» журналлары, «Интервью без галстука» проектына әңгәмәләрендә әйтелгән фикерләре файдаланылды. Фото: shaimiev.tatarstan.ru)

БЕЗНЕҢ БАБАЙ

Татарстанның Беренче Президенты, Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиевкә 20 гыйнварда 85 яшь тулды. Татарстан халкы, аның белән төрле елларда эшләгән кешеләр, зыялылар үзләренең аңа бәйле истәлекләре белән бүлештеләр.

Фәрит МӨХӘММӘТШИН: «Татарстандагы тотрыклы үсеш, татулык Минтимер Шәймиев исеменә бәйләнгән»

Минтимер Шәрип улы – исеме федераль дәрәҗәдә һәм дөнья масштабында танылган зирәк сәясәтче, көчле шәхес. Миңа күп еллар дәвамында аның белән бергә эшләргә туры килде. Бу вакыт эчендә бик күп гаҗәеп вакыйгалар, бәхәсләр, фикер алышулар булып узды, принципиаль сәяси карарлар кабул ителде. Әлбәттә, алар барысы да Минтимер Шәймиев тарафыннан республикабыз мәнфәгатен кайгыртып эшләнде.

Һичшиксез, Татарстанның алдынгы, тотрыклы үсеше, күпмилләтле һәм төрле диннәр тотучы халкыбызның дус, тату яшәве Минтимер Шәймиев исеменә тыгыз бәйләнгән. Тарихыбыз борылыш кичергән катлаулы елларда ул хокукый һәм демократик тәртип нигезендә, республиканың киләчәген төзү идеясе тирәсендә халыкны берләштерүгә ирешә. Моның өчен никадәр зирәк акыл, җаваплылык һәм сәяси ихтыяр көче кирәк булуын без хәзер генә аңлыйбыз. Аның тарафыннан формалаштырылган «Татарстан моделе» хәзергә кадәр күп кенә илләрнең сәясәтчеләре игътибарын җәлеп итә.

Гаять катлаулы ул чорда республика җитәкчесе урынында башка кешене күз алдына да китереп булмый. Күрәсең, тормыш аны яшь чагында ук төрлечә сынап, аңа хезмәт сөючәнлек, кешелеклелек, сөйләшә һәм килешә белү сәләте биреп, Татарстан җитәкчелеге өчен әзерләгәндер. Минтимер Шәриповичның күп тапкырлар: «Сәясәтчеләр һәм җитәкчеләр, барыннан да элек, җир кешеләре булырга тиеш», – дип әйткәне бар. Ул бит үзе дә – нәкъ шундый, гаҗәеп тормыш мәктәбен узган кеше. Аңарда сәясәтче һәм җәмәгать эшлеклесе өчен иң кыйммәтле сыйфатлар бар: кешеләрнең ышанычы һәм халык теләктәшлеге, хезмәттәшләре алдында абруе һәм оппонентларының ихтирамы.

Сәясәтче буларак Минтимер Шәриповичның уникаль үзенчәлеге – эшлеклелек һәм конструктивлык, төрле-төрле, еш кына капма-каршы фикерләрне килештерә белү. Шул ук вакытта ул принципиаль моментларда тәвәккәл, ныклы һәм эзлекле. Тормыш кредосы турында сөйләгәндә ул юкка гына: «Какшаган нервлар белән хакимияттә йөрмиләр», – димәгәндер.

Дөресен генә әйткәндә, нәкъ менә Минтимер Шәймиев Татарстанда заманча сәясәт мәктәбен булдырды һәм катлаулы чорда барлык дәрәҗәдәге хакимият, предприятиеләр һәм оешмалар җитәкчеләре өчен шул мәктәпнең иң абруйлы беренче укытучысы булды. Яшермим, мин әлегә кадәр күп нәрсәне аңларга һәм кемнедер күндерергә, дөрес карарлар кабул итәргә аңардан өйрәнәм. «Дәлилләрең булмаса, беркайчан да кешеләр янына чыкма, ә аргументларың бар икән, алар тимер булырга тиеш», – дигән сүзләре гомергә истә калган.

Минтимер Шәрип улы башлаган эш-гамәлләрне бүген Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов дәвам иттерә. Һәм бу хәл табигый да, чөнки ул – Шәймиев командасында чыныккан, хакимиятнең барлык баскычларын узган кеше.

Үз халкының лаеклы улы Минтимер Шәймиев хәзер дә туган республикасына тугрылыклы хезмәт итә. Болгар һәм Зөя калаларын яңадан торгызу, Казан соборын төзү, «Адымнар – белем һәм татулыкка юл» полилингваль мәктәпләр челтәрен үстерү – болар барысы да аның тормыш рәвеше, киләчәкне алдан күреп эшләве.

Хөрмәтле Минтимер Шәрип улы! Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары һәм шәхсән үз исемемнән Сезне 85 яшьлек юбилеегыз белән чын күңелдән тәбрик итәм. Һәр яңа көн Сездән көч һәм куәт таләп итә, шуңа күрә сәламәт һәм нык булыгыз! Сезгә игелек һәм иминлек, барлык хыялларыгызның һәм ниятләрегезнең тормышка ашуын телим.

«УЙЛАРЫҢНЫ КҮБРӘК ИҖАТ ЭШЕНӘ БИРЕРГӘ КИРӘК, ДИП КИҢӘШ БИРДЕ»

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА, Татарстан Язучылар берлеге рәисе:

– 1989 елны, язучыларның нәүбәттәге корылтаенда, татар-башкорт мөнәсәбәтләре уңаеннан бәхәсле чыгыш ясадым һәм Айдар Хәлимнең Татарстан җитәкчелегенә ачык хатын укыдым. Ул бик шау-шу куптарды. Чыгышны бүләргә дә теләп, президиумдагылар «тәмамласын» дип шаулашсалар да, регламент кысасыннан да чыгып, ахырына кадәр җиткердем. Тәнәфестә Минтимер ага, ул вакытта әле Министрлар Кабинеты җитәкчесе, тотып алды да, шактый гына үгет-нәсыйхәт укыды. «Син әле яшь, уйламыйча сөйләмә, җиде кат үлчәгәннән соң гына бер кат кисәргә кирәк», – дип, борынгыдан килгән хакыйкатьне искә төшерде. «Син – талантлы егет, шуңа күрә уйларыңны күбрәк иҗат эшенә бирергә кирәк», – дип киңәш бирде. Миңа бу гамәл бик гыйбрәтле тоелды, чөнки Министрлар Кабинеты рәисе әдәбият белән, мәдәният белән кызыксына дип уйламаган идем. Шактый яшь кеше сөйләгәннәрне җанына якын алып киңәш бирүе дә сәер тоелды. Ник дигәндә, без бит югары вазыйфа биләгән кешеләрне әдәбияттан шактый ерак торучы технократ итеп күзалларга өйрәнгән.

Ул театрга еш йөри, премьераларны калдырмый иде. Гадәттә җитәкчеләр концертларга, спорт ярышларына йөри, ләкин театрга килеп, артистларны, язучыларны шәхсән белгән җитәкче – ул, мөгаен, берданбердер. Хәзер дә Минтимер ага әдәби, мәдәни процессларны күзәтеп бара, талантлы яшьләрне белә, укый. «Ватаным Татарстан»ны, гомумән, татар матбугатын укып, таныша, кызыксына. Шалтыратып, бигрәк тә публицистик мәкаләләр уңаеннан, фикерен дә җиткерергә мөмкин. Аның белән бергә-бер очрашкан, өчәр сәгать сөйләшеп утырган чаклар да булды. Аның эрудициясе, белеме шаккатыра. Әдәбият-сәнгать өлкәсендә генә түгел, бөтен өлкәдә хәбәрдар, белемле. Әдәбият-сәнгать белән кызыксынуы, минемчә, балачагыннан киләдер. Ул балачагында ук авыл китапханәсендәге барлык китапны укып чыккан. Олыгайган көнендә дә кызыксыну хисе сүрелмәгән. Ул бер нәрсәгә дә битараф түгел. Димәк, яшәү потенциалы көчле. Болар барысы да балачактан килә. Әйтәләр бит әле, алтыдагы – алтмышта дигән кебек. Тугыздагы да – туксанда! Һәрвакыт заман белән янәшә атлау ул – әлбәттә, олы шәхесләрнең асыл сыйфаты.

«АНЫҢ ЯНЫНА БЕРВАКЫТТА ДА ШӘХСИ ГОЗЕРЕМ БЕЛӘН КЕРГӘНЕМ БУЛМАДЫ»

Рәис СӘЕТОВ, Татарстанның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре:

– Минтимер Шәймиев 1962 елда Минзәләдә «Сельхозтехника» идарәсе башлыгы иде. Без – институт тәмамлап кайткан яшь инженерларны шунда яңа хезмәткә билгеләделәр. Мине 1967 елда, Минтимер Шәймиев тәкъдиме белән, Минзәләнең авыл хуҗалыгы идарәсенә баш инженер итеп күчерделәр. Аннан аны Казанга алдылар. 1972 елда мине Минзәләдә «Сельхозтехника» идарәчесе итеп куйдылар. Бу вазыйфаны тугыз елдан артык алып бардым. Эшләгән чорда, Казанга баргач, аның янына кереп чыкмый калмый идем инде. Ул баштa обкомда, аннан соң мелиорация һәм су хуҗалыгы министры булды. Кайсы гына эшкә алынса да, җентекләп өйрәнеп, тәҗрибәләр үткәрә, яңалык кертә иде. Басуларда сугару өчен «Волжанка», «Фрегат» машиналарын куллану, тагын әллә никадәр яңалыкның башында ул торды. Аннан мине авыл хуҗалыгы идарәсенә күчерделәр, анда инде Минтимер Шәрипович белән тагын да ныграк бәйләнештә эшләдек. Сөйләшеп утырганнан соң һәрвакытта да: «Үзеңнең соравың юкмы?» – ди иде. Мин аның янына гел хөкүмәт эше буенча керә идем, үземнең гозер белән бервакытта да борчыганым булмады. Нәрсә әйтәсем килә: ул бик тәртип ярата торган җитәкче булды. Үзе белән эшләгән кешеләргә һәрвакыт хөрмәт белән карады. Нәрсәнедер эшләп бетермәсәң, җитешсезлегеңне конкрет әйтә иде. Яшь чакта хата сизелми кебек тоела ул, ләкин кемдер ялгышыңны әйтергә тиеш. Үзе дә яңалыкка омтыла, бергә эшләгән кешеләрне дә шуңа этәрә иде. Ә бит ул Минзәләгә килгәндә, «Сельхозтехника» әле оешмаган да була. Шәһәрнең төрле җирләрендә эшләгән оешмаларны, складларны МТСка җыеп, бердәм оешма оештырды. Яшь кешенең төзелеш материалларына да кытлык заманда мондый эшкә алынуы, әйтергә кирәк, зур кыюлык булды. Әйтәсем килгәне шул: аның яшь чакта ук күңелендә төзелеш бар иде, шуңа күрә гомере буе гаме төзүдә булды.

Рухи як турында берничә сүз. Миңа калса, Габдулла Тукайны Минтимер Шәймиевтән дә яхшырак өйрәнгән кеше юктыр ул. Ул шагыйрьнең

«Һич бетәрме тарихи бу бергәлек?
– Без туган бер җеплә теркәлеп», –

дигән шигырь юлларының тарихи мәгънәсен аңлап эш итте, «Китмибез!» дигән шигырен бервакытта да исеннән чыгармады. Милли мәсьәлә – кылдан нечкә мәсьәлә бит ул. Ул исә халыкны да, югарыдагыларны да үзенә ышандыра, артыннан иярте бара торган көчле шәхес булды. Ә театрга мәхәббәт Минзәләдә чакта салынгандыр дип уйлыйм. Минзәлә театрының һәр премьерасына җыелышып бара идек без. Карагач, сез болай, тегеләй, дип әйтми, билгеле бер вакыт узып, фикере туганнан соң гына, җаен туры китереп әйтә иде.

«АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫНА ЯҢАЛЫК КЕРТТЕ»

Зәки ИСЛАМОВ, Татарстанның һәм Россиянең атказанган инженеры:

– Минтимер Шәрипович Казан авыл хуҗалыгы институтын тәмамлап, 1959 елда Мөслим машина-трактор паркына (МТС) инженер булып эшкә кайтты. Ул вакытта мин – «Алга» МТСында склад мөдире. Уку йортын тәмамлап, практикага кайткач, Минтимер Шәймиев мине дүрт колхозга механик итеп билгеләде. Бу вакытта ул районда берданбер югары белемле инженер иде. «Сельхозтехника»да эшләгәндә, үзен чын белгеч итеп күрсәтте. Таләпчән, уйлап табуга сәләтле, алдынгы булды. МТСның фрезер станогы юк. Трактор, машинага кирәк булган шестерняларны шунда ясыйлар. Шул станокны кайтартып, хутка җибәреп, техникаларны кирәк-ярак белән тәэмин итте. Ул елларда районнарга «ДТ-54» дизель тракторлары кайта башлады. Эш өчен кулай, көчле тракторлар булса да, бер кимчелеге бар: рамнары бик тиз какшый иде. Минтимер Шәймиев республикада беренчеләрдән булып, шушы тракторларның рамнарын сүтеп, өр-яңадан торгызуны оештырды. Авыл хуҗалыгы машиналарын энәсеннән җебенә кадәр белә иде. Механизаторлар әзерли торган курс ачты. Дүрт ай эчендә тракторчылар техникага утыра иде.

Кукурузны квадратларда, ягъни оялап утырту модага кергән заманнар бу. Әлеге культураны аркылыга-буйга чәчү кукурузның рәт араларын эшкәртү өчен уңайлы, уңышы да мул була. Тик заводтан кайтартылган чәчкечләр квадратны тыгызлап бетерми. Минтимер Шәрипович чәчкечләрне яңарткач, проблема хәл ителде. Республика буенча да әлеге тәҗрибә киң кулланыла башлады. Моны үзе бер инкыйлаб булды дип әйтергә мөмкин.

Мөслим МТСы районда су башняларын өр-яңадан ясауга ирешә. Колхоз-совхозларда терлекчелекне алга җибәрүдә баш инженерның файдасы зур булды. Терлекчелек торакларын элек читәннән үрелгән иде. Аннан кирпечтән төзи башладылар. Яшь терлекләр торагын җылытырга кирәк. Минтимер Шәрипович ут ягып җылыта торган калорифер уйлап тапты. Мич эчендә ут яга лар да җылынган һаваны терлек торакларына өрдерәләр. Нәтиҗәдә маллар туңмый.

1962 елда Минтимер Шәймиевне Минзәләгә яңа эшкә билгеләделәр. Бергә хезмәт куйган елларны еш искә алам. Аны юбилее белән котлап, балаларының игелеген күреп, республика уңышлары өчен хезмәт куеп, сәламәт булып, озын гомер кичерүен телим.

«ВТ» архивыннан

«КОЛ ШӘРИФ МӘЧЕТЕ АТА-БАБАЛАРЫБЫЗГА ҺӘЙКӘЛ БУЛДЫ»

Әзһәр ШАКИРОВ, Россиянең һәм Татарстанның халык артисты, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты:

– Минтимер Шәймиев дигәч, минем күз алдыма Ирек мәйданы тулы халык килеп баса. Безнең халкыбыз өчен бик хәлиткеч мизгелләр иде ул. Шул чакта Минтимер Шәрипович, без референдум үткәрәбез, чит илләрдән күзәтүчеләр чакырабыз, безне бөтен дөнья таныячак, дип халкыбызга игълан итте. Әлбәттә, бу гамәлгә каршы чыгучылар да, янаулар да, өркетүчеләр дә булды. Без чигенмәдек. Ә шушы гаять авыр, катлаулы чорда чын кеше, татар булып калу – үзе бер батырлык. Әгәр ул шул вакытта халык ышанычын акламаган булса, безнең киләчәгебез билгесез булыр иде.

Тагын бер вакыйга искә төште. Кремль уртасында Кол Шәриф мәчетен ачу тантанасын гомеремдә дә онытасым юк. Миңа калса, бу мәчет 1552 елны Ватан өчен изге сугышта һәлак булган ата-бабаларыбызга мәңгелек һәйкәл булды.

Минтимер Шәрипович кебек әдәбиятны, сәнгатьне аңлаган, хөрмәт иткән җитәкчеләр сирәк була. Ул яктан безгә бәхет елмайды. Театрның һәр яңа спектаклен карап, бәйрәмнәребезгә килеп, туган көннәребез белән котлавын беркайчан да онытасым юк. Әлбәттә, монда мәрхүмә Сәкинә ханымның да өлеше зур. Ул да безнең уңышларыбыз өчен чын күңелдән сөенә иде. Тормышымда шундый кешеләр очравы – үзе бер бәхет!

«ХАЛЫК ХӨРМӘТЕН КАЗАНГАН ШӘХЕС»

Рамил ҖИҺАНШИН, Болгар дәүләт тарихи-архитектура музей-тыюлыгы директоры:

– Ул булмаса, безнең күз алдыбыздагы хәзерге Болгар да булмас иде. Ул – эшсөяр, искиткеч сәясәтче, абруйлы, иң мөһиме – халык хөрмәтен казанган кеше.

Зөя һәм Болгарны торгызуга бәйле эшләр мисалында гына карагыз. Моңа керешкәнче, аңа бит иң элек күңеле белән шушы карарга килергә кирәк булгандыр. Әле бит күңелендә йөрткәнне тиешле кешеләргә җиткерә белү дә мөһим. Аның бу адымы бәяләп бетергесез. Беренче Президентыбыз шундый көчле команда туплый, шулкадәр күп кешеләрне күндерә алды. Тормыш башкача барса, Болгар 2010 елгы хәлендә калган булыр иде. Ул вакытта территориядә бер генә музей иде. Ә хәзер биредә күпме заманча бина, мәдәни мирас саналган күпме корылма бар! Торгызу эшләре генә түгел, бу бит әле – өстәмә эш урыннары, инфраструктура! Хәзер инде аңа һәм аның командасына рәхмәтләр генә әйтеп торасы килә. Бөтен кеше дә Минтимер Шәрипович сыман кешеләре белән мактана алмый, шулай ич? Аның исемен ишетү генә дә миңа шулкадәр энергия бирә. Шәхсән минем өчен бик кадерле һәм хөрмәтле кеше ул. Кем белә бит, Болгарны торгызу эшләре башланганчы, мин дә Казанга китәргә уйлап йөргән идем. Әмма кайда тудың – шунда кирәксең, дигәндәй, үземне биредә таптым. Аңа бу җәһәттән дә рәхмәтле мин.

«УЛ КЕШЕЛӘР БЕЛӘН СӨЙЛӘШҮДӘН КУРЫКМЫЙ»

Артем СИЛКИН, «Зөя утрау-шәһәрчеге» музей-тыюлыгы директоры:

– Югары вазыйфаларны биләгән кайбер кешеләрдә башкаларга карата тәкәббер караш, бүтәннәрне санга сукмау күзәтелә. Минтимер Шәриповичта бу юк. Ул – кешеләр белән сөйләшүдән курыкмый торган, ә ярата торган шәхес. Минтимер Шәрипович белән аралашудан кешеләр дә күп нәрсә ала. Җитәкче кеше буларак, аңа да халык фикерен ишетү ошый. Тыңлый да белә. Команда белән эшләгәндә ул, үз фикерен дәлилләп, аны яклый, алга сөрә, шул ук вакытта башкаларны да ишетә. Башкаларның фикерен колак яныннан гына уздырмый ул.

Аерым алганда, Минтимер Шәриповичның тарихи-мәдәни мирасыбызны торгызу эшенә бәйле эшчәнлеге турында да әйтеп китәргә кирәк. Зөяне торгызу эшләрен генә алыйк. Аңа бәя биреп, бу эштә Минтимер Шәриповичның ролен аңлатып бетерерлек тә түгел. Ул тотынганчы биредәге хәлләрнең нинди булуын, эшләр ничек барганын барыбыз да белеп-күреп тордык бит. Аның ихтыяр көче зур эшне башкарып чыгарга булышты. Аннан башка Зөядәге социаль-икътисади, мәдәни планда берни дә чынга ашмас иде. Хыялда Зөядә бервәр урын, корылмага аның исемен бирү дә бар әле безнең.

Ул эшләр кешеләрнең йөрәгендә, күңелендә, аңында. Ә күңелдәгесе югалмый ул.

«БЕРЕНЧЕ ПРЕЗИДЕНТ ФАТИРЛЫ ИТТЕ»

Лилия ШӘРӘПОВА, Идел буе районының 73 нче мәктәбе татар теле һәм әдәбияты укытучысы:

– 2005 елда Татарстанда бюджет өлкәсендә эшләүчеләр өчен социаль ипотека дигән программа кертелде. Шушы программа нигезендә меңләгән гаилә торак шартларын яхшыртты. Безнең үзебезгә дә шушы программа белән фатир алырга насыйп булды. 2010 елда чиратка басып, озак та көтмичә (3,5 ел ярым), 2014 елда җылы оялы булдык. Шундый матур, якты, уңайлы, җылы фатирлы булуыбызда Татарстан Республикасының Беренче Президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиевнең өлеше бик зур. Әлеге программада катнашып, фатир алу гына түгел, бюджетта эшләп, бәби тудыручыларга ярдәм йөзеннән 200 мең сум акча да күчерелде. Бу яшь гаиләләргә авыр шартларда зур ярдәм булды. Шушы программа буенча яхшы фатир иясе булуга ирешкән меңләгән бюджет хезмәткәрләренең берсе буларак, Минтимер Шәрип улы Шәймиевкә чиксез рәхмәтемне белдерәм.

РӘХМӘТ ИШЕТМӘСКӘ ӘЗЕР БУЛЫРГА, ЛӘКИН ҺӘРВАКЫТ РӘХМӘТ ӘЙТЕРГӘ...

Зилә ВӘЛИЕВА, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе:

– Минтимер Шәрип улы – мәдәният мәсьәләләрендә минем өчен дә, ил һәм дөнья күләмендәге зур шәхесләр өчен дә зур авторитет. «Эрмитаж» директоры, атаклы галим Михаил Пиотровский кебек акыл ияләре, сәнгать йолдызлары безнең Беренче Президентыбыз белән хезмәттәшлек итеп, зур проектларга капка ачтылар. Театр, сынлы сәнгать, рухи тормыш, тарих темалары белән кызыксынуы аңа зур сәясәтчеләр, талантлы шәхесләр белән эш йөртергә ярдәм итте. Нәтиҗәсе Татарстан файдасына булды, әлбәттә.

Сәясәттә вакытында эшләнгән эшнең масштабы үзеннән-үзе арта. Кремльгә кергәч, анда Кол Шәриф мәчете мәңге торган кебек. Әле берничә ел элек кенә ул юк иде. Анысы да Минтимер Шәймиев белән бәйле. Һәйкәлләрне халыкара дәрәҗәгә чыгару, ЮНЕСКОга кертү – бу карап торышка гына җиңел кебек. Чынлыкта ул күпме эш таләп итә.

2008 елда Татарстан Мәдәният министрлыгының коллегия утырышын Болгарда уздырдык. Истәлекле ел иде ул. Болгарда һәйкәлләр корыла, әмма акча юк дип, Хөкүмәт җыелышы җыйган идек. Мин ул вакытта – вице-премьер, мәдәният министры. Премьер-министр Рөстәм Миңнеханов беренче тапкыр Болгарга республика бюджетыннан 13 миллион сум акча бүлеп бирде. Башта бу бик зур сумма кебек күренде. Спас районының ул вакыттагы башлыгы Камил Нугаевның кош тоткан кебек сөенгәнен хәтерлим. Аңа кадәр федераль бюджеттан ел саен 2–3 миллион бирелә иде. Ул бары кайбер объектларның кар-яңгыр астында таркалуын кимету өчен генә җитте.

Боз кузгалу кебек булды бу. Без үзебезне хәллерәк хис иткәч, Болгарда утырыш уздырдык. Музей уртасында, һәйкәлләр арасында махсус чатыр кордык. Җилле көн, чатыр селкенә. Утырыш үткәннән соң, Минтимер Шәрипович, чыгып, җилгә каршы басты да: «Димәк, вакыт җитте» – диде. Соңрак «Яңарыш» фонды эшчәнлеге бу эшнең никадәр зур колачлы икәнлеген күрсәтте.

Ул чорда бик күп эшләр башкарылды. Иң зурысы – бүгенге республиканың яшәеше, минемчә. Үз эшен дәвам иттерердәй шәхесләр тәрбияләде. Гамәлдәге Президент Рөстәм Миңнехановны үстерде, республикада эшли торган команда туплады.

Һәркем Минтимер Шәймиевне үзенчә кабул итә. Күпчелек, хөрмәт итеп, «Бабай» дип атый аны. Ул рәхмәт ишетер өчен эшләмәде. Әмма үзе рәхмәт әйтергә онытмады. Изге эшләр кешенең үзенә әйләнеп кайта ул.

«БЕЗ – АНЫҢ МӘКТӘБЕН ҮТКӘН КЕШЕЛӘР»

Энгель ФӘТТАХОВ, Актаныш районы башлыгы:

– Минтимер Шәрипович – Татарстан өчен генә түгел, татар дөньясы өчен бирелгән шәхес ул. Андыйлар гасырга бер генә туа. Татарстанның, татар халкының шундый дәрәҗәдә булуында да Беренче Президентның роле бик зур. Беренче инкыйлабны 1917 елда кичерсәк, туксанынчы елларда икенчесен кичердек дигән фикердә мин. Шунда Минтимер Шәрипович, бөтен энергиясен биреп, дөрес ориентлашып, Россиянең федератив дәүләт булып сакланып калуына зур өлеш кертте. Зур энергияле, эшлекле, характерлы җитәкче ул. Актаныш халкы аның белән горурлана. Минем өчен исә ул икенче әткәй кебек. Аның мәктәбен үткән кеше бервакытта да начар эшли алмый. Район башлыгы вазыйфасында мин гомер буе «Минтимер Шәриповичны биргән район бер генә өлкәдә дә начар эшләргә тиеш түгел!» дигән девиз белән эшләргә тырыштым. Ул үзе дә туган ягын онытмый. Ел саен кайтып, хәлләрне белешеп китә.

Ул безгә яшәү рәвеше белән дә үрнәк. Ходай аңа исәнлек-саулык бирсен, киләчәктә бергәләп эшләргә язсын. Сүз уңаеннан, ул: «Тән саулыгы белән генә рух ныклыгына ирешеп була», – дип әйтә иде. Спортка мәхәббәтне ул тәрбияләде, дисәк тә була. Мин дә: «Әгәр кеше үзенең сәламәтлеге турында кайгыртмый икән, ул – аның мәгънәсезлеге», – дим. Шуңа күптелле гимназиядә балаларга яхшы белем бирергә, сәламәтлекләрен ныгытырга тырышабыз. Кеше һәрвакыт хәрәкәттә булырга тиеш. Шушы хакыйкатьне киләчәк буынга да тапшырырга телибез.

МИНТИМЕР ШӘЙМИЕВ ТУРЫНДАГЫ ФИКЕРЛӘРНЕ ТУЛЫСЫНЧА VATANTAT.RU САЙТЫННАН УКЫГЫЗ

24 гыйнвар | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «СӨЮЛӘРЕМ СИНЕ ХАК МИНЕМ» 12+
10.00, 23.00 «КОРОЛЕВА ИГРЫ» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «20 МИНУТ» 16+
13.00 «Семь дней» 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
14.45 «Аулак өй» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Акыл баттл» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Әдәби хәзинә» 6+
18.00 «Мин» 12+
19.00, 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
00.00 «Черное озеро». Банда ювелирщиков 16+
00.25 «Башваткыч» 12+
01.10 «Таяну ноктасы» 16+
02.00 «Манзара» 6+
02.50 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ» 12+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара» 6+
07.15, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ» 16+
14.00, 02.00 «Ком сәгате» 12+
15.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
19.10 «Халык җырлары». Зөһрә Сәхәбиева җырлый 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00, 09.25 «Доброе утро»
09.00 Новости
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор» 6+
12.00, 15.00, 18.00 Новости (с субтитрами)
12.15, 17.00, 01.40, 03.05 «Время покажет» 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
18.40 «На самом деле» 16+
19.45 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.30 Премьера. Анна Банщикова. «Ищейка». Новый сезон (S) 16+
23.35 «Познер» 16+
00.40 К 80-летию со дня рождения Валерия Ободзинского. «Вот и свела судьба…» 12+
03.00 Новости

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым» 12+
12.40, 18.40 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.55 «ТАЙНЫ ГОСПОЖИ КИРСАНОВОЙ» 12+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир» 16+
21.20 Русская серия. «СКЛИФОСОВСКИЙ» 16+
23.35 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.20 Вячеслав Разбегаев, Кирилл Плетнёв, Наталия Быстрова, Анна Гарнова, Андрей Арзяев, Дмитрий Ермак. «ПЫЛЬНАЯ РАБОТА» 16+
04.00 Ярослав Бойко, Анатолий Васильев, Раиса Рязанова, Дарья Повереннова, Илья Соколовский. «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.10, 12.30, 15.40, 17.55, 20.55 Новости
06.05, 23.00 Все на Матч! Прямой эфир.
09.15, 12.35 Специальный репортаж 12+
09.35 «ЧЕЛОВЕК ПРЕЗИДЕНТА» 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.55, 02.25 Зимние виды спорта. Обзор 0+
13.30, 15.45 «В СОЗВЕЗДИИ СТРЕЛЬЦА» 12+
18.00 «Громко» Прямой эфир
18.55 Баскетбол. Единая лига ВТБ. ЦСКА – «Калев» (Эстония). Прямая трансляция
21.00 «Я, АЛЕКС КРОСС» 16+
23.30 Тотальный футбол 12+
00.00 «ВОЙНА ЛОГАНА» 16+
01.55 «Человек из футбола» 12+
03.00 Новости 0+
03.05 «Сенна». Док. фильм 16+
05.05 «Громко» 12+

НТВ

04.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня.
08.25, 10.25 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Боевик «НЕВСКИЙ. ТЕНЬ АРХИТЕКТОРА» (S) 16+
23.35 «ЗОЛОТОЙ ЗАПАС» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.40 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.45 «Давай разведёмся!» 16+
09.50 «Тест на отцовство» 16+
12.00 «Понять. Простить» 16+
13.05 «Порча». «Красные слёзы» 16+
13.35 «Знахарка» 16+
14.10 «Верну любимого» 16+
14.45 «ТОТ, КТО РЯДОМ» 16+
19.00 «ТЕНЬ ПРОШЛОГО» 16+
23.00 «ЖЕНСКИЙ ДОКТОР» 16+
01.00 «Верну любимого» 16+
01.30 «Порча» 16+
02.00 «Знахарка» 16+
02.25 «Понять. Простить» 16+
03.15 «Тест на отцовство» 16+
04.55 «По делам несовершеннолетних» 16+
05.45 «Домашняя кухня» 16+
06.10 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА

05.10 «ПРИВЕТ ОТ КАТЮШИ» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 21.15 Новости дня 16+
09.20, 01.40 «ВПЕРВЫЕ ЗАМУЖЕМ» 12+
11.20, 21.25 «Открытый эфир» 12+
13.25 «Оружие Победы». Док. сериал 12+
13.40, 14.05, 03.55 «КРАСНЫЕ ГОРЫ» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.30 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Без права на ошибку. История и вооружение инженерных войск». Док. сериал 16+
19.40 «Скрытые угрозы» с Николаем Чиндяйкиным. «Альманах №88» 16+
20.25 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Док. сериал. «Тайна гибели главы МВД СССР Бориса Пуго и его жены». Премьера! 12+
23.05 «Между тем» 12+
23.40 «ГЕНЕРАЛ» 12+
03.15 «Высоцкий. Песни о войне» 6+

25 гыйнвар | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «СӨЮЛӘРЕМ СИНЕ ХАК МИНЕМ» 12+
10.00, 23.00 «КОРОЛЕВА ИГРЫ» 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
11.15 «Память сердца» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «20 МИНУТ» 16+
13.00 «Оныта алмыйм…» 0+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 « Не от мира сего…» 12+
14.45 «Аулак өй» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Уймак» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Ватандашлар» 12+
18.00 «Казаннан – казанга» 12+
19.00, 01.30 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Чёрное озеро» 16+
00.00 «Видеоспорт» 12+
00.25 «Соотечественники». У истоков жизни. В.С.Груздев 12+
00.50 «Черное озеро». Охотники за квартирами 16+
01.15 «Реквизиты былой суеты» 12+
02.00 «Манзара» 6+
02.50 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ» 12+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
04.45 « Ком сәгате » 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара» 6+
07.15, 19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40, 16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ» 16+
14.00, 02.00 «Ком сәгате» 12+
15.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
16.30 «Тамчы-шоу» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+

1 КАНАЛ

05.00, 09.25 Телеканал «Доброе утро
09.00 Новости
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор» 6+
12.00, 15.00, 18.00 Новости (с субтитрами)
12.15, 17.00, 01.25, 03.05 «Время покажет» 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
18.40 «На самом деле» 16+
19.45 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.30 «ИЩЕЙКА». Новый сезон (S) 16+
22.35 Премьера сезона. «Док-ток» 16+
23.30 «Вечерний Ургант». Лучшее (S) 16+
00.20 Ко дню рождения Владимира Высоцкого. «Я не верю судьбе…» 16+
03.00 Новости

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «Судьба человека» 12+
12.40, 18.40 «60 минут». Ток-шоу. 12+
14.55 «ТАЙНЫ ГОСПОЖИ КИРСАНОВОЙ» 12+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир» 16+
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ» 16+
23.35 «Вечер» 12+
02.20 «ПЫЛЬНАЯ РАБОТА» 16+
04.00 «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.10, 12.30, 15.40, 17.55, 21.10 Новости.
06.05, 18.55, 22.00, 00.45 Все на Матч! Прямой эфир.
09.15, 12.35 Спец. репортаж 12+
09.35 «ЧЕЛОВЕК ПРЕЗИДЕНТА: ЛИНИЯ НА ПЕСКЕ» 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.55 «МатчБол»
13.30, 15.45 «В СОЗВЕЗДИИ СТРЕЛЬЦА» 12+
18.00 Профессиональный бокс. Н. Иноуэ – М. Дасмаринас. Бой за титул чемпиона мира по версиям WBA и IBF. Трансляция из США 16+
18.25 Профессиональный бокс. Н. Убаали – Н. Донэйр. Бой за титул чемпиона мира по версии WBC. Трансляция из США 16+
19.25 Мини-футбол. Чемпионат Европы. Россия – Хорватия. Прямая трансляция из Нидерландов
21.15 Смешанные единоборства. UFC. Ф. Нганну – С. Ган. Трансляция из США 16+
22.40 Баскетбол. Евролига. Мужчины. «Реал» (Испания) – УНИКС (Россия). Прямая трансляция
01.30 «Голевая неделя» 0+
02.00 «Фристайл. Футбольные безумцы» 12+
03.00 Новости 0+
03.05 Волейбол. Лига чемпионов. Мужчины. «Зенит» (Санкт-Петербург, Россия) – «Войводина» (Сербия) 0+
05.00 «Когда папа тренер» 12+

НТВ

04.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня
08.25, 10.25 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Боевик «НЕВСКИЙ. ТЕНЬ АРХИТЕКТОРА» (S) 16+
23.35 «ЗОЛОТОЙ ЗАПАС» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.55 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.00 «Давай разведёмся!» 16+
10.05 «Тест на отцовство» 16+
12.15 «Понять. Простить» 16+
13.20 «Порча». «Хранитель» 16+
13.50 «Знахарка» 16+
14.25 «Верну любимого» 16+
15.00 «КЛЕВЕР ЖЕЛАНИЙ» 16+
19.00 «МОЙ МИЛЫЙ НАЙДЁНЫШ» 16+
23.30 «ЖЕНСКИЙ ДОКТОР» 16+
01.30 «Верну любимого» 16+
02.00 «Порча» 16+
02.30 «Знахарка» 16+
02.55 «Понять. Простить» 16+
03.45 «Тест на отцовство» 16+
05.25 «По делам несовершеннолетних» 16+
06.15 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА

05.25 «КРАСНЫЕ ГОРЫ» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 21.15 Новости дня 16+
09.20, 18.30 «Спец. репортаж» 16+
09.40 «ВЕРТИКАЛЬ» 12+
11.20, 21.25 «Открытый эфир». Ток-шоу 12+
13.25 «Оружие Победы» 12+
13.40, 14.05, 03.55 «КРАСНЫЕ ГОРЫ» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.50 «Без права на ошибку. История и вооружение инженерных войск». Док. сериал 16+
19.40 «Легенды армии» с Александром Маршалом. Гавриил Половченя 12+
20.25 «Улика из прошлого» 16+
23.05 «Между тем» 12+
23.40 «В ДВУХ ШАГАХ ОТ «РАЯ» 12+
01.25 «ССОРА В ЛУКАШАХ» 12+
02.55 «Легендарные самолеты». «ТУ-95. Стратегический бомбардировщик» 16+
03.35 «Москва фронту» 16+

ЙОЛДЫЗНАМӘ 24 – 30 ГЫЙНВАР

КУЧКАР (21.03 – 20.04)
Бу чорда очрашу-танышулар, һичшиксез, дәвамлы булыр. Романтик хисләргә дә урын калыр. Гомумән алганда, уңышлы, акчалы, файдалы, сөенечле һәм кызык атна.

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05)
Карьера баскычыннан менеп китү өчен бик уңайлы вакыт. Җитәкчегез алдында үзегезне күрсәтергә әзер булыгыз! Атна ахырында гаиләгезгә күңелле хәбәрләр килеп ирешүен көтегез.

ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06)
Көч-куәтегез, тфү-тфү, моңарчы күрелмәгәнчә, ташып торачак. Аны дөрес юнәлешкә борып җибәрәсе генә! Ләкин шуны истә торыгыз: бу чорда килеп чыккан тынгысызлык, ризасызлыкның кайтавазы озак барырга мөмкин. Шуңа күрә сүз-гамәлләрдә бик-бик сак булыгыз.

КЫСЛА (22.06 – 22.07)
Тыйнаклыкны онытып, тирәгездәгеләргә үзегезнең көчле якларыгызны күрсәтегез әле. Барысы да таң калып, сезнең турында бөтенләй башкача уйлый башлаячак. Атна ахырында акча мәсьәләсенә бәйле әйбәт хәбәрләр ишетеләчәк.

АРЫСЛАН (23.07 – 23.08)
Бумеранг кагыйдәсе шәп эшләячәк: ашка – аш, ташка – таш! Хафаланмагыз: күбрәк «аш»лы булачаксыз. Атна ахырында эштәге бер мәсьәләдә шикләнү, эчке курку хисе барлыкка килергә мөмкин. Юкка гына…

КЫЗ (24.08 – 22.09)
Кәефегез шәптән түгелме? Ясалма рәвештә булса да күтәренкелек булдырырга тырышыгыз. Юкса кемнәрнедер сөендерәчәксез. Ял көннәрендә күңелегезгә сары май булып ятардай хәбәрләр ишетерсез.

ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10)
Мөһим эшләрегезне менә хәзер тәмамлап куярга тырышыгыз. Кичектерсәгез, бик күп мәшәкать китерәчәк алар. Тәмле телле булуыгыз хезмәт урынында кыен хәлдән җиңүче кебек чыгарга ярдәм итәр.

ЧАЯН (24.10 – 22.11)
Атнаның беренче яртысында эшлекле бер тәкъдим ишетерсез. Аның турында кат-кат уйланулардан соң бик дөрес карарга килерсез. Керемнәрнең артуын көтегез.

УКЧЫ (23.11 – 21.12)
Көнкүрештә борчыган проблемаларның очына чыгып сөенерсез. Матди хәлегезнең бермә-бер яхшыруына өмет-ышанычлар барлыкка килүен көтегез. Җитәкчегезгә чын сәләтегезне күрсәтергә җай чыгачак. Бу хәл вазыйфагызның үзгәрүенә китерәчәк.

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01)
Тәвәккәллек, кыюлык кирәк хәзер. Тегеләй яки болай кагылсалар, сүз әйтүдән куркып калмагыз. Аны сез бер, әмма берәгәйле итеп әйтәчәксез. Атна ахырында дустыгыз күңел кылларын тибрәтеп җибәрердәй яңалыклар җиткерер.

СУКОЯР (21.01 – 19.02)
Шәхси тормышыгыз турында ачылып сөйли күрмәгез. Юкса хезмәттәшләрегез алдында абруегыз төшәргә мөмкин. Эш урынында үсү мөмкинлеге пәйда булырга торганда, һәрбер сүзне бик үлчәп сөйләргә кирәк.

БАЛЫК (20.02 – 20.03)
Планнарыгыз барып чыкмас, тырышулар файдасыз кебек тоелыр. Ләкин сез дөрес уйламыйсыз! Барысы да көтелгәннән дә яхшырак килеп чыгар. Сабырсызланмаска, ашык-пошык карарга килеп ялгышмаска гына кирәк.

Белдерү

ИЗВЕЩЕНИЕ О ПРОВЕДЕНИИ СОБРАНИЯ ПО СОГЛАСОВАНИЮ МЕСТОПОЛОЖЕНИЯ ГРАНИЦ ЗЕМЕЛЬНОГО УЧАСТКА

Кадастровым инженером Галимзяновым Ф.М., являющимся членом саморегулируемой организации «Ассоциация кадастровых инженеров Поволжья» (уникальный реестровый номер 1413, номер в реестровой записи 30841 от 16.12.2016 г., 420101, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Мавлютова, 31А, офис 2-5, sinaf@mail.ru, (843) 514-63-63, № квалификационного аттестата 16-14-697 от 20.05.2014 г., СНИЛС 106-073-122 06) в отношении земельного участка с кадастровым номером 16:20:090101:38, расположенного по адресу: Республика Татарстан, Зеленодольский муниципальный район, Новопольское сельское поселение, п. Новопольский, ул. Свободы, д 77 проводятся работы по уточнению местоположения границы и (или) площади земельного участка.

Заказчиком кадастровых работ является Краснов Владимир Петрович, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Мавлютова, 31А, офис 2-5, тел.: 89030618183.

Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования местоположения границ состоится 24 февраля 2022 г. в 10 часов 00 минут по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Мавлютова, 31А, офис 2-5, тел.: 514-63-63.

С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Мавлютова, 31А, офис 2-5, тел.: 514-63-63.

Обоснованные возражения относительно местоположения границ, содержащихся в проекте межевого плана, и требования о проведении согласования местоположения границ земельного участка на местности принимаются с 9.00 до 17.00 ч. по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Мавлютова, 31А, офис 2-5, тел.: 514-63-63 с 24.01.2022 г. по 24.02.2022 г.

Смежные земельные участки, с правообладателями которых требуется согласовать местоположение границ земельных участков с кадастровыми номерами:

16:20:090101:37, расположенный по адресу: Республика Татарстан, Зеленодольский муниципальный район, Новопольское сельское поселение, п. Новопольский, ул. Свободы, д. 78;

16:20:090101:41, расположенный по адресу: Республика Татарстан, Зеленодольский муниципальный район, Новопольское сельское поселение, п. Новопольский, ул. Свободы, д. 76;

16:20:090101:40, расположенный по адресу: Республика Татарстан, Зеленодольский муниципальный район, п. Новопольский, ул. Свободы, дом 79а.

16:20:090101:192, расположенный по адресу: Российская Федерация, Республика Татарстан, Зеленодольский муниципальный район, п. Новопольский, ул. Свободы, з/у 79Б.

При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, нотариально заверенную доверенность на предоставление интересов юр. лица, а также документы, подтверждающие права на соответствующий земельный участок (часть 12 статьи 39, часть 2 статьи 40 Федерального закона от 24 июля 2007 года N 221-ФЗ «О кадастровой деятельности»).

БАШ АВЫРТУ ЧИР ТУРЫНДА КИСӘТӘ

Бүген Җир йөзендәге һәр биш кешенең берсе баш авыртудан интегә. Кан басымы күтәрелсә дә, һава торышы үзгәрсә дә, баш авыртудан зарланабыз. Аннан дару эчмичә генә котылып буламы? Баш авырту нинди авырулар турында кисәтә?

Табиб-невролог, реабилитолог, медицина фәннәре кандидаты Диләрә ШАҺИЕВА шул сорауларга ачыклык кертте.

:: Диләрә Рәхимовна, баш авырту нинди чирләр турында кисәтә ала?

– Баш авырту еш кына инсультның беренче билгесе булып тора. Андый чакта, гадәттә, пульс сыман баш авыртуы борчый. Аневризма (кан тамырлары стенасы бүртү) кебек куркыныч чир дә баш авырту рәвешендә уза. Организмда кан әйләнеше бозылганда да кеше баш авыртудан интегә. Баш авырту яман шеш билгесе дә булырга мөмкин. Шеш булса, ул баш миенә басым ясый. Шуңа күрә, әйткәнемчә, баш авыртуга җиңел карарга ярамый.

:: Баш авырту нәрсә ашавыбызга да бәйлеме?

– Әйе, шоколад, кәһвә, чикләвек, кызыл шәраб баш авыртуга китерә ала.

:: Гадәти баш авырту коронавирус, мигрень вакытында күзәтелгән баш авыртудан нәрсәсе белән аерыла?

– Коронавирус кешенең иң зәгыйфь, авырткан җиренә бәрә. Шуңа күрә электән баш авырту, кан басымы югары булудан интеккән кеше еш кына коронавирус вакытында да баш авыртудан зарлана. Коронавирус вакытында баш төрле җирдән – берәүләрнең чигәдән, икенчеләрнең баш артыннан авырта. Пульс типкән сыман авырту да борчырга мөмкин. Төрле кешедә төрлечә, кыскасы. Аннары коронавирус вакытында баш бик нык һәм озак авырта. Чагыштыру өчен: гадәти баш авырту дәрәҗәсе 3–4 балл белән бәяләнсә, ковид вакытында ул 7–8 баллга җитә. Коронавирус белән авыручылар арасында баш авырту аркасында икенче якка борылып ята алмыйча тилмерүчеләр дә булды. Мигрень вакытында баш бер яктан гына авырта. Моннан тыш кеше төрле ис, тавыш, яктылыкка да сизгер була башлый.

:: Баш авыртудан дару эчмичә, өй шартларында гына котылып буламы?

– Дару эчмичә генә котылып буладыр дип уйламыйм. Дару эчкән очракта да авыртуны вакытлыча басып кына торырга мөмкин. Аның көче беткәч, авырту яңадан борчый башлый. Баш авырту безне организмда бар да тәртиптә булмау турында кисәтә. Шуңа күрә вакытында табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Баш пульс рәвешендә авыртса, аеруча игътибарлы булу сорала.

:: Махсус күнегүләр, гимнастика ярдәм итә аламы?

– Баш авырту төрле кешедә төрлечә уза. Сәбәпләре дә төрле булырга мөмкин. Шуңа күрә аны ниндидер махсус күнегүләр ярдәмендә җиңәргә маташу – зур хата. Аеруча интернетта өйрәтелгән теләсә нинди күнегүләр хәтәр. Баш бик нык авыртканда шул борчыган җирне бераз массажлап алуның гына зыяны юк.

:: Баланың ничә яшьләрдә беренче тапкыр башы авыртырга мөмкин?

– Зурлар гына түгел, яңа туган бала да баш авыртудан тилмерә ала. Андый сабый начар йоклый, башын артка җибәрә, тынгысызлана. Нарасыйның баш авыртуы туганда имгәнүгә дә бәйле булырга мөмкин. Шуңа күрә алда телгә алынган үзгәрешләрнең берсе генә күзгә ташланса да, баланы педиатрга, остеопатка күрсәтергә кирәк.

:: Даими рәвештә баш авыртудан интеккән кешенең хәтере начарлана, диләр. Бу сүзләр дөреслеккә туры киләме?

– Кан басымы уйнаган кешеләр баш авыртудан аеруча еш интегә. Андый чакта кан тамырлары киеренке хәлдә эшләргә мәҗбүр. Кан басымы бер төшү, бер менү аркасында баш миендә хәтергә тискәре йогынты ясаучы урыннар пәйда була. Холестерин арту сәбәпле, кан әйләнеше бозылган кешеләрнең дә хәтере начарлана. Шуңа күрә вакытында табибка күренеп торырга кирәк.

ӨЯНӘКНЕ КИСӘТҮ ӨЧЕН ФАЙДАЛЫ КИҢӘШЛӘР

1. Иң беренче чиратта, вакытында йокларга ятып, вакытында торырга кирәк.
2. Шоколад, кәһвә, чикләвек, кызыл шәраб кебек продуктлардан баш тарту хәерле.
3. Көн дәвамында утырып эшләүчеләргә дөрес итеп утырырга кирәк. Арка – туры, компьютер мониторы күз биеклегендә булырга тиеш. Аяклар 90 градуска бөгелгән, куллар өстәлдә булса, яхшы.
4. Баш авыртмасын, дисәң, аякны аяк өстенә куеп утырырга да киңәш ителми. Бер сәгать утыргач, гәүдәне яздырып, йөреп килергә дә онытмагыз.
5. Бүлмәне даими рәвештә җилләтеп торуның да файдасы зур.

Абау!

Тел чиреңне «сатар»

Табибка баргач, телне күрсәтү – гадәти хәл. Белгеч диагноз куюны иң элек әнә шуннан башлый. Баксаң, телнең торышы буенча бер генә түгел, 14 төрле чирнең барлыгын ачыклап була икән. Күптән түгел Пакьстанның Роджалакшм көллияте белгечләре шундый нәтиҗәгә килгән. Моннан тыш табибләр телнең күп кенә башка билгеләренә дә игътибар итәргә чакыра.

Кайсы нәрсә өчен җаваплы?

✓ **Тел очы** – йөрәк һәм үпкәне, аның урта өлеше – ашказаны, бавыр, үт куыгы эшчәнлеген контрольдә тота. Тел тамыры – эчәклек, аның ян-яклары исә бөернең торышы турында сөйли. Сәламәт кешенең теле, гадәттә, эренле катламсыз, ачык алсу төстә була.

✓ **Тел төсе.** Агарып торган тел – организмның хәлсезләнүе, кызыл төстә булса – йөрәк, үпкәдәге хилафлыклар, кан авырулары барлыгы турында сөйли. Тел караңгы төстә булса, хәл тагын да мөшкелрәк дигән сүз. Ялтырап торган шома тел исә – анемия, шәмәхә тел – куркыныч стадиягә җиткән кан һәм үпкә авырулары барлыгын, зәңгәр тел йөрәккан тамыры системасында, бөерләрдә авыру барлыгы турында кисәтә. ВИЧ йоктырган яки бик озак антибиотиклар эчкән кешенең теле исә карала.

✓ **Эренле катлам.** Тел өстендә шундый үзгәреш күзәтелсә, организмга колак салыр чак җиткән дигән сүз. Ул сары төстә булса, ашкайнату системасында, бавырда үзгәрешләр булырга мөмкин. Ак төстәге катлам исә – эч кату, коңгырт төстәгесе сулыш һәм ашкайнату системасындагы хилафлыклар турында кисәтә. Бу катлам телнең үзәгендә урнашса, табиб эчәклек һәм бөерләрне тикшерттерергә мөмкин.

✓ **Тәм сизмәү.** Кеше баллы, ачы, төче һәм тозлы тәмнәрне сизми башласа, кичекмәстән нерв, эндокрин системаларын тикшертергә кирәк.

✓ **Төер, сызык, сикәлтәләр...** Телдәге төерләр – организмга B_{12} витамины, тимер җитмәү, юл-юл сызыклар – сифилис барлыгы, сикәлтәләр – кешедә Крон авыруы яки юан эчәкнең ялкынсынуы турында сөйли.

Киңәш-табыш

Үкчә ярылып интектерсә...

ПАРАФИН. Үкчәсе ярылудан интегүчеләргә йоклар алдыннан тигез күләмдә парафин, салицил кислотасы һәм балавыз алып, шуны «су мунчасы»нда тотып, җылы килеш үкчәгә сөртергә киңәш ителә. Бер каты кипкәч, икенче һәм өченче кат итеп сөртергә кирәк. Аннары аякны бинт белән урап ятып, иртән аякны сабынлы-содалы җылы су белән юарга, үкчәне чистарткыч таш белән ышкырга кирәк.

СОДАЛЫ СУ. Аның өчен табакка ярты стакан вакланган сабын һәм шуның кадәр үк чәй содасы алып, өстенә кайнар су салабыз. Анда аякларны 10 минут чамасы тотасы.

СУГАН. Бер баш суганны урталай бүлеп, бер-ике кат кайнар су белән пешекләп алабыз да, шуны үкчәгә бәйләп, йокларга ятабыз. Иртән үкчәне чистарткыч таш белән ышкып юабыз. Соңыннан майлы крем сөртәбез.

ҮЛӘН СУЫ. Бу катнашманы ясау өчен имән кайрысы, ромашка, сары мәтрүшкә белән тырнак гөл кирәк булачак. Аларның һәркайсын берәр аш кашыгы күләмендә алып, өстенә бер литр кайнар су салырга кирәк. Әлеге катнашманы көн буе төнәткәч, кичен сөзеп, кайнар су белән кушасы.

АЛМА. 2 алма уып, шуңа 200 г сөт, 1 бал кашыгы чәй содасы кушып болгатабыз да калын итеп үкчәгә сөртәбез. Өстеннән бинт һәм полиэтилен пакет белән урап, ярты сәгать тотабыз.

Үзем сынадым

ПАНКРЕАТИТТАН КОТКАРДЫ

Ашказаны асты бизе ялкынсынуыннан үземә булышкан ысулны сезгә дә өйрәтим әле. Иң элек 2 кишер, 3 бәрәңгене яхшылап юып, согын сыгарга кирәк. Шуннан 1 стакан чамасы сок чыга. Аны ашарга ярты сәгать кала эчәргә кирәк. Шуны бер ай дәвамында бер атна эчкәннән соң бер атна ял итеп эчәргә кирәк. Файдасы шундук сизелә.

Фирая ЗАКИРОВА. Питрәч

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

Белеп тор!

Кышын су коенсагыз

Кыш көне су коенучылар елдан-ел күбәя хәзер. Сәламәтлекне кайгырту, иммунитетның вируслларга каршы торуын көчәйтергә теләү аларны шулай бозлы су тарафларына этәрә. «Морж»лар әйтүенчә, кышын су керү тәнне генә түгел, җанны да чыныктыра, күңелгә тынычлык индерә.

Әлбәттә инде, кышын су коенуның үз кагыйдәләре, үз тәртибе бар. Табиб-диетолог Елена Соломатина әйтүенчә, суга керер алдыннан майлы ит ризыклары ашарга ярамый. Ник дигәндә, салкын суда коену – организм өчен зур стресс. Аңа энергия кирәк, ә майлы ризык ашаганда, организм бөтен көчен шуны эшкәртүгә тотачак. Шуңа күрә коеныр алдыннан җиңел эшкәртелә торган ризык – яшелчә белән йомырка тәбәсе, җиңелчә гарнир белән куркә яки тавык ите, ботка ашап алудан да яхшысы юк. Шулай ук диңгез балыгы да әйбәт. Андагы май кислотасы – омега-3 организмны җылытып җибәрә, көч өсти.

«Туганайлар» газетасы хезмәткәре – кышын Казанның Зәңгәр күлендә су коенырга яратучы ***Олеся ДМИТРИЕВА*** *киңәшләре*

◆*Коену алдыннан җылынып алыгыз: зарядка ясагыз, йөгереп килегез. Елгага ашыкмыйча гына төшегез.*

◆*Башны юешләтмәскә тырышып йөзегез. Коену вакытын ике-өч минуттан арттырмагыз (бик чыныккан кешеләр генә суда озаграк йөзә ала). Судан чыккач, сөлге белән тиз-тиз ышкып, тәнне җылытыгыз һәм коры кием киегез. Шуннан соң кайнар чәй эчегез.*

ИГЪТИБАР! Йөрәк-кан тамырлары, эндокрин системасы, сулыш юлы, ашказаны-эчәк, җенес системасы авыруларыннан интегүчеләргә кышын суда коену киңәш ителми.

ИТЕ БАРМЫ?

Илдар Мөхәммәтҗанов

Сосиска – алдый торган тәмле ризык. Тик менә тәме һәм тышкы кыяфәте буенча гына әчендә ниләр барлыгын һич белеп булмый аның. Фаршын бик нык ваклыйлар һәм матуррак күренсен өчен буяуны да кызганмыйлар. Кайбер җитештерүчеләр, табыш артыннан куып, сосисканы иттән түгел, ә үсемлек җепселләреннән, пальма мае, ясалма аксым һәм хәтта кәгазьдән ясыйлар, дип ишетергә туры килә кайчак. Чыннан да, шулаймы икән бу?

Әлеге сорауга җавапны «Татарстан Республикасында Гигиена һәм эпидемиология үзәге»нең туклану гигиенасы, балалар һәм үсмерләр гигиенасы бүлеге мөдире **Ринат Әсгат улы МУСИН** беләнн бергәләп табарга тырыштык.

ГОСТ

Дәүләт стандарты буенча җитештерелә торган сосискаларның кимендә 60 проценты иттән торырга тиеш. Һәр сортка билгеле бер процентта субпродуктлар (май, кан, ит калдыклары), йомырка, сөт, крахмал, он, тоз, тәмләткечләр, натрий глутаматы, шулай ук натрий нитриты (азык буявы һәм консервант) кушыла. Сосиска составында шулардан башка берни булмаска тиеш.

ТУ таләпләре

Җитештерүче сосисканы, организмга зыян салмый торган компонентлар кулланып, үз рецепты (ТУ – техник шартлар) буенча гына да җитештерергә мөмкин. Әмма ул аларның барысын да составында күрсәтергә тиеш. Кайберәүләр, продукция ТУ буенча эшләнгән икән, димәк, начар дип уйлый. Әмма, Ринат Әсгат улы әйтүенчә, дөрес фикер түгел бу. Техник шартлар буенча җитештерүче ризык составындагы ингредиентларның нисбәтен үзенчә үзгәртергә, гадәти булмаганнарын – сыр, яшел тәмләткечләр, гөмбә кертергә мөмкин. Бары шул гына.

Ким булмасын

Ринат Мусин сүзләренә караганда, сосискаларны лаборатория шартларында тикшергәндә, чыннан да, кайвакыт составында күрсәтелгәннәрнең чынбарлыкка туры килеп бетмәве ачыклана. Әйтик, май, крахмал, сыер ите урынына – тавык ите, сеңер, кимерчәк, соя һәм каррагинан ише куерткычларның тиешле нормадан күбрәк булуы ачыклана. Шулай булуга карамастан, ризык гадәттә иминлек таләпләренә туры килә һәм анда ит өлеше 50 проценттан ким булмый. Шуңа күрә, сосиска составында ит юк, дигән фикер дөрес түгел.

СЫЙФАТЛЫСЫН СЫЙФАТСЫЗЫННАН НИЧЕК АЕРЫРГА?

✸Әйбәт сосиска бәясе итнекеннән ким булмаска тиеш, бу продуктның үзкыйммәтенә бәйле. Шуңа күрә арзанлысына кызыкмаска кирәк.

✸Җете алсу яки җете кызыл төстәгесен алмаска тырышыгыз, чөнки мондыена буяу күп кушылган була. Иң әйбәте – пешкән иттән аз гына кызгылтрак төстәгесе.

✸Сосискага бармак белән басып карагыз. Ул тыгыз булырга, бармакны алгач, эзе шундук юкка чыгарга тиеш.

✸Пешергәндә, әйбәт сосиска таркалмый, суы алсу төскә керми яки болганмый.

СУЫКТА КҮП ЙОМЫРКА САЛСЫН, ДИСӘҢ

Кышын тавыкларга җылыта торган азык ашатырга кирәклеге кошкорт асраучыларның һәркайсына мәгълүм. Моның өчен кошларны күбрәк болгаткан азык белән тукландырырга кирәк. Түбәндәге рецепт тавык асраучыларга файдага булыр.

Азыкның 50 проценты – пешерелгәннән соң ваклап туралган яшелчә (кишер, бәрәңге, чөгендер, кәбестә, топинамбур);

● 10–15 проценты – үрдерелгән бөртек (арпа, солы, бодай);

● 10–15 проценты – гадәти бөртек (арпа, бодай);

● 10–15 проценты – бодай көрпәсе;

● 5–10 проценты – вакланган кукуруз.

Моннан тыш азыкка 20 грамм чамасы сөяк оны, балык мае (бер тавыкка 1 грамм исәбеннән) өстәргә мөмкин.

Болар барысы да бик туклыклы, кошкорт организмында озак эшкәртелә һәм аңа энергия, җылылык бирә.

Кирәгә чыгар

БАТАРЕЯНЫ НИЧЕК ЮАРГА?

Өй җыештырганда, хуҗабикә өчен иң кыены – җылылык батареясын юу. Аны тузан суырткыч белән генә һич чистартып бетерә торган түгел. Аны чистартуның бер исулын тәкъдим итәбез. Иң элек стенага су чәчрәмәсен өчен, батарея артына, бер ягын тәрәзә төбенә скотч белән ябыштырып, зур чүпрәк элеп куябыз. Батарея астына поднос урнаштырабыз. Шуннан бөркегечле савытка порошоклы су тутырабыз да җылыткыч батареясының, барлык почмак-ярыкларына шуны бөркибез. Бөтен пычрак су подноска агып төшәчәк һәм батарея чистарып, тирәсендәге һава сафланып калачак.

Крахмалның 7 сере

Хуҗабикәләр крахмалны гадәттә җимеш суыннан кесәл әзерләүдә куллана. Аны тагын нинди очракларда эшкә җигәргә була соң?

1 Төче камыр өчен онның чама белән 10 процентын крахмалга алыштырганда, ризык иректкеч тәмле булып, күпереп пешә һәм озаграк саклана.

2 Крахмал коймак камырына да бик килешә: кырыйлары челтәрләнеп торган юка гына коймак килеп чыга.

3 Торт өчен кремны крахмал белән (куку-рузныкы яхшырак) куертып җибәрергә була.

4 Кайнатма, эремчек, җиләктән торган сыек бәлеш әчлегенә дә, агып чыкмасын өчен, крахмал өстәргә мөмкин.

5 Кисәкләп кыздыру өчен, итне тәмләткечләр (бераз тоз, борыч, дарчин h.б.) өстәлгән крахмалга салып әвәләгәндә, эче сусыл, йомшак булып пешә, ә юка гына тышы алсуланып, кетердәп тора.

6 Ит подливасы яки соусына берничә кашык крахмал өстәп җибәрсәң, куерып китәчәк, тәмле дә булачак.

7 Кәтлит ясаганда, йомырка урынына крахмал кулланырга мөмкин. 2 аш кашыгы крахмал 1 йомырканы алыштыра.

Аш-су

Советча бавырсак

Бакчачы-блогер Эльмира ИСХАКОВА рецепты

«Бакчада эшләр башланганчы, «тәмлүшкә»ләр белән сыйланып калыйк әле. Бу бавырсак рецепты – СССР заманыннан. Хәтерләмәсәгез, рецептын язам, рәхәтләнеп пешерегез», – дип язган ул «Инстаграм»дагы аккаунтында.

Кирәк булачак: 400 грамм эремчек, 3 кашык куерак каймак, 3 йомырка, 1 стакан шикәр комы, ярты чәй кашыгы тоз, 1 чәй кашыгы сода (он белән бергә салырга) һәм он.

Шушы ингредиентларны бергә кушып, камыр басабыз. 1 см калынлыкта җәябез. Ромб рәвешендә кисеп, майда пешерәбез. Майга салгач, күпереп китә һәм бик тәмле булып пешә.

Валентина СЕМЕНОВА әзерләде

БУРЫЧЫҢ ДА, РӘНҖЕТКӘН КЕШЕҢ ДӘ КАЛМАСЫН

Якты дөньяга килгәнсең икән, беркөн аннан китәр чак та җитәчәк. Һичшиксез, Үлем фәрештәсе һәммәбез артыннан да киләчәк. Күпчелек, сау-сәламәт чакта, әлбәттә, кайчандыр мәңгелеккә күзләрен йомасы турында уйлап та бирми. Үлем белән күзгә-күз очрашканчы, аңа әзерләнү кирәкме? Мәет озату тәртибе нидән гыйбарәт? Бу дөньядан киткәннәрне ничек искә алырга?

Саба районы имам-мөхтәсибенең яшьләр белән эшләү буенча ярдәмчесе, Сатыш авылы имам-хатыйбы Алмаз хәзрәт ГАЛИМҖАНОВ белән шул хакта сөйләштек.

:: Хәзрәт, дөнья шулай корылган инде: үлем сәгате кайчан сугасын берәү дә белми. Кинәт үлеп китүчеләр дә бихисап. Үлемеңә ничек әзерләнергә? Әйтик, алдан зиратта җир алу, кәфенне әзерләп кую дөресме?

– Бисмилләһир-рахманир-рахим. Аллаһы Тәгаләнең әмере кайчан җитәсен белеп булмый. Аның рәхмәте белән һәр нәрсәнең башы һәм азагы бар. Шуңа күрә, үлемгә әзерлек дигәндә, иң элек кәфен, зираттан җир сатып алуны гына күздә тотмыйбыз. Иң беренче чиратта кеше Аллаһы Тәгалә белән мөнәсәбәтләрен яхшыртсын иде. Әйтик, күп изге гамәлләр кылырга, тормышын Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешерлек итеп алып барырга тиеш. Шул ук вакытта кеше белән кеше арасындагы мөнәсәбәтләр дә Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына ирешерлек дәрәҗәдә булсын иде. Дөнья булгач, төрле хәлләр була. Кемнәрдер ачуланыша, бер-беренә үпкә саклый. Менә шушындый хәлләр булган очракта да, бер-беребезгә карап, гафу үтенә һәм гафу итә белсәк иде. Бу дөньядан киткәндә әҗәтләребез, өстебезгә йөкләнгән бурычларыбыз, безгә рәнҗегән кешеләр калмавы мөһим.

Пәйгамбәребез (с.г.в.), кешенең иң хәерле гамәле – балаларына яхшы тәрбия бирү, дип әйткән. Без балаларыбызны нык, көчле булырга өйрәтергә һәм бер-бер хәл булса, соңгы юлга озата белердәй итеп үстерергә тиеш.

:: Ислам дине таләпләрен үтәп җирләү ничек башкарыла?

– Мәетне юабыз, кәфенлибез, аннан соң җеназа намазын укып, ләхеткә салып, җиргә индерәбез. Берничә уч балчык ташлыйбыз. Күмгәч, җәмәгать белән бергәләп дога кылына. Аннан соң таралышалар. Кайбер җирлекләрдә берничә кеше калып, кабернең баш очына басып, дога кылган очраклар да бар. Мәетне озатканнан соң, йорт-җир, керләр юыла. Бу – күркәм гадәт. Җирләдек тә онытттык түгел. Өчесе, җидесе, кырыкларыннан тыш, көн дә дога белән искә алу кирәк. Бигрәк тә җомга көннәрдә. Күпләр: «Үлгән кеше төшкә керде. Ник керә икән?» – дип тә сорый. Димәк, дога кирәк, ул дога сорый. Анда бары тик дога белән генә ярдәм итеп була.

:: Кәфенгә дога тыгып калдыручылар да бар. Бу – дөрес гамәлме?

– Дога тыгып калдыру безгә нәрсәсе белән ярдәм итәр икән? Иң мөһиме – доганы кылу бит. Әйтик, вафат булган кешенең балалары атасына яисә анасына дога кыла белергә тиеш. Яисә инде киресенчә.

Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Әгәр дә кеше үлсә, аның өч төрле гамәленә генә – гел әҗер-савап язылучы сәдакага яки файдалы гыйлемгә, яки аңа дога кылучы балага әҗер-савап языла, ә башкалары туктый», – ди. Ата-анасына дога кылырдай бала кала икән, бу кеше үзеннән соң бик зур мирас калдырган булып санала. Баласы дога ирештергән саен, Аллаһы Тәгалә рәхмәте белән, аңа әҗере языла.

:: Мәетне юганнан соң, гадәттә, аның белән хушлашырга туганнарын чакыралар. Юылган гәүдәгә яшь таммасын, дип тә кисәтәләр. Ни өчен шулай?

– Мәет өстенә күз яше төшсә, аның юылган госеле юкка чыга. Җан барысын да күрә, ишетә, белә. Өстендә елап торганнарын күрсә, аңа да авыр булыр. Мәет юылып, төрелә икән, аңа кагылу, үбү кебек гамәлләрдән тыелу хәерлерәк булыр. Хәзерге вазгыятьтә бигрәк тә. Дөнья хәлен белеп булмый, Аллаһы Тәгалә үзе сакласын.

dumrt.ru

:: Кабер казучыга, табутны күтәреп баручыга сәдаканың билгеле бер күләме бармы? Бирмәсәң дә ярыймы?

– Шәһәрдә моның белән махсус хезмәтләр шөгыльләнә. Авыл җирендә бу мәсьәләгә бәйле эшләр җиңелрәк хәл ителә. Туганнар, якыннар, дуслар чын күңелдән ярдәм итәргә дип килә. Әгәр дә сәдаканы чын күңелдән тапшырасың икән, зарары юк. Мөмкинлегең булмаса, бирмәскә дә мөмкин. Катгый таләп юк.

:: Үлгән кешене кызганып яки артык кайгырып, бик озак еларга ярамый, югыйсә ул су эчендә ята, диләр. Бу чынлап та шулаймы?

– Кайгыру озакка сузылырга тиеш түгел. Елап, без вафат булган кешегә авырлык кына китерәбез. Кешенең тәне үле булса да, җаны бар бит. Сабыр булып, дога кылсак, хәерлерәк булыр. Түземлек кирәк, дип әйтү генә җиңел, әлбәттә. Аллаһы Тәгалә Коръәндә дә: «Без сезне сынарбыз», – ди. Аллаһы Тәгалә сабыр булучылар белән бергә. Сабыр иткән өчен әҗере, рәхмәте булыр. Сынаудан соң җиңеллек килә.

:: Кайчагында үлгән кешенең туганы бик ерактан кайтып җитә алмый. Бу очракта мәетне ике-өч көн җирләми торырга да мөмкиннәр. Шулай рөхсәт ителәме соң?

– Күрәсе дә киләдер анысы. Әмма мәрхүм булган кеше матур булып истә калса, хәерлерәк. Мәетне күмүне ашыктырыгыз, ди Рәсүлебез дә. Мәет бозыла да башларга мөмкин бит. Хәзерге вазгыятьтә бу бигрәк тә актуаль. Кайчагында үлгән кешене озак кына тоталар да, туганнары кайткач, мәет янына хушлашырга кечкенә сабыйларны да кертәләр. Бу бала психикасы өчен бик үк дөрес булмас. Вафат булган кеше ямьсезләнә, төсе дә үзгәрергә мөмкин, күмү эшләрен ашыктыру хәерле.

:: Үлгән кешеләрне искә алып, нинди дога укырга?

– Коръән аятьләре, догалар укырга киңәш ителә. Әйтик, «Әл-Бәкара», «Фатиха», «Әл-Мулк», «Ясин», «Ихлас», «Фәләкъ», «Нәс». Әнә шуларны укысак, салаватлар әйтсәк, хәерле булыр. Ихластан кылынган догалар барып ирешер, Аллаһы Тәгалә аларны ишетер.

Әбу Хәнифә киңәшләре



pixabay.com

Хәнәфи мәзһәбе – сөнни исламда дүрт мәзһәбнең берсе. Мәзһәбнең атамасы – әл-Әгъзам Әбу Хәнифәдән алынган. Имам әл-Әгъзам бөек имам дигәнне аңлата. «Хәниф» – тугры юлда булганнар дигән сүз. Димәк, моннан шул да аңлашыла: Әбу Хәнифә ул – тугры юлга кертүче һәм безне әйдәп баручы, асыл ислам кыйммәтләрен аңлатучы бөек имам. Аның үз исеме Ногман була, ул Гыйракның Куфе шәһәрендә дөньяга килгән.

Әбу Хәнифә менә нәрсәләр киңәш иткән:

– белеп тор, кешеләр белән яхшы мөгамәләдә булмасаң, алар сине дошман күрерләр. Хәтта ата-анаң да синнән риза булмас;

– шәрәфле кешеләргә хөрмәтлә. Гыйлем әһелен бөек дип бел. Остазларга хөрмәт күрсәт;

– күңеленә ошамаган эшкә тотынма. Ялганчылар дәрәҗәсенә төшмә. Хуш күңел белән яшә;

– гафу ит – кайбер нәрсәләргә күзеңне йом. Сиңа кыенлык китергәннәрне кире как, һәркемнең хакын хакла;

– кешеләргә алар кабул итмәслек нәрсәләрне йөкләмә. Алар яраткан нәрсәләрне син дә ярат. Аларга һәрдаим изге нияттә бул;

– колыңнан килгән кадәр һәр кешегә сөеп кара. Синнән югары, түбән һәркемгә сәлам бир.

(Татарстан мөселманнарының Диния нәзарәте сайты мәгълүматларыннан)

Өч хәдис



Изгелектән кем бөртек кадәре генә кылган булса да, аны күрәчәк; явызлык, гөнаһтан бөртек кадәре генә кылган булса да, аны да күрәчәк.

Изгелек черемәс, явызлык, гөнаһ онытылмас, аның арасында хөкем итүче Раббыбыз Аллаһ һич үлмәс, хөкем итүче ул.

И кешеләр, бәлки сез дөнья тереклеген ихтыяр кыласыз, барча көнегезне дөнья өчен генә сарыф итәсез. Бит ахирәт дөньядан яхшырактыр һәм мәңгелектер.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде

КӨРӘШЧЕ ДИНАР КӘРИМУЛЛИН:

«КЕЛӘМДӘГЕ КӨНДӘШ ДУС БУЛА АЛМЫЙ»

Бил алышып, акча эшләп буламы? Келәмдәгеләр арасында дуслык бармы? Бу сорауларга җавапны «Ни хәл?» сәхифәсенең чираттагы кунагы – көрәшче Динар КӘРИМУЛЛИН белән эзләдек.

:: Беренче тапкыр келәмгә чыккан көнең исеңдәме?
– Тумышым белән Теләче районының Олы Мәтәскә авылыннан мин. Алты-җиде яшьләр тирәсе булган микән, мәктәптә көрәш түгәрәгенә йөри башладым. Дөресен генә әйткәндә, ул чакта авыл баласының сайлау мөмкинлеге әллә ни зур түгел иде. Егетләрнең барысы диярлек көрәште. Әти дә: «Әйдә, улым, син дә көрәшеп карыйсыңмы әллә?» – диде. Дөрес, шуннан соң әни белән шактый бәхәсләште әле алар. Әниләр шундый ич инде ул – борчылалар, ут йотып торалар. Минем әни дә имгәнер дип курыкты.

Әл беренче ярышым Теләченең үзендә узды. Әле дә бик яхшы хәтерлим: икенче урын алдым мин анда. Ул чакта тренерымның сөенүен күрсәң! Ә мин кечкенә бит – көрәшкәндә алдым да салдым, алдым да салдым, нәрсә эшләгәнемне аңлап та бетермәгәнмендер.

:: Ә хәзер Лаеш районы өчен бил алышасың. Якташларыңнан сүз ишетергә туры килмәдеме?
– Юк, алар, киресенчә, ярдәм итәргә тырыша. Мөмкинлек чыкканда, кулдан ычкындырмадым, җитәкчеләр дә бик яхшы аңлады. Көрәш белән генә дөнья бетми бит.

:: Димәк, хәзер Теләче командасын читтән күзәтәсең. Яшьрәк якташларың арасында көчле көрәшчеләр күренәме?
– Миңа калса, Теләчедә шәхес буларак бик көчле кешеләр яши. Көчле кешеләр кайда – нәтиҗә дә шунда. Ә яшьләргә килгәндә, мактану һәм масаю буларак кабул итә күрмәсеннәр, ләкин миннән соң көчле егетләр бик күренми әле. Миңа кадәр нинди шәп көрәшчеләр бар иде бит! Хәзер балалар да икенче, тренерлар да... Аларның да өлеше бик зур. Мин моны балалар белән эшләүче тренер буларак әйтәм. Эшлисең икән, нәтиҗәсе дә була.

:: Яшьләр турында сүз куерткач, көрәшнең бүгенге хәленә дә күзәтү ясап алыйк әле.
– Көрәш гаделлеген югалта, дигән сүзләрне еш ишетәбез. Бигрәк тә хөкемдарларга күпне ишетергә туры килә. Көрәшне кем генә хөкем итсә дә, ул барыбер бөтен кешегә ошап бетә алмаячак. Ул – уртада, ә аның тирәягында йөзләгән кеше, димәк, йөзләгән караш, фикер дигән сүз. Хөкемдарларкагыйдәләрне күктән алмый.

Тавыш күбрәк шул кагыйдәләр аркасында чыга да инде. Алар ахыргача уйланып бетмәгән, шуңа, ничек тә җайлар өчен, үзгәрешләр кереп тора. Билбаулы көрәш буенча дөнья чемпионы булдым. Анда бернинди тавыш юк, чөнки һәр адым өчен конкрет балл биреп баралар.

:: Татар көрәше тирәсендәге менә шушы бетмәс шау-шу аның дәрәҗәсен төшермиме?
– Юк. Беренчедән, ул бит инде безнең канга сеңгән. Икенчедән, хәзер шундый заманда яшибез: нидер тирәсендә тавыш чыга икән, ул әйбер таныла башлый. Көрәшкә реклама, киресенчә, җитеп бетми кебек. Кайберәүләр аның нәрсә икәнен белми дә. Билгеле, начар яктан танытучы реклама түгел. Данлыклы татар көрәше турында һәр почмакта сөйләсеннәр иде.

:: Элек Сабантуйларда бөтен кеше үрелә-үрелә көрәш карый иде...
– Чөнки матур алым күрсәтүче көрәшчеләр күп иде. Хәзер яту белән тату була башладылар. Кисәтү өстенә кисәтү. Электән көрәш яраткан кешенең карыйсы килми, билгеле. Шулай да, көрәшнең этешеп-төртешеп йөри торган төрләре белән чагыштырганда, безнеке матур әле ул.

:: Февральдә герой-шагыйрь Муса Җәлил истәлегенә безнең газета гамәлгә куйган көрәш турниры узачак. Ике ел элек батыр калган идең, быелга ниятләрең нинди?
– Җиңәсе килә, әлбәттә! Алла боерса, имгәнмичә, матур көрәш күрсәтергә иде. Муса Җәлил турнирын Татарстан чемпионаты белән чагыштырыр идем мин. Ул ел саен берсеннән-берсе көчле көрәшчеләрне җыя. Ә синең турында башка көрәшчеләргә караганда күбрәк сөйлиләр икән, мондый дәрәҗәдәге ярышларга карата җаваплылык та берничә мәртәбә арта. Оттырмаска, ничек тә яулаган үреңнән артка чигенмәскә кирәк. Кыскасы, алда мине бик мөһим ярыш көтә.

> Көрәшче өчен җәрәхәт алудан да куркыныч нәрсә юктыр. Чөнки ул көрәш белән генә яши, җиңү дип тир түгә. Менә шулай көрәш дип янып йөргән мәлдә җәрәхәт ала да, ике кулына тотып эшләр эше калмый, үзен беркемгә кирәксез итеп тоя башлый. Бер ел элек мин дә шундый хәлдә калдым, ул чорны бик авыр кичердем. Көрәштән башка бернәрсәне дә күрми яшәү начар. Тормышның башка яклары да күрә белергә кирәк. Гаилә корасы, якыннарны кайгыртасы бар. Ә уңышлы көрәшчеләр бездә биш-алтыдыр. Калганнары, тормышның башка өлкәләрен дә кайгыртучылар, яшерен-батырын түгел, ияреп кенә йөри.

:: Киләчәктә, Ходай кушып, ир балаң туса һәм ул да көрәш юлын сайласа, ни диярсең?
– Мин каршы булмаячакмын, әмма көрәштереп карамыйча тәгаен әйтү кыен. Көрәш җиңел спорт төре түгел. Егетләр өчен нәкъ менә шул ягы яхшы да инде аның. Монда дисциплина көчле, һәрвакыт авырлыклар белән очрашып торасың. Тормыш үзе дә җиңел түгел бит – көрәш менә шуңа әзерли. Аннан соң, бу юлны сайласа, аның дуслары булачак. Үз тәҗрибәмә таянып әйтә алам монысын.

:: Дуслык, димәктән, читтән караганда, көрәшчеләр бик тату күренә. Бер-береңә каршы басып, көрәшә башлагач, ул дуслык кая китеп тора соң?
– Яшермим, шәхсән мин көндәшләремне яратмыйм. Келәмдәге көндәшең берничек тә синең дустың була алмый. Икебез дә, җиңәм, дип көрәшәбез бит. Шөкер, әлегә көндәшләрем юк: оттырганнарның барысын да җиңеп чыктым. Гомумән алганда, көрәшчеләрнең күбесе – авыл малайлары, гади, ихлас егетләр. Шуңа да алар арасында татулык көчле. Көрәшнең берләштерә торган көче бар. Татарстан картасының кайсы ноктасына төртсәм дә, Аллага шөкер, һәр районда дус дип әйтерлек кешем бар.

ӘҢГӘМӘНЕҢ ТУЛЫ ВАРИАНТЫ – VATANTAT.RU САЙТЫНДА

Ә СИН ТАНЫЙСЫҢМЫ?

Уенның чираттагысын тәкъдим итәбез. Җырлар башка булса да, шартлар үзгәрмәде: җырчы һәм җырның исемен язып җибәрергә кирәк. Тулы, дөрес һәм беренче җавап бирүчегә бездән бүләк – телефонына 100 сум! Җавапларны +7 (904) 718-14-69 номерына юллагыз.

*Узган атнадагы санда чыккан уенда дөрес җавапны беренчеләрдән булып безнең актив укучыларыбызның берсе **Гөлфинә ханым Шакирова** җибәрде. Афәрин! Рәсемнәр астына без Мөнир Рахмаевның «Ә мин әле яшь», Айрат Сафин һәм DJ Радик башкаруындагы «Ике йөрәк» һәм Фирдүс Тямаевның «Дуслар була санаулы гына» җырларын яшергән идек.*

Әлеге җырны туйларда бик яратып җырлыйлар. Татлы иреннәр очрашканда әйтә торган сүзләр – бу җырның төп күрке.

Бу җырны башкаручы, сөйгәненең исемен кабатлыйкабатлый, йолдызларны саный, югарыдагы бер йолдызлыкны күзәтә.

Әгәр әлеге җырчы якын кешесенең хәер-фатихасыннан калса, ул бәхетле була алмаячак. Җыр әнә шул турыда.

Лилия ГЫЙМАЗОВА әзерләде

26 гыйнвар | Чәршәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «СӨЮЛӘРЕМ СИНЕ ХАК МИНЕМ» 12+
10.00, 23.00 «КОРОЛЕВА ИГРЫ» 16+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «20 МИНУТ» 16+
13.00, 00.50 «Жырлыйк әле!» 6+
14.00 «Азбука долголетия» 6+
14.15 «Если хочешь быть здоровым...» 12+
14.45 «Аулак өй» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Шома бас» һәм « Калеб » 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
18.00 «Халкым минем...» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00, 00.00 «Соотечественники» 12+
00.25 «Черное озеро». Казанский Каин 16+
01.35 «Таяну ноктасы» 16+
02.00 «Манзара» 6+
02.50 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ» 12+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
05.50 Татарстан хәбәрләре 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара» 6+
07.15, 19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
08.40, 23.05, 05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+
09.40 «Ачыктан-ачык» 12+
10.30, 20.30 «Юлчы» (субтитрлы) 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ» 16+
14.00, 02.00 «Ком сәгате» 12+
15.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Яшьләр тукталышы» 12+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
04.15 «Йөрәктән – йөрәккә». Нәҗибә Ихсанова турында телеочерк 6+

1 КАНАЛ

05.00, 09.25 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор» 6+
12.00, 15.00, 18.00 Новости (с субтитрами)
12.15, 17.00, 01.15, 03.05 «Время покажет» 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
18.40 «На самом деле» 16+
19.45 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.30 «ИЩЕЙКА». Новый сезон (S) 16+
22.35 «Док-ток» 16+
23.30 «Вечерний Ургант». Лучшее (S) 16+
00.10 «Горький привкус любви Фрау Шиндлер» 16+
03.00 Новости

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым» 12+
12.40, 18.40 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.55 Детективный телесериал «ТАЙНЫ ГОСПОЖИ КИРСАНОВОЙ» 12+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир» 16+
21.20 «СКЛИФОСОВСКИЙ» 16+
23.35 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.20 Вячеслав Разбегаев, Кирилл Плетнёв, Наталия Быстрова, Анна Гарнова, Андрей Арзяев, Дмитрий Ермак. «ПЫЛЬНАЯ РАБОТА» 16+
04.00 Ярослав Бойко, Анатолий Васильев, Раиса Рязанова, Дарья Повереннова, Илья Соколовский. «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.10, 12.30, 15.40, 17.55, 20.55 Новости
06.05, 23.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.15, 12.35 Специальный репортаж 12+
09.35 «ВОЙНА ЛОГАНА» 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.55 «ЧЕЛОВЕК ПРЕЗИДЕНТА» 16+
14.50, 15.45 «ЧЕЛОВЕК ПРЕЗИДЕНТА: ЛИНИЯ НА ПЕСКЕ» 16+
16.45, 18.00 «ПОЛИЦЕЙСКАЯ ИСТОРИЯ» 16+
18.55 Волейбол. Лига чемпионов. Мужчины. «Динамо» (Москва, Россия) – «Маасейк» (Бельгия). Прямая трансляция
21.00 «Тройной удар». Кулачные бои. Прямая трансляция из Москвы
23.30 «ПОЛИЦЕЙСКАЯ ИСТОРИЯ. ЧАСТЬ 2-Я» 16+
02.00 «Фристайл. Футбольные безумцы» 12+
03.00 Новости 0+
03.05 Волейбол. Лига чемпионов. Мужчины. «Кендзежин-Козле» (Польша) – «Локомотив» (Новосибирск, Россия) 0+
05.00 Баскетбол. Евролига. Женщины. УГМК (Россия) – МБА (Россия) 0+

НТВ

04.55 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня
08.25, 10.25 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Боевик «НЕВСКИЙ. ТЕНЬ АРХИТЕКТОРА» (S) 16+
23.35 «Поздняков» (S) 16+
23.50 «Русская душа». Концерт Андрея Никольского (S) 12+
01.25 «СОСЕДИ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.55 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.00 «Давай разведёмся!» 16+
10.05 «Тест на отцовство» 16+
12.15 «Понять. Простить» 16+
13.20 «Порча». «Детский вопрос» 16+
13.50 «Знахарка» 16+
14.25 «Верну любимого» 16+
15.00 «КРЫЛЬЯ» 16+ Мелодрама. Россия, 2016 г.
19.00 «УСПЕТЬ ВСЁ ИСПРАВИТЬ» 16+
23.00 «ЖЕНСКИЙ ДОКТОР» 16+
00.55 «Верну любимого» 16+
01.25 «Порча» 16+
01.55 «Знахарка» 16+
02.25 «Понять. Простить» 16+
03.15 «Тест на отцовство» 16+
04.55 «По делам несовершеннолетних» 16+
05.45 «Домашняя кухня» 16+
06.10 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА

05.25 «КРАСНЫЕ ГОРЫ» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 21.15 Новости дня 16+
09.25 «КУРЬЕР» 12+
11.20, 21.25 «Открытый эфир». Ток-шоу 12+
13.25 «Оружие Победы». Док. сериал 12+
13.40, 14.05 «КРАСНЫЕ ГОРЫ» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.30 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Без права на ошибку. История и вооружение инженерных войск». Док. сериал 16+
19.40 «Главный день». Премьера! 16+
20.25 «Секретные материалы» 16+
23.05 «Между тем» 12+
23.40 «БАЛТИЙСКОЕ НЕБО» 12+
02.45 «Вторая мировая война. Вспоминая блокадный Ленинград». Док. фильм 12+
03.15 «Легендарные самолеты». Док. сериал. «Истребитель Ла-5» 16+
03.50 «КРАСНЫЕ ГОРЫ» 16+

27 гыйнвар | Пәнҗешәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «ЯҢА ЕЛДА БЕРГӘ БУЛЫЙК» 12+
10.00, 23.00 «КОРОЛЕВА ИГРЫ» 16+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «20 МИНУТ» 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
14.00, 01.15 «Здоровая семья: мама, папа и я» 6+
14.15 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
14.45 «Аулак өй» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Бергәләп өйрәник» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Казаннан – казанга» 12+
18.00 «Юлчы» 6+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Ватандашлар» 12+
00.00 «Видеоспорт» 12+
00.25 «Соотечественники». Анатолий Луппов. Если бы Моцарт жил в Казани 12+
00.50 «Черное озеро». Гильотина по-Казански 16+
01.30 «Таяну ноктасы» 16+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
02.50 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ» 12+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Башваткыч» 12+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара». Мәгълумати- күңел ачу программасы 6+
07.15, 19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
09.40 «Кунак БИТ Шоу» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ» 16+
14.00, 02.00 «Ком сәгате» 12+
15.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Халкым минем» 12+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Калеб» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
03.25 «Онытa алмыйм» 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00, 09.25 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор» 6+
12.00, 15.00, 18.00 Новости (с субтитрами)
12.15, 17.00, 01.20, 03.05 «Время покажет» 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
18.40 «На самом деле» 16+
19.45 «Пусть говорят» 16+
21.00 «Время»
21.30 Премьера. «ИЩЕЙКА». Новый сезон (S) 16+
22.35 «Большая игра» 16+
23.30 «Вечерний Ургант». Лучшее (S) 16+
00.10 «Невский пятачок. Последний свидетель» 12+
03.00 Новости

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым» 12+
12.40, 18.40 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.55 «ТАЙНЫ ГОСПОЖИ КИРСАНОВОЙ» 12+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир» 16+
21.20 Русская серия. Максим Аверин. «СКЛИФОСОВСКИЙ» 16+
23.35 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.20 Вячеслав Разбегаев, Кирилл Плетнёв, Наталия Быстрова, Анна Гарнова, Андрей Арзяев, Дмитрий Ермак. «ПЫЛЬНАЯ РАБОТА» 16+
04.00 Ярослав Бойко, Анатолий Васильев, Раиса Рязанова, Дарья Повереннова, Илья Соколовский. «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.10, 12.30, 15.40, 17.55, 20.55 Новости
06.05, 20.05, 23.30 Все на Матч! Прямой эфир
09.15, 12.35, 05.15 Специальный репортаж 12+
09.35 «РОЖДЕННЫЙ ЗАЩИЩАТЬ» 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.55 «ПОЛИЦЕЙСКАЯ ИСТОРИЯ» 16+
15.05, 15.45 «ДЕЛО ХРАБРЫХ» 16+
18.00 «КРОВЬ И КОСТЬ» 16+
21.00 «Тройной удар». Кикбоксинг. Прямая трансляция из Москвы
23.55 Футбол. Чемпионат мира-2022. Отборочный турнир. Эквадор – Бразилия. Прямая трансляция
02.00 «Фристайл. Футбольные безумцы» 12+
03.00 Новости 0+
03.05 Футбол. Чемпионат мира-2022. Отборочный турнир. Чили – Аргентина. Прямая трансляция
05.30 «Третий тайм» 12+

НТВ

04.50 Сериал «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.15 Сегодня
08.25, 10.25 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» (S) 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Боевик «НЕВСКИЙ. ТЕНЬ АРХИТЕКТОРА» (S) 16+
23.35 «ЧП. Расследование» (S) 16+
00.15 «Захар Прилепин. Уроки русского» (S) 12+
00.50 «Мы и наука. Наука и мы» (S) 12+
01.40 Василий Лановой. «ОШИБКА СЛЕДСТВИЯ» (S) 16+
03.20 «СОСЕДИ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.50 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.55 «Давай разведёмся!» 16+
10.00 «Тест на отцовство» 16+
12.10 «Понять. Простить» 16+
13.15 «Порча». «Чёрная душа» 16+
13.45 «Знахарка» 16+
14.20 «Верну любимого» 16+
14.55 «ЕСЛИ ТЫ МЕНЯ ПРОСТИШЬ» 16+
19.00 «ЧЕЛОВЕК БЕЗ СЕРДЦА» 16+
23.15 «ЖЕНСКИЙ ДОКТОР» 16+
01.10 «Верну любимого» 16+
01.45 «Порча» 16+
02.15 «Знахарка» 16+
02.40 «Понять. Простить» 16+
03.30 «Тест на отцовство» 16+
05.10 «По делам несовершеннолетних» 16+
06.00 «Домашняя кухня» 16+
06.25 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА

05.25 «КРАСНЫЕ ГОРЫ» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 21.15 Новости дня 16+
09.20 «ТЕКУМЗЕ» 12+
11.20, 21.25 «Открытый эфир». Ток-шоу. Премьера! 12+
13.25, 04.20 «Оружие Победы». Док. сериал 12+
13.50, 14.05 «ТАНКИСТ» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.30 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Без права на ошибку. История и вооружение инженерных войск». Док. сериал 16+
19.40 «Легенды кино». Валентин Смирнитский. Премьера! 12+
20.25 «Код доступа». Премьера! 12+
23.05 «Между тем» с Наталией Метлиной. Премьера! 12+
23.40 «ПОРОХ» 12+
01.30 «ДВА ФЕДОРА» 12+
02.55 «Блокада. День 901-й». Док. фильм. 12+
03.40 «Легендарные самолеты». Док. сериал. «Ил-76. Небесный грузовик» 16+

28 гыйнвар | Җомга

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Вести Приволжского федерального округа»
09.15 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «ЯҢА ЕЛДА БЕРГӘ БУЛЫЙК» 12+
11.00 «Нәсыйхәт» 6+
11.30, 16.30, 21.00 «Татарлар» 12+
12.00, 23.10 «20 МИНУТ» 16+
13.00 «Башваткыч» 12+
14.00 «Актуальный ислам» 6+
14.15 «Рыцари вечности» 12+
14.45 «Аулак өй» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Тәймә» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Мин» 12+
19.00, 20.00 «Точка опоры» 16+
22.00 «Вызов 112» 16+
22.10 «КВН РТ-2022» 12+
01.00 «Соотечественники». Две жизни Ильяса Дауди 12+
01.25 «Черное озеро». Вороны везде черные 16+
01.50 «Янам мәхәббәт дулкынында». Марат Фәйрушин 6+
02.50 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ» 12+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.15, 19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
08.40 «Ком сәгате» 12+
09.40, 16.30 «Нәсыйхәт» 6+
10.30 «Казаннан – казанга» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 22.20 «ЕГЕРМЕ МИНУТ» 16+
14.00, 23.05, 02.00 «Ком сәгате» 12+
15.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
20.00 «Аулак өйгә дәшкән егет». Татарстанның халык артисты Айдар Файзрахманов турында телеочерк 6+
01.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Мансур Гыйләҗев турында телеочерк 6+
03.25 Р. Валиев. «И МАШИНА, МАШИНА, ЖИТТЕ МИНЕМ БАШЫМА». К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры спектакле 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00, 09.25 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.50 «Жить здорово!» 16+
10.55 «Модный приговор» 6+
12.00, 15.00, 18.00 Новости (с субтитрами)
12.15, 17.00 «Время покажет» 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.00, 03.40 «Мужское/Женское» 16+
18.40 «Человек и закон» с Алексеем Пимановым 16+
19.45 «Поле чудес» 16+
21.00 «Время»
21.30 Ко дню рождения Владимира Высоцкого. Премьера. «СВОЯ КОЛЕЯ» (S) 16+
23.20 «Вечерний Ургант» (S) 16+
00.15 Док. фильм «Гражданин Китано» 16+
01.25 «Наедине со всеми» 16+
02.10 «Модный приговор» 6+
03.00 «Давай поженимся!» 16+
05.00 «Россия от края до края» 12+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым» 12+
12.40, 18.40 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.55 «ТАЙНЫ ГОСПОЖИ КИРСАНОВОЙ» 12+
17.15 «Андрей Малахов. Прямой эфир» 16+
21.20 Русская серия. Максим Аверин. «СКЛИФОСОВСКИЙ» 16+
01.45 XX Торжественная церемония вручения Национальной кинематографической премии «Золотой Орёл». Прямая трансляция
04.10 Ярослав Бойко, Анатолий Васильев, Раиса Рязанова, Дарья Повереннова, Илья Соколовский. «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 08.40, 12.30, 15.00, 17.55, 20.55 Новости
06.05, 18.00, 23.15 Все на Матч! Прямой эфир
08.45 «ДЕЛО ХРАБРЫХ» 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.35 Специальный репортаж 12+
12.55, 15.05 «ПОЛИЦЕЙСКАЯ ИСТОРИЯ. ЧАСТЬ 2-Я» 16+
15.30 Смешанные единоборства. One FC. А. Малыхин – К. Грищенко. М. Григорян – Ч. Аллазов. Прямая трансляция из Сингапура
18.55 Баскетбол. Евролига. Мужчины. УНИКС (Россия) – ЦСКА (Россия). Прямая трансляция
21.00 «Тройной удар». Смешанные единоборства. Прямая трансляция из Москвы
23.35 «Точная ставка» 16+
23.55 Футбол. Чемпионат мира 2022. Отборочный турнир. Колумбия – Перу. Прямая трансляция
02.00 Футбол. Чемпионат мира-2022. Отборочный турнир. Венесуэла – Боливия. Прямая трансляция
03.00 Новости 0+
03.05 Баскетбол. Евролига. Мужчины. «Зенит» (Россия) – «Анадолу Эфес» (Турция) 0+
05.00 Хоккей. НХЛ. «Даллас Старз» – «Вашингтон Кэпиталз». Прямая трансляция

НТВ

04.55 Сериал «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 Сегодня
08.25, 10.25 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ» (S) 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «ДНК» (S) 16+
17.55 «Жди меня» (S) 12+
20.00 Боевик «НЕВСКИЙ. ТЕНЬ АРХИТЕКТОРА» (S) 16+
23.20 «Своя правда» с Романом Бабаяном (S) 16+
01.20 Квартирный вопрос (S) 0+
02.20 Комедийный сериал «СОСЕДИ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.50 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.55 «Давай разведёмся!» 16+
10.00 «Тест на отцовство» 16+
12.10 «Понять. Простить» 16+
13.15 «Порча». «Выпускной» 16+
13.45 «Знахарка» 16+
14.20 «Верну любимого» 16+
14.55 «МОЙ ЛЮБИМЫЙ ВРАГ» 16+
19.00 «СТАНЬ МОЕЙ ТЕНЬЮ» 16+
23.00 «ЖЕНСКИЙ ДОКТОР» 16+
01.00 «Верну любимого» 16+
01.30 «Порча» 16+
02.00 «Знахарка» 16+
02.30 «Понять. Простить» 16+
03.20 «Тест на отцовство» 16+
05.00 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

04.35 «БАЛТИЙСКОЕ НЕБО» 12+
07.50, 09.20 «Автомобили Второй мировой войны». Док. сериал 16+
09.00, 13.00, 18.00, 21.15 Новости дня 16+
12.00, 13.25, 14.05 «ПРОРЫВ» 16+
14.00 Военные новости 16+
14.20, 18.40, 21.25 «БЛОКАДА» 12+
23.10 «Десять фотографий». Виктор Рыбин 12+
00.00 «ТЕКУМЗЕ» 12+
01.45 «ВЕРТИКАЛЬ» 12+
03.00 «Бомба для Японии. Спасти Дальний Восток». Док. фильм 12+
03.50 «БЛИЗНЕЦЫ» 6+

29 гыйнвар | Шимбә

ТАТАРСТАН

08.00 «Вести-Татарстан»
08.20 Местное время. Суббота

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
07.00 «Sиңа Миннән Sәлам». Музыкаль котлаулар 6+
09.00 «Әй, язмыш, язмыш…» Нуртдин Нәҗмиев 12+
10.00 «Кайнар хит» 12+
11.00 «Мин» 12+
11.30 «Казаннан – казанга» 12+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Видеоспорт» 12+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
13.30 «Когда поёт душа». Док. фильм 6+
14.45 Презентация книг, изданных программой «Рухият» благотворительного фонда «Татнефть» в 2021 году 12+
16.30 «Юлчы» 6+
17.00 «Әдәби хәзинә» 6+
17.30 «Татарлар» 12+
18.00, 04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
19.00 «Халкым минем…» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу 12+
20.00 «Адымнар» 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «КунакБиТ шоу» 12+
23.00 «ХОЛОСТЯКИ» 16+
00.45 «Каравай». Наки Исанбет и Йолдыз Исанбет 6+
01.10 «ЯҢА ЕЛДА БЕРГӘ БУЛЫЙК» 12+
02.50 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ» 12+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Йөрәктән – йөрәккә». Мансур Гыйләҗев турында телеочерк 6+
07.00, 15.00 «Sиңа Миннән Sәлам» 6+
09.00 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
10.00 «Кайнар хит» 12+
11.00, 18.15, 03.00 «Башваткыч» 12+
12.05, 19.05, 03.50 «Җырлыйк әле!» 6+
13.00 «Көтегез, без киләбез». Музыкаль телевизион фильм 12+
17.10 «Казаннан – казанга» 12+
17.45, 05.05 «Халкым минем» 12+
20.00 «Адымнар» 12+
20.30 Әлфия Авзалова исемендәге II халыкара фестиваль-бәйге гала-концерты 12+
22.40 М.Гыйләҗев. «БУРЛАК». Чаллы Татар дәүләт драма театры спектакле 12+
00.10 «Галиҗәнап шагыйрь». Гамил Афзалның тууына 100 ел тулуга багышланган кичә 6+
04.40 «Юлчы» (субтитрлы) 6+
05.30 «Нәсыйхәт» 6+

1 КАНАЛ

06.00 «Доброе утро. Суббота»
09.00 «Умницы и умники» 12+
09.45 «Слово пастыря» 0+
10.00, 12.00 Новости (с субтитрами)
10.15 Ко дню рождения Владимира Высоцкого. «Письмо Уоррену Битти» 16+
11.15, 12.15 «Видели видео?» 6+
13.25 Владимир Высоцкий. «СТРЯПУХА» 0+
14.45 «Владимир Высоцкий. «И, УЛЫБАЯСЬ, МНЕ ЛОМАЛИ КРЫЛЬЯ» 16+
16.40 «Кто хочет стать миллионером?» с Дмитрием Дибровым 12+
18.15 «Точь-в-точь» (S) 16+
21.00 «Время»
21.20 «Сегодня вечером» 16+
23.05 Премьера. Тиль Швайгер. «НЕБЕСА ПОДОЖДУТ» (S) 16+
00.55 «Наедине со всеми» 16+
01.50 «Модный приговор» 6+
02.40 «Давай поженимся!» 16+
03.20 «Мужское/Женское» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России. Суббота»
08.00 Местное время. Вести-Татарстан
08.20 Местное время. Суббота
08.35 «По секрету всему свету»
09.00 «Формула еды». 12+
09.25 «Пятеро на одного»
10.10 «Сто к одному». Телеигра
11.00 Вести
11.35 «Юмор! Юмор! Юмор!!!» 16+
12.50 «Доктор Мясников». Медицинская программа 12+
14.00 Екатерина Кузнецова, Иван Жидков, Анатолий Лобоцкий, Юлия Рутберг, Ксения Князева, Дмитрий Исаев, Михаил Ремизов, Агния Кузнецова. «ПОДАРИ МНЕ ВОСКРЕСЕНЬЕ» 16+
18.00 «Привет, Андрей!» Вечернее шоу Андрея Малахова 12+
20.00 Вести в субботу
21.00 Премьера. Александра Каштанова, Дмитрий Белякин, Кирилл Дыцевич, Анастасия Масленникова, Юлия Такшина, Александр Никитин. «МОЙ ЛЮБИМЫЙ ДРУГ» 12+
01.25 Наталия Антонова, Александр Тютин, Дмитрий Мухин, Анна Михайловская, Игорь Сигов. «СЧАСТЬЕ ЕСТЬ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 Хоккей. НХЛ. «Даллас Старз» – «Вашингтон Кэпиталз». Прямая трансляция
07.30, 09.20, 12.00, 18.05, 20.55 Новости
07.35, 22.30 Все на Матч! Прямой эфир
09.25 «ФИКСИКИ». Мультфильм 0+
09.55 «КРОВЬ И КОСТЬ» 16+
12.05 Биатлон. Чемпионат Европы. Гонка преследования. Мужчины. Прямая трансляция из Германии
13.20 «ТЕЛОХРАНИТЕЛЬ» 16+
15.10 Биатлон. Чемпионат Европы. Гонка преследования. Женщины. Прямая трансляция из Германии
16.25 Мини-футбол. Чемпионат Европы. Россия – Польша. Прямая трансляция из Нидерландов
18.10 «ЕДИНСТВО ГЕРОЕВ» 16+
20.25, 21.00 «ЕДИНСТВО ГЕРОЕВ-2» 16+
22.55 Футбол. Кубок Франции. 1/8 финала. «Марсель» – «Монпелье». Прямая трансляция.
01.00 Смешанные единоборства. One FC. А. Малыхин – К. Грищенко. М. Григорян – Ч. Аллазов. Трансляция из Сингапура 16+
02.00 «Фристайл. Футбольные безумцы» 12+
03.00 Новости 0+
03.05 Волейбол. Чемпионат России «Суперлига Париматч». Женщины. «Локомотив» (Калининградская область) – «Динамо-Ак барс» (Казань) 0+
05.00 Дзюдо. Гран-при. Трансляция из Португалии 0+

НТВ

04.55 «ЧП. Расследование» (S) 16+
05.20 Василий Лановой, Арсений Робак. «ЧУЖОЙ ДЕД» (S) 16+
07.20 Смотр (S) 0+
08.00, 10.00, 16.00 Сегодня
08.20 «Готовим с Алексеем Зиминым» (S) 0+
08.45 «Поедем, поедим!» (S) 0+
09.25 Едим дома (S) 0+
10.20 Главная дорога (S) 16+
11.00 «Живая еда с Сергеем Малозёмовым» (S) 12+
12.00 Квартирный вопрос (S) 0+
14.05 «Однажды…» (S) 16+
15.00 Своя игра (S) 0+
16.20 Следствие вели… (S) 16+
19.00 «Центральное телевидение» с Вадимом Такменевым
20.20 Ты не поверишь! (S) 16+
21.20 «Секрет на миллион». «Семейные тайны Чумакова и Ковальчук» (S) 16+
23.25 «Международная пилорама» с Тиграном Кеосаяном (S) 16+
00.20 «Квартирник НТВ у Маргулиса». EMIN (S) 16+
01.40 «Дачный ответ» (S) 0+
02.30 Комедийный сериал «СОСЕДИ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.50 «МАМА МОЕЙ ДОЧЕРИ» 16+
10.45 «АВАНТЮРА НА ДВОИХ» 16+
19.00 «ВЕЛИКОЛЕПНЫЙ ВЕК» 16+
23.55 «ЧЕЛОВЕК БЕЗ СЕРДЦА» 16+
03.35 «АВАНТЮРА НА ДВОИХ» 16+

ЗВЕЗДА

05.15 «СКАЗКА ПРО ВЛЮБЛЕННОГО МАЛЯРА» 6+
06.40, 08.15 «КОРТИК» 12+
08.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
08.40 «Морской бой». Премьера! 6+
09.45 «Круиз-контроль». Премьера! 12+
10.15 «Легенды цирка с Эдгардом Запашным». Премьера! 12+
10.45 «Улика из прошлого». «Куликовская битва. Между фактом и вымыслом» 16+
11.35 «Война миров». Док. сериал. «КГБ против ЦРУ. Операция «Трианон» 16+
12.30 «Не факт!» 12+
13.15 «СССР. Знак качества» с Иваном Охлобыстиным». Премьера! 12+
14.05 «Легенды кино». Игорь Кваша 12+
15.00 «ЗОЛОТАЯ МИНА» 12+
18.15 «Задело!» Информационно-аналитическая программа 16+
18.30 «ТАНКИСТ» 16+
22.20 «ПРОРЫВ» 16+
00.05 «ЖДИТЕ СВЯЗНОГО» 12+
01.35 «По следам Ивана Сусанина». Док. фильм 12+
02.20 «Оружие Победы» 12+
02.35 «БЛОКАДА» 12+

30 гыйнвар | Якшәмбе

ТАТАРСТАН

08.00 Местное время. Воскресенье

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Пар алма». Илназ Баһ һәм Гүзәл Идрисова 6+
08.00 «Адымнар» 12+
08.30 «ХАЙКЮ». Мультфильм 12+
09.00 « Здоровая семья: мама, папа и я» 6+
09.15 «Тамчы-шоу» 0+
09.45 «Яшьләр тукталышы» 12+
10.15 «Ачыктан-ачык» 12+
11.00 «Бәхетемне килә табасым». Айдар Рәкыйпов 6+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество» 12+
13.00 «Үзгәреш җиле-2021» – «Ветер перемен – 2021» 6+
16.00 «Ком сәгате» 12+
17.00 «Видеоспорт» 12+
17.30 «Татарлар» 12+
18.00 «Башваткыч» 12+
19.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
20.00 «Профсоюз – союз сильных» 12+
20.15 «Батырлар» 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш…» Мәдинә Маликова 12+
22.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
23.00 «УЧИТЕЛЬ АНГЛИЙСКОГО» 16+
00.35 «Ком сәгате» 12+
01.25 «Татар халык җырлары» 0+
02.00 «Манзара» 6+
02.50 «Бәхетемне килә табасым». Айдар Рәкыйпов 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 6+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 00.40 «Татарлар» 12+
06.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
07.00 «Ялантауга ай кунган». Равилә Шәйдуллинаның китабын тәкъдим итү кичәсе 6+
09.00 «Аулак өйгә дәшкән егет». Татарстанның халык артисты Айдар Фәйзрахманов турында телеочерк 6+
10.00 «Юлчы» (субтитрлы) 6+
10.30 «Калеб» 6+
11.10 «Тамчы-шоу» 6+
11.45 «Бергәләп өйрәник» 6+
12.05 «Яшьләр тукталышы» 12+
12.35, 23.20 «Халкым минем» 12+
13.35 «Нәсыйхәт» 6+
14.05 «Калеб» 6+
14.30 «Татар сүзе» 6+
15.30 «Олы юл әйтте…» циклыннан. «Ышаныч». Айдар Фәйзрахманов, Равил Фәйзуллин 6+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш…» (субтитрлы) 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате» 12+
20.00 «Семь дней» 12+
21.10 «Бер язмыш – ике моң». Фәридә–Алсу дуэтының 25 еллык юбилей концерты 6+
01.05 «Манзара» 6+
02.05 «Ялантауга ай кунган». Равилә Шәйдуллинаның китабын тәкъдим итү кичәсе 6+
04.00 «КӨТЕГЕЗ, БЕЗ КИЛӘБЕЗ» 12+

1 КАНАЛ

04.45, 06.10 «ГАЛКА И ГАМАЮН» (S) 16+
06.00 Новости
06.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
07.40 «Часовой» (S) 12+
08.10 «Здоровье» 16+
09.20 «Непутевые заметки» с Дм. Крыловым 12+
10.00, 12.00 Новости (с субтитрами)
10.15 Жанна Бадоева в проекте-путешествии «Жизнь других» (S) 12+
11.15, 12.15 «Видели видео?» 6+
14.00 «Страна Советов. Забытые вожди» (S) 16+
17.15 «Две звезды. Отцы и дети» (S) 12+
19.00 Премьера. «Дело Романовых. Следствием установлено…» 16+
21.00 «Время»
22.00 Премьера. «ХРУСТАЛЬНЫЙ» (S) 16+
00.00 Ник Фрост в комедии «ТАНЦУЙ ОТСЮДА!» (S) 16+
01.45 «Наедине со всеми» 16+
02.30 «Модный приговор» 6+
03.20 «Давай поженимся!» 16+
04.00 «Мужское/Женское» 16+

РОССИЯ 1

05.25 «ПОДРУГИ» 16+
07.15 «Устами младенца»
08.00 Местное время. Воскресенье
08.35 «Когда все дома»
09.25 «Утренняя почта»
10.10 «Сто к одному». Телеигра
11.00 Вести
11.35 «Парад юмора» 16+
14.00 «ПОДАРИ МНЕ ВОСКРЕСЕНЬЕ» 16+
17.50 Премьера. «Танцы со Звёздами». Новый сезон 12+
20.00 Вести недели
22.00 Москва. Кремль. Путин
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.30 Егор Бероев, Екатерина Гусева, Максим Суханов, Егор Пазенко, Андрей Ташков, Тимофей Трибунцев и Татьяна Лютаева. «ЧЕЛОВЕК, КОТОРЫЙ ЗНАЛ ВСЁ» 16+
03.20 Алла Юганова, Янина Соколовская и Александр Волков. «ПОДРУГИ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 Смешанные единоборства. UFC. Х. Нурмагомедов – Г. Тибау. А. Сильва – Ч. Соннен. Трансляция из США 16+
07.00, 09.20, 15.00, 17.55, 20.55 Новости
07.05, 14.15, 20.05, 23.35 Все на Матч! Прямой эфир
09.25 «ФИКСИКИ». Мультфильм 0+
09.45 «СПОРТ ТОША». Мультсериал 0+
09.55 Лыжные гонки. Марафонская серия Ski Classics. 70 км. Прямая трансляция из Италии
12.05 Биатлон. Чемпионат Европы. Смешанная эстафета. Прямая трансляция из Германии
15.05 Биатлон. Чемпионат Европы. Одиночная смешанная эстафета. Прямая трансляция из Германии
16.45, 18.00 «АЛИ» 16+
21.00 Хоккей. НХЛ. «Питтсбург Пингвинз» – «Лос-Анджелес Кингз». Прямая трансляция
00.20 Гандбол. Чемпионат Европы. Мужчины. Финал. Трансляция из Венгрии 0+
02.00 «Фристайл. Футбольные безумцы» 12+
03.00 Новости 0+
03.05 Футбол. Кубок Франции. 1/8 финала. «Ланс» – «Монако» 0+
05.00 Дзюдо. Гран-при. Трансляция из Португалии 0+

НТВ

04.50 Константин Соловьев, Екатерина Вуличенко, Федор Лавров. «БОБРЫ» (S) 16+
06.35 «Центральное телевидение» (S) 16+
08.00, 10.00, 16.00 Сегодня
08.20 «У нас выигрывают!» Лотерейное шоу (S) 12+
10.20 «Первая передача» (S) 16+
11.00 «Чудо техники» (S) 12+
12.00 «Дачный ответ» (S) 0+
14.00 «НашПотребНадзор» (S) 16+
15.00 Своя игра (S) 0+
16.20 Следствие вели… (S) 16+
18.00 «Новые русские сенсации» (S) 16+
19.00 «Итоги недели» с Ирадой Зейналовой
20.10 «Звезды сошлись» (S) 16+
21.40 «Основано на реальных событиях» (S) 16+
01.30 «СОСЕДИ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.40 «Пять ужинов» 16+
06.55 «МОЙ МИЛЫЙ НАЙДЁНЫШ» 16+
11.10 «ТЕНЬ ПРОШЛОГО» 16+
15.05 «УСПЕТЬ ВСЁ ИСПРАВИТЬ» 16+
19.00 «ВЕЛИКОЛЕПНЫЙ ВЕК» 16+
23.20 «СТАНЬ МОЕЙ ТЕНЬЮ» 16+
03.00 «АВАНТЮРА НА ДВОИХ» 16+
06.10 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА

05.40 «БЛОКАДА» 12+
09.00 «Новости недели» с Юрием Подкопаевым 16+
09.25 «Служу России» 12+
09.55 «Военная приемка» 12+
10.45 «Скрытые угрозы» с Николаем Чиндяйкиным. «Альманах №85» 16+
11.30 «Секретные материалы». Док. сериал. «Печорский десант. Диверсия на Русском Севере» 16+
12.20 «Код доступа». «Геном раздора: неестественный отбор» 12+
13.10 «Специальный репортаж» 16+
13.30 «ЛАДОГА» 16+
18.00 Главное с Ольгой Беловой 16+
19.25 «Легенды советского сыска». Док. сериал 16+
22.45 «Сделано в СССР». Док. сериал 12+
23.00 «Фетисов». Ток-шоу. Премьера! 12+
23.45 «ЗОЛОТАЯ МИНА» 12+
02.15 «Блокада снится ночами». Док. фильм 12+
03.00 «Освобождение». Док. сериал 16+
03.25 «ЛАДОГА» 12+

РАДИО РОССИИ

«ТАТАРСТАН» РАДИОСЫ НИЛӘР СӨЙЛИ?

Казан – FM 99,2 МГц
Чаллы – FM 92,01 МГц
Түбән Кама – FM 101,1 МГц

radiotatarstana.ru

Дүшәмбе, 24 гыйнвар

6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуаль әңгәмә»
6.50,7.50,18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10,12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10,19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10 Каюм Насыйри. «Әбүгалисина». Моноспектакль
13.10 «Татарстан дулкынында»
18.10 Яңалыклар
18.25 «Сердәшханә»
18.35 «Җыр – минем гомерлек юлдашым»

Сишәмбе, 25 гыйнвар

6.00-8.00 «Новый день». Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуальное интервью»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.10 Прямой эфир
8.00-11.10,12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10,19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Пар канатлар»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 Концерт
18.25 Александр Ключарев. «Тау әкияте» балетыннан фрагментлар

Чәршәмбе, 26 гыйнвар

6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуаль әңгәмә»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
7.45 «Юллар чатында»
8.00-11.10,12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10,19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Актуальное интервью»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Яшьлек аланы»
18.25 Композитор Илдус Якупов әсәрләре

Пәнҗешәмбе, 27 гыйнвар

6.00-8.00 «Новый день». Панорама событий. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Перекресток»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Прямой эфир
8.00-11.10,12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10,19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 Татарстан: национальные проекты
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Офыклар»
18.25 Әхмәт Гадел шигырьләренә җырлар

Җомга, 28 гыйнвар

6.00-8.00 «Иртәнге нур». Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр».
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00-7.10 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10,12.00-13.10,14.00-15.10,16.00-18.10,19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 Вести ПФО
11.30 «Доброе братство лучше богатства» (на удмуртском языке)
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 Концерт
18.25 Лирик концерт

Шимбә, 29 гыйнвар

8.10 «Моңсара». Сара Садыйкова иҗатына багышланган радиокомпозиция
9.00-10.10, 11.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00 -15.10,16.00 Трансляция радио России
10.10 «Язучылар – балаларга»
10.30 «7 көн». Атналык күзәтү
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 Татар халык көйләре
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10 «Әдәбиятыбыз сәхифәләре». Фатих Әмирхан әсәрләре

Якшәмбе, 30 гыйнвар

8.10-9.00 «Между Волгой и Уралом». Объединенный радиожурнал семи республик
9.00-10.10, 11.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10,16.00-16.10, 17.00 Трансляция радио России
10.10 «Көмеш кыңгырау»
10.30 «7 дней». Обзор событий недели
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 Ял концерты
13.10, 15.10, 16.10 «Татарстан дулкынында». «Галиҗәнап шагыйрь». Илдар Юзеев иҗатына багышланган кичәдән репортаж

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

«Татагрохим» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры Гобәйдуллин Наил Фарук улы һәм җәмгыять коллективы, «Балтач агрохимсервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш инженеры

ХӨСӘЕНОВ
Илшат Миннегали улының

вафат булуы сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе коллективы, филармониянең элеккеге директоры, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре

САФИН
Әсхат Зөфәр улының

вафат булуы сәбәпле, мәрхүмнең якыннарының, туганнарының авыр кайгысын уртаклаша.

ТЕЛЕФОНЛЫ САБЫЙЛАР

ЗАМАНА УЕНЧЫГЫН БАЛАГА ИРТӘ ТОТТЫРУ НИНДИ НӘТИҖӘЛӘРГӘ КИТЕРӘЧӘК?

Кулларына телефон тотып туалар, диләр хәзерге балалар турында. Биләүсәдән төшкән сабыйга чүлмәккә утырганда да, ашаганда да замана уенчыгы кирәк. Бирмәсәң – каравыл кычкыра башлый, бирсәң – бәйлегә әйләнергә мөмкин. Әти-әниләргә алтын урталыкны ничек табарга?

3 яшьтән – «Ютуб»та

Россиядә интернетта утыручы мәктәпкәчә яшьтәге балалар саны өч тапкыр арткан. 2011 елда 3–6 яшьлек сабыйларның 22,6 проценты гаджетлар белән мавыкса, 2020 елда бу сан 68,3 процентка җиткән. Югары икътисад мәктәбе уздырган сораштыру нәтиҗәләре әнә шуны күрсәтә. 2020 елда 3–14 яшьлек балаларның 90 проценты көнгә бер мәртәбә булса да, дөнья «пәрәвезе»нә кергән. Эстониядә бу күрсәткеч – 91, Чехиядә – 92 процент.

– Улыбыз Сәгыйть «Ютуб»ка 3 яшьтән керә башлады. Аңа хәзер – 4 яшь. А4 дигән тәхәллүсле блогер өч дусты белән төшергән видеоларны исе китеп карый. Блогерга 14 миллион кеше язылган. Бал корты турында клип чыккач, көннәр буе шуны карады. Безгә башка каналны ачарга кушмый иде. Ул җырдан туйды инде. Мармелад дигән уенны да бик ярата. Телефон бирсәң, күзләрен минут саен чепелдәтеп йома башлый. Берара бөтенләй туктата алмадык. Бакчадагы тәрбиячесе безне, нерв авырулы бу, дип ачулана. Аптыраган инде, бөтенләй бирмичә дә булмый. Күзләре бетмәсен дип, телевизорга «Ютуб»ны тоташтырдык, – ди Светлана Шәйдуллина.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Мәскәүдә яшәүче артист Нәфисә Хәйруллинаның улы Даниэльгә – 4 яшь.

– Мин телефон бирүгә бөтенләй каршы идем. Иремә дә, телефон, планшетлар бирмибез, телевизор күрсәтмибез, дип әйтеп куйдым. Әмма яшьтәшләре барысын да белгәндә, безнеке артта калачак бит. Һәр әти-әни баласының заманнан артта калмавын тели. Башта Даниэльнең телефонга исе китмәде, ике яшьтә аңа да кызык була башлады. Планшетымны аңа бирдем. Мультфильмнар карамаса да, клиплар, «Око» платформасы карарга ярата. Җыр кирәк аңа. «Тик-ток»ка теркәлмәдек. Күз табибы, әлегә барысы да яхшы, телевизорны якыннан карый башласагыз, телефон бирсәгез, балагыз күзлек киеп йөри башларга мөмкин, дип кисәтте. Планшетны озакка бирмибез анысы. Баланы кызыксындыру авыр түгел. Әгәр барыбыз да дөньяны онытып, интернетка кереп китсәк, әлбәттә, бала да дөньясын онытачак. Алар безгә охшарга тырыша. Йокларга ятканда улыма китаплар укыйм. Укыган шигырьләрне тиз отып кала, – ди Нәфисә Хәйруллина.

«Телне телефон ачмый»

Казандагы 112 нче бакча тәрбиячесе, татар әти-әниләр төркеме әгъзасы Мөслимә Гыйльманова, сабыйлар бакчага телефон алып килми, әмма «акыллы сәгать»ләр тагарга теләүче әти-әниләр бар, ди.

– Яңа СанПиН нормалары буенча хәзер 4–5 яшьлек балалар өчен шөгыль вакытында интерактив такталар куллану бетерелде. Фәкать зурлар төркемендә генә калдырылды. 2–3 яшьлек сабыйларга гаджетларны бөтенләй бирергә кирәкми. Баланың теле ачыла торган вакыт. Аны бит телевизор яки сенсорлы телефон белән ачмыйлар. Әни белән бала арасындагы якынлык мөһим. Балам сөйләшми дип, логопедка йөрүче әти-әниләр дә күп. Бу – шул телефон нәтиҗәсе, – ди Мөслимә Гыйльманова. – Телефон баланың психикасына йогынты ясый. Төрле компьютер уеннарын әйткән дә юк инде. Заманга иярү ул – баш-аяк белән цифрлаштыруга бәйлелек дигән сүз түгел. Әти-әниләр баласының кулына телефон тоттырып куя да үз эшенә чума. Өйдә генә түгел, сәүдә йортларында, әти-әниләр кием сайлаганда да, «тәгәрмәчле кәрҗин»дә утырган балаларның күзе шул замана уенчыгында. Кайберләре аларның нинди мультфильм караганын да белми. «Симпсоннар» мультфильмында хәтта секс турында сөйләшәләр, үзем берничә тапкыр ишеттем. Шуңа күрә ул мультфильмны балага бөтенләй караткмыйм.

Әби-бабай тәрбиясе җитми

Гаджетлы сабыйларга карата «Ак калфак» татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасы рәисе Кадрия Идрисованың да фикерен белештек.

– Бүген тормышны интернет, телефоннан башка күз алдына китерә алмыйбыз. Аны бөтенләй тыеп булмый. Беренчедән, бәләкәй балага телефон алмаска кирәк. Биргән очракта унбиш минут вакыт җитә. Бала телефонны ярата, тыныч кына утыра дигән әйбер булырга тиеш түгел. Башта 1–2 яшьтә мультфильм караса, үсә төшкәч, ул әллә нинди сайт, төркемнәргә кереп китәргә мөмкин. Интернетның чиге юк. Беренчедән, сәламәтлеккә зыян китерсә, икенчедән, психик тайпылышлар турында онытмаска кирәк, – ди Кадрия Идрисова. – Бала белән уйныйбыз икән, аны мультфильмнан да яхшырак кызыксындыра алабыз. Әби-бабайлар тәрбиясе җитми. Яшьләрнең күбесендә, алар оныкларга нәрсә бирә, дигән фикер бар. Юкка гына бу ел Россия халыкларының мәдәни мирасы елы дип игълан ителмәде. Телебез, бишек җырлары, милли киемнәр дә кирәк. Әби-бабайлар, оныкларына кәләпүш кидереп, туган телдә шигырьләр өйрәтә ала. Әти-әниләргә караганда, безнең вакыт күбрәк. Телефонны бала кулыннан алып булмый дип сылтау табабыз. Аның өчен башка төрле шөгыль табарга кирәк. Шул хакта уйланганыбыз бармы? Әгәр проблеманы вакытында хәл итмәсәк, бала виртуаль дөньяда яши башлаячак. Анда аны ачуланучы да, кычкыручы да, үз таләпләрен куючы да юк. Шул ук вакытта әкрен генә бер юл белән алып китүчеләр бар. Эштән кайткач, бала янызга килеп, кызык итеп нәрсәдер сөйли башлый. Аны куәтләп алмыйбыз бит. Бар әле, чыгып тор, вакыт юк, соңыннан килерсең, дибез. Бер, ике, өч килә дә аннан килми башлаячак. Әгәр аның киңәшчесе, дусты була алмыйбыз икән, баланы кулдан ычкындырачакбыз. Ул серен сөйләргә кеше табачак, әмма әти-әнигә түгел, башка юлдашларына.

Сәрия МИФТАХОВА

Рәмилә СӘХӘБЕТДИНОВА,
«ШАЯН ТВ» башкарма директоры – баш мөхәррир, педагогика фәннәр кандидаты:

Сабыйларга бик иртә телефон бирүгә әчем поша. Ашаганда да шушы замана уенчыгын тоттырып куялар. Янәсе, аппетиты начар, ә мультфильм караса, ахшырып китә. Яшь әниләргә, ашамый икән, ник сез аны мәҗбүр итәсез, дигән сорауны биргәнем бар. Ул үзенә тиешлесен болай да ашый. Мультфильмнар карап, сабый үзенең нәрсә ашаганын да белми, ризыкның тәмен дә сизми. Кайбер гаиләләрдә шуны күзәткәнем бар: олылар табын янында, ә балалары читтә интернетта утыра. Бу бит – сабыйларны гаилә традицияләреннән аерып кую дигән сүз. Тавыш-тыны чыкмасын дип, сырхауханәләрдә чират торганда да, сәүдә үзәкләрендә дә гаджет бирәләр. Бала як-ягын күзәтергә тиеш. Телефонны артык куллану акылга да зыян китерә дип уйлыйм. Алар күбрәк аралашырга, сөйләшергә тиеш. Телефонны 1 нче сыйныфка барганда бирү дөрес дип саныйм. Анысы да әти-әни белән хәбәрләшү өчен кирәк. Өйдә телефонны ярты яки бер сәгатькә бирүче гаиләләргә хөрмәтем зур. Дәрес әзерләгәч, күпмедер вакыт интернетта утырырга рөхсәт итәләр, ә болай чикләп куялар. Телевизор каршында да баланы көннәр буе утыртырга ярамый. «Шаян ТВда программаларны балаларның яшь үзенчәлеге, психологиясен истә тотып төзедек. Мәсәлән, кечкенәләр өчен тапшырулар бишәр минутлык. Әти-әниләр барысын да контрольдә тотарга тиеш. Бала уенчыкларын җыештырганда, уен уйнаганда, татарча телевизор яңгырап торса, бик әйбәт. Татар теле аның колагына керәчәк.

Белгеч сүзе

Лилия ГОРОХОВА,
ДРКБның психология бүлеге мөдире, табиб:

Компьютер, телефоннарга бәйле балаларның аппетиты югала, эче, башы авырта башлый. Йокламагач, күз төпләре каралып тора. Бер рәвештә генә утыргач, берничә айдан умыртка баганасында тайпылышлар күзәтеләчәк. Күз табиблары күз күрүе начараю турында еш әйтәләр. Китап укымый, дуслары белән аралашмыйлар. Кафеда утырабызмы, самолетта очабызмы – һаман бер картинаны күрәбез. Кечкенә сабыйларның кулларында – планшет. Элек әниләр, әбиләр кычкырып китап укый, рәсемнәр карап аңлата иде. Хәзер кыйммәтләр үзгәрде. Интернет белән мавыгу нерв системасының эштән чыгуына китерә. Андый бала реаль дөнья белән элемтәсен югалта, яшерен депрессия барлыкка килә. Бала үз эченә бикләнеп, әти-әнисе белән сөйләшмәскә мөмкин. Актив тормыш, кешеләр белән аралашу, ярату бала шәхесен үстерә.

Әгәр бала башта геройлары начар булган мультфильмнар караса, вакыт үтү белән шундый ук темадагы уеннарга күчәчәк. Башка әйбердән, дуслары белән аралашудан, китап укудан, ниндидер максатларга ирешүдән ләззәт алудан туктаячак. Бу сәламәтлектән бигрәк, рухи халәтенә зыян салачак, шәхес буларак җимерүгә китерәчәк. Бала нәрсәнең яхшы икәнен аермый башлаячак. Совет заманында мультфильм, нәфис фильмнарны, телевизор экранына чыкканчы, махсус комиссия тикшерә иде. Күп кенә психологлар балалар яратып карый торган заманча мультфильмнарны, видеосюжетларны өйрәнде. Чыннан да, кайберләре психиканы җимерүгә юнәлтелгән. Белгечләр баланың кулына беренче тапкыр телефон тоттырганда, мультфильмнарны бергә карарга киңәш итә. «Ни өчен бу герой үзен шулай тота?» – дип фикерләрен сорарга кирәк. Бергәләп карау бала белән әти-әни арасындагы ышанычны да арттырачак. Әгәр балагызның кәефе, үз-үзен тотышында нинди дә булса үзгәреш сизсәгез, психологка барыгыз. Балагызны тыңлагыз, аның белән дус булыгыз. Ялгышырга ирек куегыз. Әгәр кадак кагарга җыена икән, без инде бармагына суга күрмәсен, дип кайгыра башлыйбыз. Ә бит телефонда ул – ялгыз. Анда үзен күрсәтү өчен ялган исемнәр таба. Анда аны мактыйлар, «балл»ар җыя. Без балаларны ихтыяҗларын интернетта түгел, тормышта канәгатьләндерергә өйрәтергә тиеш.

ВАКЦИНА: УЙДЫРМА ҺӘМ ЧЫНБАРЛЫК – 2

kzn.ru

Пандемиянең һәркемгә кагыласына берәүнең дә шиге калмагандыр, дияр идең, тик... Әлегәчә коронавирус инфекциясе таралуын туктатуның бердәнбер юлы вакцина икәненә ышанмаучылар шактый. Кибәктән – бөртекне, ягъни уйдырмадан чынбарлыкны аерыр чак. Иң еш очрый торганнарына аңлатмалар тупладык.

1. Күпләр: «Бәлки, авырып алу һәм табигый иммунитет булдыру ясалма вакцина биргән иммунитеттан яхшырактыр», – дип уйлый.
Чын сугыш кырында калганчы, өйрәнүләрдә катнашу күпкә отышлырак түгелме? Вакцина ясату очрагында да шулай. Прививка иммун системасын вирус белән көрәшергә өйрәтә. Шуңа күрә иммун системасы коронавирус белән очрашканда үзен башкачарак тотачак. Ягъни ул инде вируска каршы торырга өйрәтелгән булачак. Прививка кадаткан кешеләрнең дә берничә проценты авырып китәргә мөмкин. Тик аларның чирне авыр кичерү ихтималы бермә-бер кимрәк.

2. Эпидемия вакытында вакцина ясатырга ярамый, диләр.
Киресенчә. Аерым кеше өчен эпидемия нәрсә ул? Бу чир йоктыру ихтималының гаять зур булуы. Шуңа да эпидемия вакытында вакцина ясату әһәмиятле дә. Эпидемия бетә икән, прививка кадату да кирәкмәс, чөнки чир йоктыру ихтималы ул кадәр зур булмаячак. Гади арифметика: күбрәк кешеләр вакцина ясаткан саен, эпидемия тәмамлану ихтималы да зуррак һәм үлүчеләр саны да азрак булачак.

3. «Мин авырмаячакмын, моңа кадәр иммунитетым яхшы иде, хәзер дә сынатмас».
Мондый чорда «яхшы иммунитет» дигән сүзнең мәгънәсе бермә-бер кими. Кеше организмы аерым бер вирус белән очрашмаган килеш, аңа карата антитәнчек тә, иммунитет та барлыкка китерми. Вакцина ясаткач яисә чир кичергәннән соң, организмның теге яисә бу авыруга карата (бу очракта – COVID-19) каршы торучанлыгы үсәчәк.
4. Вирус үзгәреш кичереп тора. Хәзерге вакциналар гына ярдәм итәрме?
Бу мәсьәләне бөтен дөньядагы белгечләр һәрдаим өйрәнә. Әгәр дә теге яисә бу вакцинаның чиргә каршы торучанлыгы начар булу ачыкланса, вакцина составын үзгәртергә мөмкин булачак. Прививка кадату һәм шул рәвешле вирусның таралуын киметүгә бәйле чараларны дәвам иттерү мөһим. Болар барысы да вирусның мутациясен киметергә булыша.

5. Коронавирус белән икенче, өченче тапкыр да авырыйлар.
Хәзерге вакытта илдә коронавирус белән кабат авыру ешлыгы 1 проценттан артмый. Типоспецифик (ягъни аерым бер авырудан саклый торган) иммунитетка бәйле бу. Әйтик, без бит үз гомеребездә грипп белән бер генә тапкыр чирләмибез.
Авырганнан соң, гибрид иммунитет булдырырга кирәк, дип киңәш итә белгечләр. Ягъни табигый иммунитетка вакцинадан соң барлыкка килгәне өстәлергә тиеш. Организмда төрле антитәнчекләр булачак.

6. Алты ай саен яңадан вакцина ясату (ревакцинация) кирәкми. Барлыкка килгән иммунитет та җитә.
Пандемиянең кискен фазасында, ягъни авыручылар һәм чирдән үлүчеләр саны да күп булганда, без иммунитетны һәр ярты ел саен көчәйтеп торырга тиеш. Беренче мәртәбә вакцина ясатканнан соң ярты ел узгач, антитәнчекләр дәрәҗәсе түбәнәя башлый, шулай булгач, тагын бер вакцина алып, антитәнчекләр күләмен куәтләп тору мөһим. Илдә күмәк иммунитет дәрәҗәсе тиешле дәрәҗәдә булгач, прививка 12 айга бер тапкыр кадый торганга әйләнәчәк. Ревакцинация өчен антитәнчекләргә анализ биреп тору кирәкми. Вакциналарның инструкцияләрендә антитәнчекләрнең теләсә нинди дәрәҗәсе ревакцинациягә каршы килми диелгән. Антитәнчекләр күләме югары булганда да вакцина ясатырга мөмкин.

Белгеч сүзе

Марина ПАТЯШИНА, Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе башлыгы:
– Былтыр вакцинациягә бәйле мәгълүмат кырында шактый катлаулы вазгыять килеп туды. Социаль челтәрләрдә антиваксерлар оештырган төркемнәргә каршы торырга туры килде. Бернигә дә карамастан, төрле мәгълүмат мәйданчыкларыннан халыкка һәрдаим сөйләп тордык, аңлаттык, өлкән буын вәкилләрен вакцина ясатырга үгетләдек. Хезмәт коллективларында да махсус аңлатулар алып бардык, 863 семинар үткәрдек. Республикада күрелгән барлык чаралар да дөрес иде. Алар эпидемиологик вазгыятьне кулдан ычкындырмаска һәм хәлнең тиз арада тотрыклануына ирешергә мөмкинлек бирде. Шул рәвешле барлык оешма-предприятиеләр дә үз эшләрен дәвам иттерде, читтән торып уку, эшләүгә күчмәдек.

Чират – балаларда

Коронавируска каршы вакцинаны балаларга да ясый башлыйлар. Сүз 12–17 яшьлек үсмерләр турында бара. Гыйнвар ахырына кадәр Татарстанга балалар өчен чыгарылган вакцинаның беренче партиясе кайтачак.

«Спутник М» вакцинасын ясату ирекле. 15 яше тулмаган балаларга прививканы ата-анасы яки аны тәрбияләүче законлы вәкил рөхсәте белән кадаячаклар. 15 яше тулган балаларга исә ул үзләре риза булган очракта гына ясалачак. Дөрес, ата-ана фикере бу очракта да исәпкә алыначак. Бала үзе вакцина ясатуга риза булып, ата-анасы каршы чыкса, аңа прививка кадамаячаклар.

Татарстанның баш эпидемиологы сүзләренә караганда, хәзерге вакытта республиканың белем бирү оешмаларында укучы балаларның ата-аналарыннан коронавируска каршы прививка кадатуга рөхсәт язуы җыя башлаганнар. «Күпме кешенең риза булуын әлегә төгәл әйтә алмыйм. Ләкин безнең бөтен укучылар да вакцина ясатырга тели, дип мөрәҗәгать иткән белем бирү оешмалары бар инде», – диде Татарстанның баш эпидемиологы Дмитрий Лопушов.

«Спутник М» вакцинасы өлкәннәргә кадый торган «Спутник» вакцинасы нигезендә ясалган. Ул ике компоненттан тора. Алар 21 көн аерма белән ясала. «Интернетта балалар өчен чыгарылган вакцина борынга салыначак дигән хәбәр таралды. Ул дөреслеккә туры килми», – дип ачыклык кертте Лопушов.

Белгеч коронавирусның «омикрон» штаммы пәйда булган шартларда ата-аналарга вакцина мәсьәләсенә аеруча җаваплы карарга киңәш итә. Бәхеткә, Татарстанда балалар арасында «омикрон»ның әлегә бер очрагы да теркәлмәгән. Ләкин ил күләмендә яңа штамм белән очрашкан сабыйлар бар инде. Россия эпидемиологы Александр Горелов сүзләренә караганда, ул 2–5 яшьлек балалар өчен аеруча куркыныч. «Әлегә авыру өске сулыш юлларына һәм бронхларга зыян сала. Моңарчы булмаган бронхиолит очраклары да бар. Һәр өченче балада – диарея», – дип сөйләгән ул федераль басмаларның берсенә.

Хәзерге вакытта башкаланың Республика клиник балалар хастаханәсендә балалар өчен ковид госпитале эшли. Биредә 41 бала дәвалана. Декабрь азагында гына биредә нибары 6 бала яткан булган. Яңа ел ялларыннан соң авыручы балалар саны әнә шулай кисәк арткан. Сезонлы грипп, ОРВИ да вазгыятьне катлауландыра, ди белгечләр.

– Яңа прививка бала организмына нинди дә үзгә тискәре реакция бирер дип куркырга кирәкми. Башка прививкалар кебек ук ул да аллергия генә бирергә мөмкин. Коронавирус белән авыр ятучы, хроник чирләре баш калкыткан балаларга вакцина ясатырга ярамый. Терелгәч, ничә көннән ясарга яраганын да табиб хәл итәргә тиеш, – ди хастаханәнең баш табиб урынбасары Светлана Сенек.

Ел дәвамында республикага 200 мең дозадан артык «Спутник М» вакцинасы кайтыр дип көтелә. «Коронавирус белән бәйле вазгыять катлаулана калса, без әзер. Авырулар кислород, дарулар белән тулысынча тәэмин ителгән. Кадрлар кытлыгы да юк. Госпитальдә ятак урыннар җитәрлек», –дип ышандырды Светлана Сенек.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

2021 елда COVID-19 – саннарда

- коронавирус белән авыручылар саны, 2020 ел белән чагыштырганда, 2 тапкыр күбрәк булган;
- чирне катлаулы формада кичерүчеләр саны 22 процентка арткан;
- 18 яшькә кадәрге балалар арасында авырулар саны 2,9 тапкыр арткан;
- гаилә эчендә чир йоктыру очраклары 36 процентка арткан;
- коронавируска каршы тору чараларын тиешенчә үтәмәгән өчен төзелгән беркетмәләр саны 2 тапкыр арткан;
- 2021 елда оешма-предприятиеләр эшчәнлегенә 19 млн сум штраф салынган. Бу 2020 елга караганда 8 млн сумга күбрәк;
- республика буенча йогышлы авырулар өчен вакытлыча ачылган 62 госпитальдә 17 меңләп медицина хезмәткәре эшләгән. Аларга 700ләп ординатор, шулай ук 1,5 меңләп көллият һәм училище студенты ярдәм иткән;
- 2021 ел азагында республикада күмәк иммунитет дәрәҗәсе 75 процентка җитте. Өлкән яшьтәге кешеләр категориясендә ул 66 процент кына.

28 гыйнварда сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист **Динә Гыйлаҗиева** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

ХАЛЫК АВАЗЫ

Илдар Мөхәммәтҗанов

КАЙЧАН ТӘРТИП БУЛЫР ИКӘН?

Авылыбызда узган ел май аенда су кертер өчен чокыр казыганнар иде. Безнең йорт янында әле дә күмелмәгән килеш тора. Бу хакта авыл җирлеге башлыгына кат-кат әйттек. Тик ул безне тыңламады. Берәр кеше төшеп имгәнгәнен көтәләрдер инде.

Тагын да борчыган проблемам бар. Бездә пай җирләре өчен акча бирәләр. Әмма аны үзара салым түләмәгән кешеләрдән тотып та калалар. Безнең йортта улым да теркәлгән. Монда тормаса да, аның өчен дә акча сорыйлар. Авылда чүпне дә ташларга махсус савыт юк. Ә акчасын җыеп ала беләләр. Анары безнең хат ташучы, пенсия китергәндә, өеп-өеп товар алып килә. Кирәкме, түгелме, сине кыстый башлый. Болай да кечкенә пенсия алам, аның бик күп өлеше даруларга китеп бара. Почта таратучылар ул товарларын сатмаса ярамыймы?

Назирә МИҢНЕГУЛОВА.
Чистай районы Чулпан авылы

Татар Баганасы җирлеге башлыгы Рафис ҖАББАРОВ:
– Без үзара салым акчасын юлларны төзекләндерү, су кертү өчен тотабыз. Чокырны да су торбасы сузар өчен казыткан идек. Аны махсус күммәдек. Безгә су урманнан төшә һәм ул бояҗра буенча әйләнеп йөри. Икенче өлешне ялгап китү җиңел булсын өчен, без су торбасының бер өлешен күммичә калдырдык.

Пай җирләренә килгәндә, без аның өчен кешегә 4200 сум акча бирәбез. Кайбер вакытта үзара салымга кушылмаган кешеләрдән шул акчаны биргәндә, 500 сумны түләмисезме, дип сорыйбыз. Үзләре риза булса, биреп калдыра. Мәҗбүриләү юк.

Чүп мәсьәләсенә килгәндә, бездә аны аерым бер көнне алып китәләр. Кемнәрдер иртәгә чүп җыялар дигән көнне генә, кайберләре теләсә кайчан китереп ташлый. Шунлыктан чүп савытлары гел тулып тора.

Татар Баганасы авылы почта бүлеге җитәкчесе:
– Хат ташучы үз теләге белән товар сатмый. Өч авылга хезмәт күрсәтә. Эше күп, акчасы аз. Өч авылга йөреп эшли. Товар сату өчен план куела. Ул ай саен 12 мең сумлык товар сатарга тиеш. Ул да рәхәттән йөрми. Әмма алырга теләмәгән кешегә беркайчан да көчләп товар калдырып чыкмый. Назирә ханым элек товарны ала иде. Соңгы айда кирәк түгел, дигән. Хат ташучы товарларны кире алып киткән.

СОЦИАЛЬ ИПОТЕКА ПРОГРАММАСЫ ЭШЛИМЕ ӘЛЕ?

Бюджет өлкәсендә эшлим. Фатир алыр идем. Социаль ипотека программасы әле дә эшлиме? Бу программа буенча Казанда фатирның бер квадрат метры күпме тора икән? Шул хакта аңлатсагыз иде.

Гөлназ ГӘРӘЕВА.
Казан

Татарстан Президенты каршындагы Дәүләт торак фондының матбугат сәркатибе Гөлзада КЫЧАКОВА:
– Социаль ипотека программасының туктаганы да юк. Узган ел бу программа буенча 280 мең квадрат метр торак тапшырылды. Фатир алуга чиратка басу өчен, эш урыныңда яки район хакимиятендәге торак комиссиясенә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Алар нинди документлар кирәген әйтә. Аларны алып килгәч, бу программа буенча фатир бирелергә тиеш дисәләр, торак бәясенең 10 процентлы күләмендә беренчел кертем сорыйлар. Шул акчаны түләгәннән соң, сезгә Торак фонды шәхси бит ача. Сез анда логин һәм пароль белән кереп, алга таба фатир оту конкурсында катнаша башлыйсыз. Торакның бер квадрат метры бәясе төрле җирдә төрлечә. Казанда хәзерге вакытта 54 мең сум тора.

КҮРШЕМНЕҢ ФАТИРЫН НИШЛӘТЕРЛӘР?

Күршебез акчасын түли алмагач, өч бүлмәле фатирын алып, аңа «Салават күпере»ннән кечерәк мәйданлы торак бирделәр. Аның фатирын хәзер нишләтәләр икән?

Ильвира САФИНА.
Казан

Татарстан Президенты каршындагы Дәүләт торак фондының матбугат сәркатибе Гөлзада КЫЧАКОВА:
– Мондый очракта фатир киредән конкурска кайтарыла. Башта аны яхшылап тикшерәләр. Ремонт кирәкме, юкмы икәнен ачыклыйлар. Кирәк булган очракта яңадан обойлар ябыштырып, ватылганны төзәтәләр. Фатирның торышына карап, бәя куела. Ул, һәрхәлдә, моннан ун ел элек булган бәя белән сатылмый. Әлеге фатир социаль ипотекага чиратта торучы берәр гаиләгә бирелә.

БАШКА ЮЛЫ ЮКМЫ?

Миңа – 84 яшь. Минем кебекләрне караган өчен 1200 сум акча түләнергә тиеш дип беләм. Әмма безнең авылда мине карарлык кеше юк. 1200 сум акчаны алырга теләгән кешенең беркайда да эшләмәве кирәк. Кем инде шушы акча өчен эшеннән китсен?! Ичмаса, бер мәктәп укучысы да теләк белдерми. Бер бала бар-барын, әмма ул әтисен югалтканлыкка пенсия ала. Аны да караучы итеп билгеләп булмый. Миңа нишләргә соң?

Әнвәр СӘМИГУЛЛИН.
Зәй районы

Россия Пенсия фондының Татарстан бүлеге идарәсе матбугат үзәге җитәкчесе Альбина НИКАНДРОВА:
– 80 яшьтән узган кешеләргә, аларны тәрбияләүче кеше булган очракта, пенсияләренә 1200 сум акча өстәлә. Хәзер бу түләүне алу өчен документларны әзерләү гадиләштерелде. Эшсез булганлык һәм шул уңайдан алган пособие турындагы белешмәне китереп торасы юк. Аны Пенсия фонды электрон рәвештә кирәкле органнан үзе соратып ала. Шулай ук караучы итеп мәктәп яшендәге баланы билгеләгәндә дә, мәктәптә укыганлыгы хакында белешмә, әтисе яки әнисенең һәм опека бүлегенең рөхсәте кирәкми. Шуны да искә төшерәбез: караучы кешегә бу эше өчен пенсиясенең иминият өлешенә һәр ел өчен 1,8 коэффициент өстәлә. Бер караучы берьюлы берничә кешегә хезмәт күрсәтә ала. Әнвәр Сәмигуллинга үзе яшәгән райондагы социаль хезмәт күрсәтүче оешмага мөрәҗәгать итәргә кирәк. Бәлки, берәр караучы табылыр иде.

СЕҢЛЕМНЕ КАЙДА УКЫТЫРГА?

Әти-әнием ятимнәр йортыннан бер кыз бала алганнар иде. Соңрак аның авыру икәнлеге ачыкланды. Акыл ягыннан кимчелекләре бар. Әмма без аны бик яратып яшибез. Шул сеңлебезне кайдадыр укытып чыгарасы иде. Безнең районга Мамадыш шәһәре якын. Андагы политехник көллияткә безнең туганыбыз кебекләрне алалармы икән? Шул хакта белешсәгез иде.

Илназ.
Балык Бистәсе

Мамадыш политехник көллияте директоры урынбасары Динар ХӘКИМОВ:
– Әлеге баланың барлык документларын карарга кирәк. Безнең көллияттә коррекцион төркем бар. Кичке курсларда да укырга була. Шуңа күрә ул баланың туганнарын үзебездә көтәм. Һәрвакыт эш урынымда булам. Килсеннәр.

МУНЧА ТӨЗЕЛӘЧӘКМЕ?

Казанның Дәрвишләр бистәсендә яшибез. Элек безнең бистәдә мунча бар иде. Шуны сүтеп ташладылар да, без хәзер Җиңү проспекты тукталышында урнашкан мунчага йөрергә мәҗбүр. Бистәдә мунча төзерләрме?

Илсөя әбиегез.
Казан

Казанның Совет районы хакимияте матбугат бүлеге җитәкчесе Анастасия ВОЛЧКОВА:
– Казанда Стадион урамы, 1 нче йорт адресы буенча күпфатирлы йорт төзеләчәк. Бу эшне «Смородина» торак комплексы төзелеш оешмасы башкарачак. Проект документларында бу йорт янында мунча комплексы төзү дә каралган.

Гөлгенә ШИҺАПОВА
әзерләде

РИММА ИБРАҺИМОВА:

«ХӘЗЕРГЕ ҖЫРЛАР ТАРИХТА КАЛЫР ДИП ӘЙТЕП БУЛМЫЙ»

Җыр кайчан үзәккә үтеп керә? Халык кабул итсен өчен, җырчы нинди сыйфатларга ия булырга тиеш? Заманча җырчыларны кайда тәрбиялиләр? Болар һәм башка мәсьәләләр хакында Татарстанның халык артисты, мөгаллим Римма ИБРАҺИМОВА белән сөйләштек.

:: Заман башка, дибез, хәзерге эстрадада моңга урын бармы?

– Моң дигәндә нәрсәне күз уңында тотасың бит. Күпләр аны мелизм белән бәйли. Алай гына түгел. Бөтен нечкәлекләрен аңлап, шул ук вакытта заман яңалыкларын да кулланган талантлы җырчылар бар бездә. Җырчылар бар, ә миңа заманча җырларга кытлык, миңа калса. Хәзер җырчылар үзләре яза, диярсез. Алай ерак китеп булмый шул. Мин дә җыр яза алам, ләкин һәр эшнең профессионаллары булырга тиеш. Җырчы – үз урынында, композиторлар – үз урынында. Нәкъ менә композиторларны әзерләргә кирәк безгә. Консерваториядә композиция бүлеге калдымы икән инде...

:: Бәлки хәзер дә сезнең чордагы кебек Мәскәүгә җибәреп укытыргадыр җырчыларны?

– Казан консерваториясе бер дигән җырчылар әзерләп чыгара, мин каядыр җибәреп укытуны файдалы булыр дип әйтмәс идем. Һәрхәлдә, Мәскәүдә татар моңын, безнең мелизмнарны яшь башкаручылар күңеленә салырлар дип уйламыйм.

:: Мәсьәләнең икенче ягы да бар бит әле. Югары уку йортын тәмамлаган затлы, зыялы яшьләр, мәсәлән, унар көн тулы залга концерт куя алмыйлар. Аларга халык килми.

– Мин үзем дә, әйтик, Фирдүс Тямаев кай ягы белән халыкны җәлеп итә икән дип кызыксынып, концертына бардым һәм җавабын таптым да кебек. Безнең профессиональ белемле җырчыларыбыз җырны рәсми рәвештә, бөтен шартын туры китереп җырлый, ләкин күбесенә халыкка якынаю җитми. Менә Әлфия апага (Авзалова. – **Ред.**) халык атлыгып тора иде. Ник дигәндә, аны үзенеке, үз ише дип кабул иттеләр. Фирдүс әнә шуны аңлый. Аның энергетикасы да көчле, үзенең халыкныкы булуын да аңлатты. Дөрес, ул үзе дә җырчы түгеллеген таный, әмма халыкның үзәгенә үтә белә. Ул җырламый, җырны сөйләп бирә. Аңа ияреп, халык сикереп тора, кушылып бии, әйдәгез, дисә, ияреп тә китәрләр иде, мөгаен. Илсөя дә (Бәдретдинова. – **Ред.**) шундый. Аларның үз йөзе, үз җыры, үз алымнары бар. Бу сыйфатларны үзеңдә тәрбияләү – шулай ук талант.

> Илһам Шакиров эһ тә итмичә ун концерт җыя ала иде. Андый шәхес җыр сәнгатендә гомумән юк, булмас та инде. Һич арттырусыз, Илһам абыйны җырда – Тукай дип әйтеп була. Халыкка да якын, җитәкчелеккә дә «син» дип дәшә. Олысын да, кечесен дә игътибар үзәгендә тота. Аңарда сез кем дә мин кем дигән масаю да юк иде.

Бер кызык хәлне дә искә алыйм әле. Концертларның берсендә бер ир кул күтәрде дә: «Хатыным рус милләтеннән иде, аның өчен бер русча җыр җырлагыз әле», – диде. Илһам абый: «Русча җырны өендә үзең җырларсың инде», – дип җавап кайтарды. Аңардан башка русча җыр сораучы булмады кебек.

Бу көннәрдә Илһам абый, Әлфия апаларның туган көннәре булды. Без, өлкән буын кешеләре, зиратка барып, догалар кылдык, олугларыбызны искә алдык. Яшь башкаручыларны да шушындый чараларга җәлеп итәсе иде. Алайса без аларны, үткәннәрне белмиләр, дип тиргибез генә, тәрбияләү турында уйламыйбыз.

:: Сез балаларыгызны татар мәктәбендә укыттыгыз, Туфан абый Миңнуллин белән бергә Ф.Аитова исемендәге кызлар гимназиясен ачуда катнашып йөрдегез. Оныкларыгызга да татарча укуны, гомумән, татарча белүне таләп итеп куясызмы?

– Әйе, безнең гаиләдә андый таләп бар. Һәрхәлдә, мин оныкларым белән татарча гына сөйләшәм. Улым Фәритнең балалары татарча матур итеп сөйләшә. Ләйлә, Әнвәр, хәзер инде Гомәрне дә «Инстаграм»да беләләр. Инде менә Каюм үсеп килә. Аның да теле татарча ачылыр, Алла боерса. Кызым Ләйсәннең олы улы Ролан белән ике телдә дә сөйләшәләр. Мин татарча гына сөйләшәм. Сөйләмендә азрак проблемалар булгач, кодагый, әллә русча гына эндәшикме балага, дип әйтеп караган иде дә, курыкма, балалар бакчасына киткәч, хәзер русчаны отып алачак ул, дидем. Бу чыннан да шулай. Минем максат – күңелләренә телгә оеткы салу. Әле менә Ләйсәннең бәләкәчен карарга ярдәм итәм. «Бишек җыры» җырлап йоклатам, әкиятләр сөйлим.

Кызлар гимназиясен исә мин безнең бәхеткә булды, дим. Анда очрашуларга еш кына Туфан абый да килә иде. Шул вакытта Туфан абый белән сөйләшеп, татар мәктәбе оештыру насыйб булды. Гәрчә мәктәбе әллә ни зур булмаса да, бу безнең өчен зур шатлык иде. Аның кебек халыкчан, милләт дип үлеп китәрдәй кешеләр башка юктыр да ул. Ркаил Зәйдулланың «Үлеп яратты» дигән әсәре бар. Туфан абыйга да туры килә үлеп яратты дигән төшенчә. Милләт турында уйлап, югалтуларны йөрәгенә якын алып, иртә китте дә ул.

:: Казанның милли йөзе бармы?

– Үзгәртеп корулардан соң миллилеккә башлангыч бар иде. Халык урамнарда иркенләп татарча сөйләшә башлады, башта мәктәпләрдә татарча сыйныфлар оешты, соңрак милли мәктәпләр ачыла башлады. Башлангычы булды, әмма бу эштә ахырына кадәр барып җитә алмадык. Хәзер инде, безнең милли мәгариф бар, дип авыз тутырып әйтә дә алмыйбыз. Шулай да матур башлангычлар бар, өметләник әле. Тормыш беркайчан да тигез юлдан гына бармаган, ахыры хәерле булсын, дип телик.

:: Эстрадада хәлләр ничек? Казан мәдәният институтының эстрада бүлегенә татарча белгән яшьләр киләме?

– Татарча бик язлы белгәне дә, авырлык белән аралашканы да бар. Төрлесеннән киләләр. Аларның тырышып татарча җыр өйрәнүләре күңелгә сары май булып ята, билгеле. Әмма җырны аңлап башкару өчен иң әүвәл үрнәкләрне бергә туплау кирәк. Минем иң зур теләгем дә, борчуым да – элек башкарылган иң матур җырларны яхшы оркестр белән яңадан яздырып туплау. Элеккеге җырлар күңелгә үтеп керә, хәтердә кала, дибез. Элек бит җырны профессиональ композиторлар язган. Хәзер яшь композиторлар юк дәрәҗәсендә. Кемне әйтә алабыз? Телгә бер Эльмир Низамов килә. Аның үз юнәлеше бар, әмма анда милли аһәң дә юк түгел. Композиторлар кытлыгы бар һәм ул бик тә сизелә.

Безнең заманга кайтсак, Мәскәүдә укып кайткан яшь җырчыларга композиторлар махсус җырлар иҗат иттеләр. Яңа җырларны тыңларга безне Татарстан Композиторлар берлегенә чакыралар иде. Яңа җырларны тыңлап, үзебез сайлап ала, радиога яздыра идек. Алай гына түгел, җыр сайлап алып, өйрәнеп беткәч тә, радиога яздырганчы комиссия карый иде. Анда исә җырның сүзе, көе, башкару алымнары җиз иләк аша үтә. Җыр әнә шундый аралашулар нәтиҗәсендә туа иде. Хәзер җырчы белән композитор арасында андый элемтәләр юк. Җырчы ул элемтәне кирәксенми дә бугай инде. Әйтик, Фирдүс Тямаев үзенә үзе җыр яза, тегесе дә үзенә җыр яза, монысы да калышмый, дигәндәй.

> Үзе яза, үзе җырлый, үзе бии, җитмәсә, үзе сөйли, ягъни алып та бара... Шундый заман китте. Миңа калса, бу юнәлешләрнең һәрберсенең үз осталары булырга тиеш. Шул чакта гына концерт халыкка ниндидер мәгънә, тәрбия бирә алыр иде.

Комиссия дигәннән. Кайчак шулкадәр матур җырлар да шул комиссияне үтә алмый. Ә синең аны бик башкарасың килә. Гастрольдә рөхсәт ителмәгән җырны башкарасың икән, утлы табага басасыңны көт тә тор. Ничек барысын да тикшереп өлгергәннәр, хәйран тамаша.

:: Галим, тәнкыйтьче Миләүшә Хәбетдинованың «Җидегән чишмә» җыры турындагы фикере кызыклы. Ул: «Яшь җырчылар «Җидегән чишмә»не күтәрә алмый. Бар да дөрес, җиренә җиткереп башкарыла, ләкин җанга ятмый, киңлек җитми», – дигән фикер әйтә. Сез аның белән килешәсезме?

– Аның фикерендә хаклык бар. Җырчылар җырның мәгънәсенә төшенеп җиткәнскә мөмкин, ә аларга аңлатып бирүче юк. «Җидегән чишмә»ләрне аңлау өчен татар теленең бөтен нечкәлеген тою, үткәннәрне белү дә кирәк бит әле. Ә менә Илүсә Хуҗина, Айгөл Гардисламова турында, шәхсән үзем югары фикердә. Көчле тавышлы, моңлы җырчылар. «Үзгәреш җиле» фестивалендә Айгөл Гардисламова башкарган җырны рәхәтләнеп тыңладым. Кабул итмәслек заманчалаштыру бар, шул ук вакытта Айгөлләр кебек җырның үзәген аңлап башкаручылар да бар. Нишлисең, замана икенче, сәхнәдә – шоу. Билгеле, моңа «Үзгәреш җиле»нең дә тәэсире булмыйча калмады. Бик җилләп үтте безнең өстән. Нәтиҗәдә бөтенләй икенче төрле башкару хәзер. Җырлары да шулай. Һәр заманның – үз сүзе, үз җыры шул инде. Хәер, бу җырлар тарихта кала дигән сүз түгел әле.

Блиц-сораштыру

– Иң зур теләгегез?
– Безнең заманда нинди генә авырлыклар, җитмәүчелекне кичерсәк тә, күңел тыныч иде. Хәзер иртәгәге көн өчен хәвеф бар. Билгесезлек борчый. Балаларга тыныч тормыш, исәнлек телим. Иң зур теләгем шушы.
– Иң истә калган гастроль?
– Зиннур Нурмөхәммәтов укудан кайткач, безне Магаданга җибәрделәр. Җир чите бит инде, монда интернациональ җырлар кирәктер дибез, үзебезчә. Шыгрым тулы зал, концертны русча җырдан башладык. Халык, без татарча җыр тыңларга килдек, дип йодрык болгап кычкырырга тотынмасынмы. Шунда ук татарчага күчеп, бөтен белгән җырларны башкардык. Гастроль-сабак булды ул. Аншлаг белән дүрт концерт бирдек.
– Иң яраткан җырчыгыз?
– Бу арада Казахстан җырчысы Димаш Кудайбергенны әсәренеп тыңлыйм. Андыйлар хакында гасырга бер туа, диләр. Чын мәгънәсендә талант, минем башка беркемдә дә андый тавыш мөмкинлеген күргәнем дә, ишеткәнем дә юк.
– Яраткан язучыгыз кем?
– Мөхәммәт абый Мәһдиев. Юлда бергә күп йөргәнгә, холкын яхшы белгәнгә дә якын ул миңа. Әдәби теле, әсәрләре хакында әйткән дә юк, камиллек үрнәге инде алар.

:: Ә русча, татарча катнаштырып җырлаучыларга ничек карыйсыз? Мәсәлән, «Малай на белом барсе» ул татарча җырмы, русчамы? Бу күренеш татар теленең киләчәгенә тискәре тәэсир итмәсме?
– Җыр үзенә җәлеп итә, яшьләрне кызыксындыра. Мин дә кызыксынып тыңладым. Ләкин болар – вакытлыча җырлар. Мин аны киләчәктә дә җырларлар дип уйламыйм.

:: Ретро җырларны сату-алу дөресме?
– Безнең заман кешесенә мондый күренешләр, гомумән, аңлашылмый. Без җырны теләге булган һәрбер җырчы башкара алган чорда күтәрелдек. Халык күңеленә исә җыр бер җырчыга бәйле рәвештә кереп кала. Ул күп очракта беренче башкаручы була. Хәзер заман икенче. Бер караганда, иҗат кешесенә яшәр өчен әсәрен сатарга да кирәктер. Җыр да – тауар. Әмма җыр өчен талашып, судлашып, аны халык алдына чыгару матур түгел. Халыкка иҗатың белән танылырга кирәк.

Заман, сүз дә юк, икенче. Без дәүләт игътибарын күргән буын булдык. Концерт, театрларга беренчеләр йөрде. Һәм алар ничектер халыкка якын иделәр. Тамашачы белән дә аралаштылар. Минтимер Шәймиевнең, мәсәлән, Сабан туеннан соң безне үз машинасына утыртып кайтканы да булды. Ул һәрберебезне, балаларыбызны белә, хәл-әхвәлне сорашмыйча калмый. Хәзер дә шулай. Без дә иҗатка җаваплы карадык. Бу – гел үз өстеңдә эшләү дигән сүз.

:: Тавышны саклар өчен ниләр эшлисез? Аның аерым кагыйдәләре бармы?
– Гел җырлап торгач, тавыш саклана. Спортчы үзенә нинди таләпләр куйса, җырчы да үзенә шундый таләпләр куя. Тавышны камилләштерү җәһәтеннән әйтәем. Күнекмәләрне даими эшләргә, җырларга кирәк. Аның кагыйдәсе шул. Студентларны укыткач, мин күнекмәләрне даими эшлим, җырлаудан да туктаган юк әле.

Гөлинә ГЫЙМАДОВА

< Дәвамы. Башы 2021 елның 10 декабрь санында

Әллә нәрсә булды бу дөньяга. Әллә дөнья үзгәрде, әллә Сәет белән Хәния. Аптыраш.

Кызларны салкын су белән коендырырга җыенган малайлар да никтер тынып калганнар. Әллә ниндиләр – үзләренә охшамаганнар. Барысының да күзләре кызлар арасында уңайсызланып басып торган кыска итәкле, дулкындай кара чәчле, зур кара күзле кызда. Кунак кыз да оялып кына итәкләрен тартып куйды. Акрын гына исәнләште. Тавышы куркып кына, тыйнак кына чыкты. Үзе карашын чүәк башларына төбәде.

– Исәнме, кунак кызы, чибәркәй, – дип тынлыкны бозды Әгъләм. Авылыбызга нинди нур иңгән дисәм, матур кыз кайткан икән. Кемнәргә кайттың, чибәр кыз, Миңлебикә әбиләргәме? Бүген кичкә шулар капка төбен саклыйбыз икән. – Аннары, борылып, малайларга дәште: – Берегез дә якын киләсе булмагыз, яңак төбегезгә сылармын. Колагыгызга киртләп куегыз: әле сезнең башыгыз яшь Әгъләм абыегыздан узып йөрергә!

Их, дип уйлап куйды Сәет, ник мин Әгъләм кебек кыю түгел икән? Ул әнә әйтәсе сүзен кырт кисеп әйтә. Ә мин шул хыялланып ятарга гына булдырам. Кызлар, чишмә улагына чиләкләрен куеп, су ала башладылар. Чиләкләре тулган бере китә торды. ак-кара күренмәде. Иртән күз алдыннан китмәгән Хәния Зәйтүнәнең бер күз сирпүеннән эреп югалды. Бүген көтү куганда күргән Хәниянең утлы карашы, кунак кызының рәхмәтле кара күзләреннән түгелгән моңлы күз карашы белән бер булып кушылды. Нәрсә булды? Дөньяның асты өскә килде. Тизрәк кич җитсен иде. Әгъләмнең кисәтүеннән куркып тормас, Миңлебикә әбиләрнең капка төбенә барып басар. Миңлебикә әби – өшкерүләргә маһир карчык, әнисе авырганда, гел хәлен белеп торды. Их, әнисе исән булсын иде. Юк шул, Сәет әнисен бик аз хәтерли. Ул бабасы белән генә үсте. Әтисе исән дә бит, тик ул Сәетне улы дип тә белми.

Ниһаять, кич җитте. Малайлар малларын авыл ягына бордылар. Кояш Ялантау өстенә менеп җитте, аннары беркадәр эленеп торды-торды да, дөньяга моңсулык таратып, тау астына тәгәрәп юкка чыкты. Малайлар, каештан үргән чыбыркыларын шартлатып, сыерларны авылга таба кудылар. Көтү артыннан сөт исе, муллык исе ияреп барды. Рәхәт иде малайларга, күңелле иде. Әле өйдә әниләре пешергән умачлы аш, тәмле сөтле чәй көтә. Көтүдән кайткан малайларын әниләре мактый-мактый сыйларлар. Аннан соң малайлар юынып, киенеп, клуб бакчасына җыелырлар. Аларга кызлар да кушылыр. Әллә ничә җирдә түгәрәк уен уйнарлар. Сугыштан соң туган яшь-җилкенчәкнең авыр, ләкин тыныч, матур тормышы бу.

РАВИЛӘ ШӘЙДУЛЛИНА-МУРАТ

ЯЛАНТАУГА АЙ КУНГАН

(БӘЯН)

Менә кунак кызы да чишмә улагына чиләген куйды. Ике чиләгә дә көмештәй су белән тулгач, көянтәгә эләсе итте. Ләкин балачактан су ташып өйрәнгән авыл кызларыныкы шикелле осталыгы юк иде аның. Икенче чиләген көянтә башына эләктерәм дигәндә генә, чиләге ычкынып китеп, чак егылмады. Чиләктәге суы түгелеп бетте. Малайлар хихылдап көлә башладылар. Кызның күзләренә яшь тулып, ике яңагы буйлап акты. Аның, чиләкләрен ташлап, чишмә буеннан йөгереп чабасы, салкын сулы чишмә суында агып китәсе, кеше күзеннән югаласы килде. Суы түгелгән чиләген алырга иелүе булды, аягы таеп, янә егыла язды. Иңеннән көянтәсе үк төшеп китте. Кыска итәге ачылып, төз аяклары күренде. Малайлар яшь тайлар кебек кешнәделәр. Кыз үксеп елап җибәрде. Тегеләргә кызык иде. Авылның сүзгә кесәгә керми торган кызларыннан бу кыз аерылып тора иде шул.

Сәет малайлар арасыннан аерылып чыкты да кунак кызының көянтәсен иңнәренә салды. Чиләкләренә су тутырып, көянтәсенә элде. Кыз күтәрелеп караган иде, күзләре Сәет күзләре белән очрашты. Ул әкрен генә: «Рәхмәт», – диде. Сәет шунда дөньядан кичте. Үзенең иске күлмәгеннән, ямаулы чалбарыннан оялды. Бирчәйгән учларын кая яшерергә белмәде. Кызның шулай күз сирпеп бер каравы Хыялый Сәетне үтерде. Ул, башы әйләнеп, кыз янында ничек киткәнен дә абайламады. Малайлар янына кабат килеп басты. Ярый әле малайлар берни сизмәделәр. Бармакларын авызларына тыгып, әче итеп сызгырдылар, көлештеләр. «Попробуйте, берегез-бер Миңлебикә әбиләрнең капка төбенә барасы түгел, сыек танаулар», – дип үкерде Әгъләм.

Сәет кичне җиткерә алмый йөдәп бетте. Бүген кояшы да байый алмый интектерде. Сәет малайларның сүзләрен ишетмәде. Күзенә

Сәет сыерларын абзарга кертеп япты да бабасы пешереп куйган кабыклы бәрәңгене утырып ашады. Яшел суганга үрелгән кулын кире тартып алды. Суган исе кунак кызына ошамас! Әнә бит, ничек итеп күзләренә карап: «Рәхмәт!» – диде. Бигрәк культурный, дип уйлады Сәет. Тиз генә юынып керде дә намазлык өстендә утырган бабасына: «Бабай, мин клуб бакчасына чыгам», – диде. Бабасы, намазын укып бетереп, инде тәсбих тарта иде. Әллә ишетмәде, әллә ишетеп тә, дәшәсе итмәде. Сәет уенга киеп чыгарга дигән киемнәрен барлый башлады. Соры төстәге чалбарын чыгарды, аның балак очлары сүсәргән, чалбар үзе күп юып үтүкләүдән шомарып беткән, ялтырап тора. Сүсәргән җепләрен кисеп, киеп караса, чалбар балагы тубыктан өскә менеп киткән. Әле язын гына таман иде. Сәет аптырап калды. Кешелеккә кия торган күлмәгенең дә җиңе кыскарган. Ярый, җиңне сызганып та була анысы. Аякка кия торган ботинкасының башы купкан. Сәет ботинкасын ачу белән почмакка атты. Чалбары икенче якка очты. Үзе өйалдындагы булмә якка җәелгән сәкегә сузылып ятты.

Әнә инде тулган ай күтәрелеп килә. Клуб бакчасы ягыннан гармун тавышы ишетелә. Гармунчы Әгъләм әле бию көен, әле «Зәлилә»не өздерә генә. Бүген бигрәк дәртләнеп уйный, дип уйлап куйды Сәет. Күзләренә яшь килде: үзен җәлли! Аннан әнисен исенә төшерде. Ул вафат булганда, малай әле мәктәпкә дә кермәгән иде. Сәкедә яткан хаста әнкәсенең ап-ак йөзен әле дә хәтерли Сәет. Ул көнне Миңлебикә әби (аны авылда «Каракай әби» дип тә йөртәләр) кергән иде. Әнисе елый-елый сөйләде. Аның бер көйгә генә сөйләгән тавышы шундый моңсу иде.

Дәвамы бар >

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

ЗАҺИД МӘХМҮДИ

(04.07.1960 – 19.01.2022)

Якташыбыз – язучы, журналист, режиссер Заһид Мәхмүди көтмәгәндә арабыздан китеп барды.

Ул киңкырлы шәхес иде: бер үк вакытта әсәрләр иҗат итте, берничә газета чыгарды, кинофильмнар төшерде, эшмәкәрлек белән шөгыльләнде. Үзенең иҗат юлын Кукмара районының «Хезмәт даны» газетасында әдәби хезмәткәр буларак башлап җибәргән, аннан республиканың төрле газета-журналларында, Татарстан радиосында эшләгән кеше һәм халык яратып укый торган берничә газета мөхәррире буларак, ул халык арасында тәҗрибәле журналист һәм төрле жанрда язылган китаплар авторы булып танылды. Башкаларны да әдәбият-сәнгатькә тартырга теләде: районыбызда берничә тапкыр балалар һәм яшьләр арасында иҗади бәйгеләр оештырды. Соңгы елларда профессиональ дәрәҗәдә татарча кино төшерү уе белән яшәде, бу хыялын да үзенең гаиләсе, дуслары ярдәмендә тормышка ашырып, берничә фильм иҗат итте.

Заһид Мәхмүди чын мәгънәсендә талантлы да, хыялый да кеше иде. Авыл туризмын үстерү идеясе дә бар иде аның, шуны тормышка ашыру өчен үз хуҗалыгында экзотик хайваннар асрый башлады. Бер урында таптануны яратмады, эшчәнлегенең бер тармагы буларак, ял урыннары өчен җиһазлар, сувенирлар җитештерүне дә җайга салды.

Үзенең туган ягын яратты, берничә ел элек туган нигезенә – Кукмара районының Манзарас авылына кайтып төпләнүе дә шуңа дәлил булып тора.

Мәхмүдов Заһид Борис улының вафаты – район халкы өчен зур югалту. Аның якты истәлеге күңелләрдә озак сакланыр. Ихлас күңелдән гаиләсенең, туганнарының, якыннарының авыр кайгыларын уртаклашабыз.

С.Д. Димитриев, Р.А. Ратникова, Р.Н. Гаянова, Р.А. Кәримуллина, А.Х. Гарифуллин, Ч.Г. Хәнәфина, А.М. Әхмәтшина, Г.М. Шәрипова

Фикер

Бәхетсез бәхетлеләр

Хәзер сыерларның сөтен арттыру өчен, виртуаль дөнья күзлекләре (VR-күзлекләр) куллана башлаганнар икән. Бер төрек фермеры үз сыерларына шундый күзлекләр кидертеп, сөтне 22 процентка арттырган. Абзарда коры печән утлаучы сыерлар, VR-күзлек кигәч, үзләрен мул һәм сусыл үләнле болында йөрибез дип күрә һәм сөт арта. The Science Times журналы бу уңайдан виртуаль дөньяда сыерлар үзләрен бәхетле тоялар, стресс кими һәм шул сәбәпле сөт күбәя дигән фараз әйтә.

Юк, минем бу язмам авыл хуҗалыгы җитештерүчәнлеген арттыру турында түгел әле. Мин яңадан инде әллә ничәнче тапкыр бәхет турында сөйләшергә телим. Бәхетнең – хис, әмма аның безнең тәндәге гормоннар белән бәйле булуы турында галимнәргә инде күптән мәгълүм. Берничә «бәхет гармоны» бар, организмда шулар бүленеп чыга икән, адәм баласы ләззәт кичерә. Менә шул ләззәтне без бәхет дип атарга күнеккәнбез. Аңлашыла инде: ләззәт даими була алмый. Әйтик, кулны ишек ярыгына кыстырсак, татлы хисләр кичерү мөмкин түгел, әмма ул очракта да сызлауны уңай якка файдаланырга була. Калифорния университетының Лоретта Грациано Бройнинг исемле атказанган профессоры бар. Ул «Ничек итеп баш миен серотонин, дофамин, эндорфин һәм окситоцин эшләргә өйрәтергә» дигән китап язган. Китапның исеменнән күренгәнчә, бәхет гормоннары бүленеп чыгу безнең баш миебезгә, төгәлрәк итеп әйтсәк, уйларыбызга бәйле.

Мин бу соңгы сүзләрне ассызыклап идем. Бәхет акчага, матди байлыкларга, чибәр хатынга, корыч кебек нык сәламәтлеккә, кайсы материкта яшәүгә, кайда эшләүгә түгел, синең боларга мөнәсәбәтеңә бәйле. Бер үк куләмдәге матди байлыклар белән кеше үзен чиксез бәхетле тоя ала, гадәттән тыш бәхетсез дә була ала. ДЦП белән туган улын 27–28 яшьләргә кадәр тәрбияләгән танышым бар минем. Социаль челтәрләрдә улы белән төшкән фотоларын куя, баласын ничек яратуын сүзләр белән белдерә, аның гариплеге ана өчен һич кенә дә кыенсыну, укенеч, аяныч хисләре тудырмый, улын сөюе белән үзен чиксез бәхетле итеп тоя иде. Инде улы үлде аның, ана ул югалтуны аяныч бер хәл итеп кабул итте. Сау-сәламәт балаларыннан зарланучы күпме әти-әни барлыгын исәпкә алсак, бәхет һәм бәхетсезлек тойгыларының полюслары бик шартлы рәвештә урнашуын аңлар идек.

Кыскасы, безнең күзләребез дөньяны ничек итеп күрә, бәхетебез шуңа бәйле. Күңел күзенә тәкәбберлек дигән виртуаль күзлек кидертеп куйсак, безнең тормыш тоташ оттырыштан торачак: байлык, сәламәтлек, балалар һәм матди дөньяның башка кыйммәтләре ягыннан котылгысыз рәвештә безне узучылар күп булачак һәм артта калу тойгысы безне гаҗәеп дәрәҗәдә бәхетсез итәчәк. Кеше нәфесе гадәттә үзен дөньядагы иң өстен кеше үк дип бәяләми, шуңа күрә «йолдыз»лар, «Форбс» исемлегендәге миллиардерларда эше юк аның, үз даирәсендәгеләрдән өстен чыгу, шулар белән ярышуны гадәт итә. Хезмәттәшләр, күршеләр, туганнар ярышы; буллинг һәм мобинг дип аталган балалар-олылар коллективларындагы рәхимсез уч алу, түбәнгә төшерергә тырышулар, туганлык җепләренең өзелүе – тәкәбберлек китергән бәхетсезлекләрнең кыска исемлеге менә шулар.

1978 елда Иллинойс психологлары бер тикшеренү үткәргәннәр: өч төркем кешене күзәткәннәр. Беренче төркемдә – лотерея-га миллион доллар отучылар, икенчесендә куркыныч аварияләргә эләгеп, тулысынча яисә өлешчә параличланган кешеләр тупланган, өченче төркем очраклы кешеләрдән җыелган. Кара акыл боларның кайсын бәхетле дип санаячак инде? Иллинойс психологлары тикшеренүе гаҗәп нәтиҗәләргә китергән. Беренчедән, лотерея ярдәмендә миллионер булучылар өченче төркемдәгеләрдән үзләрен аз гына да бәхетлерәк тоймаган. Көндәлек тормышта алардан гына түгел, хәтта авария корбаннарыннан да азрак ләззәт алып яшәгәннәр. Ә параличланып урын өстендә ятучыларның киләчәккә өметләре миллионерларныкыннан зуррак булып чыккан.

Тәкәбберләнеп, танышларыңны байлык ягыннан узарга теләгәндә, менә бу нәтиҗәләрне, һичшиксез, истә тотарга кирәк: беренчелек тажы сине бәхетле итмәячәк. Көнчелек утында яну, ярсып, башкаларны түбәнсетергә, үзеңнең өстенлегеңне расларга тырышулар сиңа стресстан һәм бер бәйләм чирләрдән башка берни дә бирмәячәк. Бүгенге җәмгыятьнең бөтен бәласе дә үзеңне бүтәннәр белән чагыштырып, аларны узарга тырышуда. Менә шул тырышлык туры һәм күчерелмә мәгънәсендә арттан пычак кадауларга китерә. «Ватаным Татарстан»да күптән түгел генә эти малын бүлешә алмыйча, берсе икенчесен утергән бертуганнар турында язма чыккан иде. Туганнарның бугазлашуына фәкыйрьлек түгел (икесе дә – мул тормышлы кешеләр алар), өстен чыгарга тырышу китергән. Бәхет дип әйтеп буламы инде менә моны?

Бәхет күплектә түгел, азлыкта. Азлыкның җитүе һәм хәтта ләззәт тә бирүен ризык мисалында сынап карарга була. Сирәк һәм аз ашыйсың икән, гел татлы ризык кына ашыйсың, хәтта ризыгың каткан ипи сыныгы булса да, ул сиңа зур ләззәт бирә. Димәк, байлык ул – «Форбс» исемлегенә эләгү түгел, ә булганга шөкер итү. Даими шөкер итсәң икән, даими рәвештә бәхет гормоннары бүленеп торачак тәнеңдә, серотонин, дофамин, эндорфин һәм окситоцинга кытлык кичермәячәксең. Ә теге миллиардерлар һәм олигархлар бәхете ул – виртуаль бәхет кенә, күзгә алдавыч күзлек кию нәтиҗәсе.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ



14 гыйнвар санында чыккан сканвордның җаваплары
Горизонталь буенча: таныш, аем, Конан, дая, Ибраһимов, Рим, Рем, сагызак, Тынис, чылану, Каас, ипле, ахмак, уалу, атчабар, фани. **Вертикаль буенча:** ки, Брахмапутра, Гир, калач, Туктамыш, Фалес, уба, нинди, атыла, Ан, кыл, Харис, Шандор, Наум, Аверин, амия, суык.

ВИКТОРИНА

Тәкъдим ителгән һәр сорауда җавапларның өч варианттан берсе генә дөрес. Берсен сайлап, белемегезне тикшерегез.

1 **«...һич тә нинди дер бер очраклы күренеш түгел иде... Аны бөтен җаны-тәне белән яңага сусаган, үзгәртеп коруларның заман таләбе булуын тойган Русь үзе тудырды...» Сүз кем турында бара?**

А) Ярослав Мудрый;
Б) Явыз Иван;
В) Петр I.

2 **Корбан Бәрдыев «Рубин» футбол командасына ничәнче елда тренер булып билгеләнә?**

А) 2001;
Б) 2010;
В) 2019.

3 **Тафта – ул...**

А) йортның аскы каты;
Б) тыгыз итеп сугылган киҗе-мамык яисә ефәк тукыма;
В) керамик плитә.

4 **Хушлашырбыз... Бәлки, бик озакка Мин утырган урын буш булыр». Бу шигырь юлларының авторы кем?**

А) Илдар Юзеев;
Б) Роберт Әхмәтҗанов;
В) Хәсән Туфан.

Җаваплар: 1) В; 2) А; 3) Б; 4) В.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 18156 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 208

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сәйт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – **газета килмәсә яки соңарып килсә**

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+